| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>УРМАН ХУҖАЛЫГЫ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

ПРИКАЗ БОЕРЫК

26.11.2018 г.Казань №_656-осн_

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2013 елның 22 октябрендәге 571/21-осн номерлы боерыгы белән расланган Лениногорск урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү турында

Лениногорск урманчылыгы чикләрендә урманнарны тәртипкә китерү барышында ачыкланган урманнарның структурасы һәм торышы үзгәрүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының 2017 елның 27 февралендәге 72 номерлы боерыгы белән расланган Урман хуҗалыгы реглмаментлары составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдә булу чорлары һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибенең 16 пунктының 1 пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2013 елның 22 октябрендәге 571/21-осн номерлы боерыгы белән расланган Лениногорск урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына, кушымтада бирелгән яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Юридик бүлеккә әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу һәм Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) рәсми рәвештә бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Мәгълүмат технологияләрен үстерү секторына әлеге боерыкның теркәүгә алынуын һәм бастырып чыгарылуын техник яктан тәэмин итәргә.

4. Финанслар, бухгалтерия исәбенә алу һәм тикшереп тору бүлегенә әлеге боерыкның татар теленә тәрҗемә ителүенә бәйле чыгымнарның финанслануын тәэмин итәргә.

5. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары Ә.Н.Бәдретдиновка йөкләргә.

Министр Р.Ә.Кузюров

Татарстан Республикасы

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы

Лениногорск урманчылыгының
# УРМАН ХУҖАЛЫГЫ РЕГЛАМЕНТЫ

Казан, 2018 ел.

# Эчтәлек

**КЕРЕШ** ........ **4**
Россия Федерациясе закон актлары ........ 5
Урман хуҗалыгы регламентын төзү өчен мәгълүмат базасы ........ 17
**1. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР** ........ **18**
1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама ........ 18
1.2. Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре ........ 39
**2 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН РӨХСӘТЛЕ ФАЙДАЛАНУ НОРМАТИВЛАРЫ, ПАРАМЕТРЛАРЫ ҺӘМ ЧОРЛАРЫ, УРМАННАРНЫ САКЛАУ, ЯКЛАУ ҺӘМ ТОРГЫЗУ БУЕНЧА НОРМАТИВЛАР** ........ **45**
2.1. Урманнардан агач материалы әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 45
2.2. Урманнардан чәер әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 113
2.3. Урманнардан агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 114
2.4. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 128
2.5. Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 136
2.6. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 139
2.7. Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 147
2.8. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 149
2.9. Урманнардан урман плантацияләре ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 160
2.10. Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 161
2.11. Урманнардан урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 163
2.12. Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 165
2.13. Урманнардан сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 170
2.14. Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 172
2.15. Урманнардан агач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 185

2.16. Урманнардан дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары ........ 186
2.17. Урманнарны саклауга, яклауга һәм торгызуга карата таләпләр ........ 187
2.18. Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча урманнардан файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре ........ 289
**3 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН ФАЙДАЛАНУДА ЧИКЛӘМӘЛӘР........ 290**
3.1. Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләмәләр........ 290
3.2. Махсус якланучы урман кишәрлеге төрләре буенча чикләмәләр........ 291
3.3. Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләмәләр ........ 295

# КЕРЕШ

Әлеге урман хуҗалыгы регламенты – Лениногорск урманчылыгы урманнарыннан файдалану, аларны саклау, яклау һәм яңадан торгызу өчен нигез булып тора.

Регламентны эшләүчеләр:

«Поволжский леспроект» «Рослесинфорг» ФДУП филиалының Казан экспедициясе, 420087, Казан ш., Г. Кутуй ур. – 155 а (2008 елның 18 февралендәге № 64 дәүләт контракты).

Үзгәрешләр керткән оешмалар турында белешмәләр:

«Рослесинфорг» ФДУП Казан филиалы, 420087, Казан ш., Г. Кутуй ур. – 155 а (2010 ел, 29 октябрь, № 441 дәүләт контракты).

«Ульяновсклеспроект» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте, Ульян ш., Орлов ур., 21а (2012 ел, 25 декабрь, № 815 дәүләт контракты).

Лениногорск урманчылыгы урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертү нигезе булып Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының урман хуҗалыгы регламентларын эшләү буенча хезмәтләр күрсәтүгә 2017 ел, 23 октябрь, № 2017.54195 дәүләт контракты тора.

Урман хуҗалыгы регламенты Россия Федерациясе Урман кодексының 87 ст. 7 өлеше, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу чорларын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге № 72 боерыгы нигезендә эшләнде.

Урман хуҗалыгы регламентының гамәлдә булу чоры – 2019 елның 01 апреленә кадәр.

Урман хуҗалыгы регламенты урманчылыкның территориясенә, урман үсү шартларына карата кулланылучы урманнарны комплекслы үзләштерү нормативлары һәм параметрлары җыелмасын үз эченә ала һәм урман кишәрлекләренең хокукый тәртибен билгели.

Урман хуҗалыгы регламенты урманчылык чикләрендә урманнардан файдалануны, аларны саклауны, яклауны, торгызуны гамәлгә ашыручы гражданнар һәм юридик затлар тарафыннан зарури үтәлергә тиеш (РФ УК 87 ст. 6 өл.).

Урманчылык чикләрендә урнашкан урманнарга карата урман хуҗалыгы регламентында РФ УК 87 статьясының 5 өлеше нигезендә түбәндәгеләр билгеләнә:

1) урманнардан рөхсәтле файдалануның РФ УК 25 статьясы нигезендә билгеләнә торган төрләре;

2) кисентеләрнең яше, тотылачак диләнке, урманнардан файдалану чорлары һәм алардан рөхсәтле файдалануның башка параметрлары;

3) РФ УК 27 статьясы нигезендә урманнардан файдалануны чикләү;

4) урманнарны саклауга, яклауга, торгызуга карата таләпләр.

Урман хуҗалыгы регламентының гамәлдә булу чорына файдалану төрләре буенча урманнардан ел саен мөмкин булганча файдалану күләмнәре билгеләнгәндә, алар түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

5) кеше сәламәтлеген кайгырту максатларында, урманның әйләнә-тирәлек хасил итү, су саклау, яклау, санитария-гигиена һәм башка файдалы үзлекләрен саклау һәм көчәйтү;

6) җәмгыятьнең урманнарга һәм урман ресурсларына булган ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен урманнардан күп максатларда, нәтиҗәле итеп, өзлексез, киметмичә файдалану;

7) урманнарны торгызу, аларның токым составын һәм сыйфатын яхшырту, уңыш бирүчәнлеген арттыру, аларны саклауны һәм яклауны көчәйтү;

8) урман фонды җирләреннән нәтиҗәле файдалану;

9) бердәм техник сәясәт нигезендә урман хуҗалыгы алып баруның нәтиҗәлелеген арттыру, фән, техника һәм алдынгы тәҗрибә казанышларын куллану;

10) биологик төрлелекне, тарихи-мәдәни һәм табигый мирас объектларын саклау.

Алга таба урман хуҗалыгы регламентын төзегәндә нигез итеп алынган норматив-хокукый, норматив-техник, методик закон документларының исемлеге китерелә:

## Россия Федерациясе закон актлары

Россия Федерациясе Урман кодексы (алга таба – РФ УК),

Россия Федерациясе Су кодексы (алга таба – РФ СК),

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК),

Россия Федерациясе Граждан кодексы (алга таба – РФ ГК),

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге № 2395-1 Россия Федерациясе законы (алга таба – «Җир асты байлыклары турында» РФ законы).

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге № 69-ФЗ федераль закон (алга таба – «Янгын куркынычсызлыгы турында» ФЗ).

«Махсус сакланучы табигый территорияләр турында» 1995 елның 14 мартындагы № 33-ФЗ федераль закон (алга таба – № 33-ФЗ федераль закон).

«Хайваннар дөньясы турында» 1995 елның 24 апрелендәге № 52-ФЗ федераль закон (алга таба – № 52-ФЗ федераль закон).

«Геодезия, картография һәм киңлек мәгълүматлары турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 30 декабрендәге № 431-ФЗ федераль закон (алга таба – № 431-ФЗ федераль закон),

«Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән имин эш итү турында» 1997 елның 19 июлендәге № 109-ФЗ федераль закон (алга таба – № 109-ФЗ федераль закон).

«Намус иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 елның 26 сентябрендәге № 125-ФЗ федераль закон (алга таба – № 125-ФЗ федераль закон).

«Күчемсез мөлкәтнең дәүләт кадастры турында» 2007 елның 24 июлендәге № 221-ФЗ федераль закон (алга таба – № 221-ФЗ федераль закон).

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы № 69-ФЗ федераль закон (алга таба – № 69-ФЗ федераль закон).

«Җир корылышы турында» 2001 елның 18 июнендәге № 78-ФЗ федераль закон (алга таба – № 78-ФЗ федераль закон).

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы № 7-ФЗ федераль закон (алга таба – № 7-ФЗ федераль закон).

«Электр энергетикасы турында» 2003 елның 26 мартындагы № 35-ФЗ федераль закон (алга таба – № 35-ФЗ федераль закон).

«Элемтә турында» 2003 елның 07 июлендәге № 126-ФЗ федераль закон (алга таба – № 126-ФЗ федераль закон).

«Россия Федерациясе Урман кодексын гамәлгә кертү турында» 2006 елның 04 декабрендәге № 201-ФЗ федераль закон (алга таба – № 201-ФЗ федераль закон).

«Орлыкчылык турында» 1997 елның 17 декабрендәге № 149-ФЗ федераль закон (№ 149-ФЗ федераль закон).

«Ау һәм аучылык ресурсларын саклау һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге № 209-ФЗ федераль закон (алга таба – № 209-ФЗ федераль закон).

«Үсемлекләр карантины турында» 2014 елның 21 июлендәге № 206-ФЗ федераль закон (алга таба – № 206-ФЗ федераль закон).

## Урман кодексында каралган норматив һәм хокукый актлар (2018 елның 01 гыйнвары буенча)

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| **Россия Федерациясе Хөкүмәте актлары** | | |
| 91 ст. 7 өл. | Дәүләт реестрыннан өземтәләр биргән өчен түләү. | РФ Хөкүмәтенең «Дәүләт урман реестрыннан өземтәләр биргән өчен түләү күләме һәм аны алу тәртибе турында» 2007 елның 03 мартындагы № 138 карары |
| 100 ст. 2 өл., 81 ст. 38 п. | Урман кишәрлекләренә һәм урманнардан файдаланганда барлыкка килә торган мөлкәт хокукларына китерелгән зыянны түләү. Урман законнары бозылу | РФ Хөкүмәтенең «Урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен исәпләп чыгару турында» 2007 елның 08 маендагы № 273 карары |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянның күләмен исәпләү таксаларын һәм методикаларын раслау | |
| 96 ст.; 81 ст. 36 п. | Федераль дәүләт урман күзәтчелеге (урман сагы), аны гамәлгә ашыру тәртибе | РФ Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт урман күзәтчелеген (урман сагын) гамәлгә ашыру турында нигезләмә раслау турында» 2007 елның 22 июнендәге № 394 карары |
| 50 ст. 3 өл. | Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле агач материалының максималь күләмен билгеләү | РФ Хөкүмәтенең «Зат, затлар төркеме тарафыннан әзерләнергә тиешле максималь агач материалы күләмен билгеләү турында» 2007 елның 22 июнендәге № 395 карары |
| 73 ст. 4 өл.; 81 ст. 27 п. | Федераль мөлкәттәге урман ресурслары бирәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеген арендалау өчен урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары билгеләү | РФ Хөкүмәтенең «Федераль мөлкәттәге урман кишәрлеген арендалау буенча урман ресурслары күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм урман кишәрлеге мәйданы берәмлеге өчен түләү ставкалары турында» 2007 елның 22 маендагы № 310 карары |
| 44 ст. | Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм аларны эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану. | РФ Хөкүмәтенең «Су объектын файдалануга тапшыру турында карар әзерләү һәм кабул итү тәртибе турында» 2006 елның 30 декабрендәге № 844 карары |
| 45 ст. | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану. | РФ Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 1995 елның 09 июнендәге № 578 карары |
| 76 ст. 3 өл. 81 ст. 30 п. | Урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре буенча түләү. Федераль мөлкәттәге җирләрдә әзерләнә торган агач материалы күләме берәмлеге өчен түләү ставкалары билгеләү. | РФ Хөкүмәтенең «Урман ресурсларының күләм берәмлеге өчен түләү ставкалары һәм федераль мөлкәттәге урман кишәрлегенең мәйдан берәмлеге өчен түләү ставкалары турында» 2007 елның 22 маендагы № 310 карары |
| 16 ст. 3 өл., 60.3 ст.; 81 ст. 17 п. | Урманнарда санитар куркынычсызлык. Урман утыртмаларын кисү тәртибе | РФ Хөкүмәтенең «Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре турында» 2007 ел, 20 май, № 607 карары |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 16 ст. 3 өл.,<br>53 ст. 3 өл.<br>81 ст. 16 п. | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы.<br>Урман утыртмаларын кисү тәртибе. | РФ Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен раслау турында» 2007 елның 30 июнендәге № 417 карары;<br>РФ Хөкүмәтенең «Урманнарны янгынга каршы кору чаралары хакында» 2011 елның 16 апрелендәге № 281 карары;<br>РФ Хөкүмәтенең «Урман янгыннары аркасында урманнарда барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләрне бетерү өчен федераль башкарма хакимият органнары көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында» 2017 елның 2 декабрендәге № 1464 карары;<br>РФ Хөкүмәтенең «Урман янгыннары нәтиҗәсендә барлыкка килгән гадәттән тыш хәлләр турында» 2011 елның 17 маендагы № 376 карары;<br>РФ Хөкүмәтенең «Урман янгыннарын сүндерү планын һәм аның формасын эшләү һәм раслау кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 17 маендагы № 377 карары;<br>РФ Хөкүмәтенең «Урманнарда янгын куркынычы һәм урман янгыннары турында белешмәләрнең төгәл булуын тикшереп тору кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 18 августындагы № 687 карары |
| 22 ст. 3 өл. | Урманнарны үзләштерү өлкәсендә инвестиция эшчәнлеге.<br>Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары исемлеген әзерләү һәм раслау. | РФ Хөкүмәтенең «Урманнарны үзләштерү өлкәсендә өстенлекле инвестиция проектлары турында» 2007 елның 30 июнендәге № 419 карары |
| 6 ст. | Урманнар урнашкан җирләр. | РФ Хөкүмәтенең «Урман фонды җирләрен бүтән (башка) категория җирләренә күчерү турында документлар составы һәм аларны әзерләү тәртибе турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы № 48 карары |
| 105 ст. 7 өл. | Урман-парк зоналарының, яшел зоналарның вазыйфаи зоналары. | РФ Хөкүмәтенең «Урман-парк зоналарының вазыйфаи зоналарын, урман-парк зоналарының мәйданын һәм чикләрен, яшел зоналарын билгеләү турында нигезләмә раслау турында» 2009 елның 14 декабрендәге №1007 карары |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 13 ст. | Урман инфраструктурасы | РФ Хөкүмәтенең «Яклаучы урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы объектлары исемлеген раслау турында» 2012 елның 17 июлендәге №1283-р боерыгы |
| 21 ст. | Урман инфраструктурасына бәйле булмаган объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү. | РФ Хөкүмәтенең «Яклаучы урманнар, эксплуатация урманнары һәм резерв урманнары өчен урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектлар исемлеген раслау турында» 2013 елның 27 маендагы 849-р номерлы боерыгы |
| 45 ст. | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану. | РФ Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналар чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус шартларын билгеләү тәртибе турында» 2009 елның 24 февралендәге № 160 карары |
| 105 ст. 7 өл. | Урман утыртмаларын сату-алу турында типик шартнамә. | РФ Хөкүмәтенең «Урман утыртмаларын сату-алуның типик шартнамәсе турында» 2015 елның 31 октябрендәге № 1178 карары |
| 105 ст. 7 өл. | Урман кишәрлегенең типик аренда шартнамәсе. | РФ Хөкүмәтенең «Урман кишәрлеген арендалау буенча типик шартнамәсе турында» 2015 елның 21 сентябрендәге № 1003 карары |
| **Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы (алга таба – РФ ТРЭМ) норматив актлары** | | |
| 62 ст. 3 өл.;<br>81 ст. 21 п. | Урман торгызу.<br>Урман торгызу кагыйдәләре. | «Урман торгызу кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 29 июнендәге № 375 боерык |
| 60.15 ст. | Сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләре | «Россия Федерациясе Кызыл китабына яисә РФ субъектлары кызыл китапларына кертелгән, сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 елның 29 маендагы № 264 боерык |
| 16 ст. 3 өл.,<br>64 ст. 3 өл.;<br>81 ст. 23 п. | Урманнарны тәрбия кылу.<br>Урманнарны тәрбия кылу кагыйдәләре.<br>Урман утыртмаларын кисү тәртибе. | РФ Табигать министрлыгының «Урманнарны тәрбияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 22 ноябрендәге № 626 боерыгы |
| 103 ст. 6 өл.<br>81 ст. 40 п. | Махсус саклanучы табигый территорияләрдә урнашкан | «Махсус саклanучы табигый территорияләрдә урнашкан урманнардан |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, торгызу үзенчәлекләре. | файдалану, аларны саклау, яклау, торгызу үзенчәлекләрен раслау турында» 2007 елның 16 июлендәге №181 боерык |
| 53.1 ст. | Урман янгыннарын кисәтү. | «Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары төрләрен, урманнардан файдаланучы затларның әлеге чаралар белән тәэмин ителү нормативларын, урманнардан файдаланганда булырга тиешле урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары нормаларын раслау турында» 2014 елның 28 мартындагы № 161 боерык |
| 53.2 ст. | Урманнарда янгын чыгу куркынычын һәм урман янгыннарын мониторинглау. | «Урманнарда янгын куркынычын һәм урман янгыннарын күзәтүне гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2014 елның 23 июнендәге № 276 боерык |
| 15 ст. 3 өл. | Урман үсә торган зоналар һәм урманлы районнар. | «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында» 2014 елның 18 августындагы № 367 боерык |
| 87 ст. 7 өл.<br>81 ст. 34 п. | Урман хуҗалыгы регламентларының составы, аларны эшләү тәртибе, аларның гамәлдә булу вакыты һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибе. | «Урман хуҗалыгы регламентларының составын, аларны эшләү тәртибен, аларның гамәлдә булу чорларын һәм аларга үзгәрешләр кертү тәртибен раслау турында» 2017 елның 27 февралендәге № 72 боерык |
| 60.5 ст. | Урман патологиясе буенча дәүләт мониторингы. | «Урман патологиясе буенча дәүләт мониторингын гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 елның 05 апрелендәге № 156 боерык |
| 60.7 ст. | Зарарлы организмнар таралуны кисәтү. | «Зарарлы организмнар таралуны кисәтү буенча чараларны гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 12 сентябрендәге № 470 боерык |
| 60.6 ст. 4 өл. | Урман патологиясе буенча тикшеренүләр.<br>Урман патологиясе буенча тикшеренүләрне уздыру тәртибе. | «Урман патологиясе буенча тикшеренүләр уздыру тәртибен һәм урман патологиясе буенча тикшеренү актының формасын раслау турында» 2016 елның 16 сентябрендәге № 480 боерык |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 16.1 ст. 4 өл.,<br>29 ст. 9 өл.<br>81 ст. 4 п. | Диләнке эшләре.<br>Агач материалы әзерләү.<br>Агач материалы әзерләү кагыйдәләре.<br>Урман утыртмаларын кисү тәртибе. | «Агач материалы әзерләү кагыйдәләрен һәм Россия Федерациясе Урман кодексының 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда, урман паркларында агач материалы әзерләү үзенчәлекләрен раслау турында» 2016 елның 13 сентябрендәге № 474 боерык<br>«Диләнке эшләре төрләрен, аларны уздыру тәртибен һәм эзлеклелеген, Диләнке эшләренең технологик картасы формасын, Диләнке карау акты формасын һәм Диләнке карау тәртибен раслау турында» 2016 елның 27 июнендәге № 367 боерык |
| 60.4 ст. | Урман яклау буенча районнарга бүленеш. | «Урман яклау буенча районнарга бүлү тәртибен раслау турында» 2017 елның 09 гыйнварындагы № 1 боерык |
| 91 ст. | Дәүләт урман реестры. | «Дәүләт урман реестрына документлаштырылган мәгълүматлар кертүгә һәм аны үзгәртүгә нигез булган документлар исемлеген, аларның формаларын һәм аларны әзерләү тәртибен раслау турында» 2013 елның 11 ноябрендәге № 496 боерык;<br>«Дәүләт урман реестрында булган, зарури тәртиптә бирелә торган мәгълүматлар төрләре исемлеген һәм аны бирү шартларын раслау турында» 2013 елның 30 октябрендәге № 464 боерык<br>«Дәүләт урман реестрын алып бару рәвешләрен раслау турында» 2016 елның 06 октябрендәге № 514 боерык |
| 70.1 ст. 12 өл. | Урман кишәрлекләрен проектлау. | «Урман кишәрлегенең проект документациясе составына һәм аның эчтәлегенә карата таләпләр, аны әзерләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 03 февралендәге № 54 боерык |
| 60.13 ст. | Урманнарны радиоактив пычранудан саклау үзенчәлекләре. | «Урманнарның радиоактив пычрану зоналарында профилактика һәм тернәкләндерү чараларын гамәлгә ашыру үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 ел, 08 июнь, № 283 боерык |
| 65 ст. 5 өл. | Урман орлыкчылыгы. | «Урман орлыкчылыгы объектларын төзү һәм аерып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 20 октябрендәге № 438 боерык;<br>«Урманның төп агач токымнарының урман |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | үсемлекләренең районнарга бүленгән орлыкларын куллану тәртибен раслау турында» 2015 елның 17 сентябрендәге № 400 боерык |
| 46 ст. 3 өл.; 81 ст. 13 п. | Урманнардан агач материалын һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдалану. Урманнардан агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләре. | «Урманнардан агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 01 декабрендәге № 528 боерык |
| 38 ст. | Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану. | «Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 21 июнендәге № 314 боерык |
| 49 ст. 3 өл.; 81 ст. 14 п. | Урманнардан файдалану турында хисап. Урманнардан файдалану турында хисап тапшыру тәртибе. | «Урманнардан файдалану турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнардан файдалану турында хисап тапшыру формасын һәм тәртибен, шулай ук урманнардан файдалану турында электрон рәвештә хисап формасына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 21 августындагы № 451 боерык |
| 66 ст. 2 өл., 81 ст. 25 п. | Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисап. Урманнардан файдалану һәм урман үрчетү турында хисап тапшыру тәртибе. | «Урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны торгызу һәм урман үрчетү турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урман торгызу һәм урман үрчетү турында электрон рәвештәге хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 21 августындагы № 452 боерык |
| 89 ст. | Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза. Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза тәртибе. | «Урманнарны үзләштерү проектына дәүләти һәм муниципаль экспертиза тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 сентябрендәге № 496 боерык |
| 26 ст. 3 өл. 81 ст. 3 п. | Урман декларациясе. Урман декларациясен тутыру һәм тапшыру тәртибе. | «Урман декларациясе формасын, аны тутыру һәм тапшыру тәртибен, электрон рәвештә урман декларациясе форматына таләпләр раслау турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы № 17 боерык |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 77 ст.;<br>81 ст. 31 п. | Урман утыртмаларын сату-алу турында шартнамә төзү.<br>Дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге җирләрдә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен әзерләү һәм төзү тәртибе. | «Дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттәге җирләрдә урнашкан урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсен әзерләү һәм төзү тәртибен раслау турында» 2015 елның 28 октябрендәге № 446 боерык |
| 73.1 ст. 6 өл.;<br>28 һәм 29 п.<br>81 ст. | Дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен төзү<br>Дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен әзерләү һәм төзү тәртибе | «Дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен әзерләү һәм төзү тәртибен раслау турында» 2015 елның 28 октябрендәге № 445 боерык |
| 60 ст. 3 өл.,<br>60.11 ст. 3 өл.;<br>81 ст. 20.1 п. | Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап.<br>Урманнарны янгыннардан саклау турында хисап тапшыру тәртибе.<br>Урманнарны яклау турында хисап.<br>Урманнарны яклау турында хисап тапшыру тәртибе. | «Урманнарны янгыннардан саклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны янгыннардан саклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны янгыннардан саклау турында электрон рәвештә хисап тапшыру форматына карата таләпләр, урманнарны яклау турында хисапка кертелә торган мәгълүматлар исемлеген, урманнарны яклау турында хисап формасын һәм аны тапшыру тәртибен, шулай ук урманнарны яклау турында электрон рәвештә хисап форматына карата таләпләр раслау турында» 2017 елның 09 мартындагы № 78 боерык |
| 60.8 ст. 3 өл.; | Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү. | «Зыянлы организмнарның чыганакларын юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2016 елның 23 июнендәге № 361 боерык |
| 53.4 ст. | Урман янгыннарын сүндерү. | «Урман янгыннарын сүндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 08 июлендәге № 313 боерык |
| 64.1 ст. 2 өл. | Урман торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман утыртмалары биләгән җирләргә кертү | «Урман торгызу өчен билгеләнгән җирләрне урман утыртмалары биләгән җирләргә кертү тәртибен һәм тиешле акт формасын раслау турында» 2014 елның 01 декабрендәге № 529 боерык |
| **Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы (алга таба – Рослесхоз) норматив актлары** | | |
| 88 ст. 2 өл., | Урманнарны үзләштерү | «Урманнарны үзләштерү проекты составын |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | проекты.<br>Урманнарны үзләштерү проектының составы һәм аны эшләү тәртибе. | һәм аны эшләү тәртибен раслау турында» 29.02.2012 ел, № 69 боерык |
| 104 ст. 2 өл.,<br>105 ст. 8 өл. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигый һәм башка объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнардан, кыйммәтле урманнардан, шулай ук махсус яклanучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, торгызу үзенчәлекләре. | «Су саклау зоналарында урнашкан урманнардан, табигый һәм башка объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнардан, кыйммәтле урманнардан, шулай ук махсус яклanучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңадан үстерү үзенчәлекләрен раслау турында» 14.12.2010 ел, № 485 боерык |
| 86 ст. 5 өл. | Россия Федерациясе субъектының урман планы.<br>Россия Федерациясе субъектының урман планы составы һәм аны әзерләү тәртибе. | «Россия Федерациясе субъекты урман планының типик формасын һәм составын, аны әзерләү тәртибен раслау турында» 2011 елның 05 октябрендәге № 423 боерык |
| 81 ст. | Урманнарны якланганлык категорияләре буенча аеру. | «ТР территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 елның 16 июнендәге № 232 боерык |
| 15 ст. 4 өл. | Урманнарны районнарга бүлү.<br>Урман утыртмалары кисентеләренең яшьләре. | «Кисентеләр яшен билгеләү турында» 2015 елның 09 апрелендәге № 105 боерык |
| 29 ст. 5 өл.<br>81 ст. 1 п. | Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибе. | «Файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләмен исәпләп чыгару тәртибен раслау турында турында» 2011 елның 27 маендагы № 191 боерык |
| 39.1 ст. | Урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү. | «Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 19 июлендәге № 308 боерык |
| 45 ст. | Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану. | «Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 10 июнендәге № 223 боерык |
| 43 ст. | Урманнардан җир асты байлыкларын геологик | «Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен файдалану. | өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 27 декабрендәге № 515 боерык |
| 31 ст. | Чәер әзерләү. | «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 24 гыйнварындагы № 23 боерык |
| 32 ст. | Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу. | «Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу турында» 2011 елның 05 декабрендәге № 512 боерык |
| 39 ст. | җимешле, җиләкле, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре үстерү. | «Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 05 декабрендәге № 510 боерык |
| 34 ст. | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю. | «Азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 05 декабрендәге № 511 боерык |
| 40 ст. | Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану. | «Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 елның 23 декабрендәге № 548 боерык |
| 41 ст. | Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану. | «Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 21 февралендәге № 62 боерык |
| 63 ст. 2 өл., 81 ст. 22 п. | Урман үрчетү. Урман үрчетү кагыйдәләре | «Урман үрчетү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 10 гыйнварындагы № 1 боерык |
| 29 ст. 6 өл. 81 ст. 2 п. | Агач материалы әзерләү. Агач материалын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеге | «Агач материалын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлеген раслау турында» 2011 елның 05 декабрендәге № 513 боерык |
| 53 ст. 4 өл.; 53.1 ст.; 81 ст. 16 п. | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы. Урман янгыннарын кисәтү. | «Урманнарны янгынга каршы кору нормативларын раслау турында» 2012 елның 27 апрелендәге № 174 боерык «Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясен һәм, һава торышына карап, урманнарда табигый янгын куркынычы классификациясен раслау турында» 2011 елның 05 июлендәге № 287 |

| РФ Урман кодексы статьясы | РФ Урман кодексында каралган | Норматив актлар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | боерык |
| 67 ст.;<br>68 ст. | Урманнарны тәртипкә китерү турында гомуми нигезләмәләр.<br>Урман корылышының эчтәлеге. | «Урман кору күрсәтмәсен раслау турында» 2011 елның 12 декабрендәге № 516 боерык |
| 65 ст. 2 өл. 1 п. | Урман орлыкчылыгы.<br>Урман орлыкчылыгы буенча районнарга бүленеш. | «Урман орлыкчылыгы буенча районнарга бүлүне билгеләү турында» 2015 ел, 08 октябрь, № 353 боерык |
| 23 ст. | Урманчылыклар һәм урман парклары | «Татарстан Республикасы территориясендә урманчылыклар санын ачыклау һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2008 елның 17 октябрендәге № 320 боерык |
| **Россия Федерациясе субъекты норматив актлары** | | |
| 82, 83 ст. | Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре.<br>Урман мөнәсәбәтләре өлкәсендә Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарының аерым вәкаләтләрен Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына тапшыру. | «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 елның 22 маендагы № 22-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы;<br>Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Урман планын раслау турында» 2009 елның 16 мартындагы № ПУ-146 указы;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2020 елларга Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 30 июлендәге № 531 карары;<br>Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының төбәк әһәмиятендәге уртак файдаланудагы автомобиль юллары һәм муниципаль берәмлекләр мөлкәтенә тапшырылырга тиешле, уртак файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген раслау турында» 2011 елның 26 сентябрендәге № 797 карары |
| | | Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында шәхси ихтыяҗлар өчен урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе буенча гражданнар өчен түләү ставкалары билгеләү турында» 2017 елның 27 февралендәге № 9-1/нпс карары. |

**Урман хуҗалыгы регламентын төзү өчен мәгълүмат базасы**

Урман хуҗалыгы регламентын эшләгәндә түбәндәгеләр файдаланылды:

1) 2014 елда «Рослесинфорг» ФДУП Пенза бүлеге уздырган урман корылышы материаллары;

2) урман хуҗалыгы регламентын эшләү буенча техник киңәшмәләрнең беркетмәләре;

3) җир корылышы материаллары;

4) Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы белән идарә итү органнарының ведомство һәм статистика хисаплылыгы;

5) РФ Юстиция министрлыгында теркәлгән норматив-хокукый актлар.

Материалларны РФ УК таләпләренә җавап бирә торган торышка китерү өчен түбәндәге эш төрләре башкарылды:

6) 2017 елның 01 гыйнварына урманчылык мәйданы билгеләнде;

7) кишәрлек урманчылыклары буенча урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре билгеләнде;

8) әзерлекләр күләме (файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләме), өлгергән һәм картайган утыртмаларны сайланма һәм тоташ кисүләрдә урманнардан рөхсәтле файдалану параметрлары һәм чорлары исәпләп чыгарылды;

9) урманнарны тәрбияләгәндә, санитар-савыктыру чаралары үткәргәндә урта яшьле, өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган утыртмаларны кискәндә әзерләнә торган агач материалы күләмнәре исәпләп чыгарылды;

10) урманнардан чәер әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары билгеләнде,

11) агач булмаган урман ресурслары әзерләү өчен урманнардан рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары;

12) азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен урманнардан рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары билгеләнде.

# 1. ГОМУМИ МӘГЪЛҮМАТЛАР

## 1.1. Урманчылыкка кыскача сыйфатлама

### 1.1.1. Урманчылыкның аталышы һәм урнашкан урыны

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының Лениногорск урманчылыгы (алга таба – Урманчылык) Рослесхозның «Татарстан Республикасы территориясендә урманчылыклар исәбен билгеләү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2008 ел, 17 октябрь, № 320 боерыгы нигезендә оештырылды. Урманчылык Татарстан Республикасының көньяк-көнчыгыш өлешендә Лениногорск һәм Бөгелмә муниципаль районнары территориясендә урнашкан.

Урманчылыкның конторасы Лениногорск шәһәрендә, ул республика башкаласы Казан ш. 340 чм һәм иң якын Бөгелмә тимер юл станциясеннән 30 чм ераклыкта урнашкан.

Урманчылыкның почта адресы: 423250, Татарстан Республикасы, Лениногорск ш., Чайковский ур., сәнәгать зонасы, Лениногорск урманчылыгы.

Телефон: 8 (85595) 2-60-58, E-mail: Leninogorskoe.Gku@tatar.ru

Урманчылык территориясенең төньяктан көньякка кадәрге озынлыгы – 57 чм, көнчыгыштан көнбатышка кадәр – 64 чм.

### 1.1.2. Урманчылыкның һәм кишәрлек урманчылыкларының гомуми мәйданы

2017 елның 01 гыйнварына булган мәгълүматларга караганда, Урманчылыкның урман фонды җирләренең гомуми мәйданы 52837 гектар тәшкил итә, шул исәптән киршәрлек урманчылыклары буенча:

Түбән Чыршылы – 11588 га;
Зәй-Каратай – 8902 га;
Иске Куак – 9106 га;
Шөгер – 10316 га;
Лениногорск – 12925 га.

### 1.1.2. Урманчылык территориясенең муниципаль берәмлекләр буенча бүленеше

Урманчылык территориясенең муниципаль берәмлекләр буенча бүленеше 1 таблицада китерелде.

1 таблица.

Урманчылык төзелеше

| № п/п | Кишәрлек урманчылыкларының атылышы | Административ район (муниципаль берәмлек) | Кварталлар исемлеге | Гомуми мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Зәй-Каратай | Лениногорск | 1-117 | 8902 |
| 2. | Лениногорск | Лениногорск | 1-161 | 11866 |
| | | Бөгелмә | | 1059 |
| | Кишәрлек урманчылыгы буенча җәмгысе | | | 12925 |
| 3. | Түбән Чыршылы | Лениногорск | 1-127 | 11588 |
| 4. | Иске Куак | Лениногорск | 1-113 | 9106 |
| 5. | Шөгер | Лениногорск | 1-142 | 10316 |
| | Урманчылык буенча барлыгы: | | 660 | 52837 |
| | шул исәптән районнар буенча: | Лениногорск | | 51778 |
| | | Бөгелмә | | 1059 |

Урманчылыкның урман фонды төньяктан Әлмәт урманчылыгы белән, төньяк-көнбатыштан – Кәләй урманчылыгы, көнбатыштан – Чирмешән урманчылыгы, көнчыгыштан – Бөгелмә урманчылыгы һәм көньяктан Самара өлкәсе белән чиктәш булып тора.

Урман биләмәләренең территориаль урнашуы, кишәрлек урманчылыкларының, торак пунктларының, кишәрлек урманчылыклары һәм урманчылыклар контораларының, транспорт юлларының һәм гидрографик челтәрләрнең чикләре, урманчылык кварталларының махсус саклanучы табигать территорияләре (МСТТ), махсус якланучы урман кишәрлекләре (МЯК) бүленеше тематик карталарда күрсәтелде.

Урманчылык территориясе бүлеп күрсәтелгән Татарстан Республикасы № 1 карта-схемада күрсәтелде.

# № 1 карта-схема

**СХЕМАТИЧЕСКАЯ КАРТА Республики Татарстан Лениногорское лесничество**




**Экспликация**

| № | Лесничества, ООПТ Федерального значения |
|---|---|
| 1 | Агрызское |
| 2 | Азнакаевское |
| 3 | Аксубаевское |
| 4 | Алькеевское |
| 5 | Альметьевское |
| 6 | Арское |
| 7 | Бавлинское |
| 8 | Билярское |
| 9 | Болгарское |
| 10 | Бугульминское |
| 11 | Буинское |
| 12 | Елабужское |
| 13 | Заинское |
| 14 | Зеленодольское |
| 15 | Ислейтарское |
| 16 | Кайбицкое |
| 17 | Калейкинское |
| 18 | Камское |
| 19 | Кзыл-Юлдузское |
| 20 | Лаишевское |
| 21 | Лениногорское |
| 22 | Мамадышское |
| 23 | Мензелинское |
| 24 | Нижнекамское |
| 25 | Нурлатское |
| 26 | Приволжское |
| 27 | Пригородное |
| 28 | Сабинское |
| 29 | Тетюшское |
| 30 | Черемшанское |
| 31 | Лубянское |
| 32 | ГПБЗ Волжско-Камский |
| 33 | НП Нижняя Кама |

**Условные обозначения**

- Граница субъекта РФ
- Граница лесничеств
- Кукмор — Населенные пункты районного значения
- Лесничество

## 1.1.3. Урманчылык урманнарының урман үсү зоналарына һәм урманлы районнарга бүленеше

РФ ТРЭМның «Россия Федерациясенең урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясенең урманлы районнары исемлеген раслау турында» 2014 ел, 18 август, № 367 боерыгы белән расланган урман үсү районнарына бүленеш нигезендә урманчылык территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала районына кертелгән (2 таблица).

2 таблица.

Урманчылык урманнарының урман үсү зоналарына, урманлы районнарга һәм урман яклау зоналарына һәм урман-орлык районнарына бүленеше

| № п/п | Кишәрлек урманчылыкларының атылышы | Урман үсә торган зоналар | Урманлы район | Урман яклау районнарына бүленеше | Урман-орлык буенча районнарга бүленеш зонасы | Урман кварталлары исемлеге | Мәйданы, га |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| 1. | Зәй-Каратай | | | | | 1 – 117 | 8902 |
| 2. | Лениногорск | | | | | 1 - 161 | 12925 |
| 3. | Түбән Чыршылы | Урман-дала зонасы | Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала районы | Урман патологиясе буенча уртача куркыныч | Нарат өчен – 3 чыршы – 4, имән-2. | 1 – 127 | 11588 |
| 4. | Иске Куак | | | | | 1 – 113 | 9106 |
| 5. | Шөгер | | | | | 1 - 142 | 10316 |
| | | | ҖӘМГЫСЕ: | | | | 52837 |

Урманчылык территориясенең һәм кишәрлек урманчылыкларының урман үсү районнарына һәм урманлы районнарга бүленеше № 2 карта-схемада күрсәтелде.

# Карта-схема № 2



## 1.1.4. Урманчылык урманнарының кварталлар яисә аларның өлешләре буенча максатчан билгеләнеше һәм яклаучы урман категорияләре буенча бүленеше, шулай ук яклаучы, эксплуатация һәм резерв урманнарын бүлеп чыгару нигезләре

3 таблица.

Урманнарның максатчан билгеләнеше һәм яклаучы урман категорияләре буенча бүленеше

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Барлыгы урманнар | | | 52837 | |
| Яклаучы урманнар, барлыгы | | | 23819 | |
| Махсус саклануча табигать территорияләрендә урнашкан урманнар | Лениногорск | Квартал өлешләре: 112,113 | 181 | |
| | Шөгер | Кварталлар: 60,61 | 111 | |
| | Барлыгы: | | 292 | |
| Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Зәй-Каратай | 116 квартал Квартал өлешләре: 2, 4, 16, 19- 21, 26, 48, 50-52, 54-57, 59, 63-65, 79-81, 83, 89, 91, 92-96, 98, 99, 102, 110, 112, 113, 115, 117 | 323 | РФ Урман кодексы, РФ Су кодексы, 2006 ел, 4 декабрь, № 201-ФЗ федераль закон, «Татарстан Республикасы территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатацияләү урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 ел, 16 июнь, № 232 Рослесхоз боерыгы, 2011 ел, 12 декабрь, № 516 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманкору инструкциясе |
| | Лениногорск | квартал өлешләре:1, 3-7, 9-14, 20, 25, 28, 45, 67, 72, 74, 76, 78 , 79, 80, 104, 105, 110, 112-117,119, 121, 123-125,134-136, 139-141, 146- 154,156,158,160 | 618 | |
| | Түбән Чыршылы | Квартал өлешләре: 1,2, 5-7, 106-109,114,116, 117,122,124 | 122 | |
| | Иске Куак | Квартал өлешләре:2,3,4, 19,21,33, 40, 42, 50, 59,66,81, 104,105,109,110 | 200 | |
| | Шөгер | Квартал өлешләре: 5,7,8,9,10,12,13, 17-20,22,24-26, 28,29,38,39, 42,46,50, 51, 99, 111, 129,137,138 | 212 | |
| | Барлыгы: | | 1475 | |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| Табигый һәм бүтән объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнар, барлыгы | | | 9099 | 2006 ел, 4 декабрь, № 201-ФЗ федераль закон, 1990 ел, 14 апрель, № 90 Гослесхоз боерыгы |
| дәвалау-савыктыру җирлекләренең һәм курортларның санитар (тау-санитар) саклык округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында урнашкан урманнар | Иске Куак | Кварталлар: 47, 48, 67,68, 70, 72, 74-77, 79-80,82-85,87,89,91, 94-98, 106, 108 ,111, 112<br>Квартал өлешләре: 69,81,86,88, 90,92, 93,99,105,109,110 | 2745 | |
| | Шөгер | Квартал өлешләре: 5, 7, 13, 31, 38,39, 40, 49, 54, 56<br>Кварталлар: 32 | 552 | |
| | Барлыгы | | 3297 | |
| Россия Федерациясе субъектлары милегендә булган, гомуми файдаланудагы тимер юллар, гомуми файдаланудагы федераль автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйларында урнашкан яклаучы урман полосалары | Зәй-Каратай | Квартал өлешләре: 30,33, 35, 36,39,40, 42-44, 48-50, 53-54, 56-59, 61-65, 78-80, 82, 83, 92,93,95,97, 99, 100-102, 108, 111, 113,115 | 455 | РФ Урман кодексы, 2006 ел, 04 декабрь, 201-ФЗ номерлы федераль закон, 2010 ел, 16 июнь, 232 номерлы Рослесхоз боерыгы, 2011 ел, 12 декабрь, 516 номерлы Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнарны тәртипкә китерү инструкциясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ведомство автомобиль юлларын Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары челтәренә кертүне исәпкә алып, Татарстан Республикасының гомуми файдаланудагы автомобиль юллары исемлеген раслау турында» 2011 ел, 12 декабрь, 516 номерлы карары |
| | Лениногорск | Квартал өлешләре: 2, 8, 13, 22-24, 31, 61,62, 68,76, 78, 88, 94, 95, 102- 105, 110, 113, 114,116, 119, 127,136, 138, 141,142,146, 147, 150- 154, 156, 158<br>Кварталлар: 69, 70, 77, 89, 90, 122, 155, 159 | 1372 | |
| | Түбән Чыршылы | Квартал өлешләре: 21-23, 25-27, 29-30, 33-34, 37, 57, 66, 68-70, 81,83-84, 110,113,116,124 | 487 | |
| | Иске Куак | Квартал өлешләре: 1, 10,11,18,20,21,26, 29-31, 37- 39, 56, 57, 60, 61, 63,69,86, 88,90,92,93,99,100, 109,110 | 511 | |
| | Шөгер | Квартал өлешләре: 2,3,5,6, 8,14, 28,31, 39, 40,41, 45,48,49, 50, 53,54, 55,56, 62, 63, 80 | 249 | |
| | Барлыгы: | | 3074 | |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | | | |
| Урман-парк зоналары | Лениногорск | Кварталлар: 16,17,29, 30,37- 41, 49<br>Квартал өлешләре: 8,18,.19,31, 52-54,137 | 988 | 2006 ел, 4 декабрь, № 201-ФЗ федераль закон, ТР Министрлар Кабинетының 2011 ел, 18 апрель, № 543-р боерыгы, ТР Министрлар Кабинетының 2011 ел, 4 май, № 669-р боерыгы |
| | Барлыгы: | | 988 | |
| Яшел зоналар | Зәй-Каратай | Кварталлар: 66-77, 104-105 | 1102 | 2006 ел, 4 декабрь, № 201-ФЗ федераль закон, 1993 ел, 22 июнь, № 168 Рослесхоз боерыгы |
| | Лениногорск | Кварталлар: 32, 57, 58, 59, 63, кв. өлешләре: 8, 18,19, 31,52, 53, 54, 61, 137, 138, 139 | 638 | |
| | Барлыгы: | | 1740 | |
| Кыйммәтле урманнар, барлыгы: | | | 12953 | |
| эрозиягә каршы урманнар | Зәй-Каратай | Кварталлар: 27 - 29, 37, 38, 41 , 45, 46 квартал өлешләре: 30, 35, 39, 40,42-44, 78-80, 82,83,99 | 1513 | РФ Урман кодексы, 2006 ел, 4 декабрь, № 201-ФЗ федераль закон, «ТР территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» 2010 ел, 16 июнь, № 232 Рослесхоз боерыгы |
| | Шөгер | квартал өлеше: 137 | 36 | |
| | Барлыгы: | | 1549 | |
| далаларда, ярымдала, урман даласы, урман-тундра зоналарында, чүлләрдә, тауларда урнашкан урманнар | Зәй-Каратай | Кварталлар: 23-25,31, 32, 34, 47, 103, 106, 107,109,114<br>Квартал өлешләре: 26,33, 36,56,61-65, 81,93-98,100- 102, 108, 110-113, 115,117 | 1487 | 2006 ел, 4 декабрь, № 201-ФЗ федераль закон, «ТР территориясендә урманнарны кыйммәтле, эксплуатация урманнарына кертү һәм аларның чикләрен билгеләү турында» |
| | Лениногорск | Кварталлар: 15, 21, 26,27, 33-36, 42-44, 46-48, 50, 51, 55, 56, 60, 71, 106, 118, 120, | 5495 | |

| Урманнарның максатчан билгеләнеше | Кишәрлек урманчылыгы | Кварталларның яки өлешләренең номерлары | Мәйданы, га | Урманнарны максатчан билгеләнеше буенча бүлү нигезләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | | 126,128-133, 143-145,157,161 Квартал өлешләре: 1-7,9- 14, 20, 22-25,28, 45, 62, 68, 72, 104, 114,115,117, 119, 121,123-125,127,134-136, 138-142,146-153, 156,158,160 | | 2010 ел, 16 июнь, № 232 Рослесхоз боерыгы, ТР Министрлар Кабинетының 2011 ел, 18 апрель, № 543-р боерыгы |
| | Түбән Чыршылы | Кварталлар: 3,4,8-17, 85,99,100,105,111, 112,115 Квартал өлешләре: 1,2,5,6,7, 106-110, 113,114, 116,117 | 1657 | |
| | Иске Куак | Кварталлар: 5, 12-17, 22-25,27,28, 32, 53, 54, 71, 73, 101-103, 107, 113 Квартал өлешләре: 1-4,11,18-21,26,29-31, 59, 100, 104 | 1714 | |
| | Шөгер | Кварталлар: 1 , 4, 11, 15,16,21,23,27,30, 89, 117-120,124, 139-142 Квартал өлешләре: 2,3,6,8,9, 10,12,14, 17-20,22, 24-26, 28,29,138 | 1051 | |
| | Барлыгы | | 11404 | |
| Эксплуатация урманнары | Зәй-Каратай | Кварталлар: 1,35, 6-15, 17 -18,22, 60, 84-88, 90 Квартал өлешләре: 2,4, 16, 19-21, 48- 55, 57-59, 89, 91, 92 | 4022 | РФ Урман кодексы, 2006 ел, 4 декабрь, № 201-ФЗ федераль закон, 2010 ел, 16 июнь, № 232 Рослесхоз боерыгы |
| | Лениногорск | Кварталлар: 64-66, 73, 75, 81-87, 91-93, 96-101, 107-109, 111 Квартал өлешләре: 67,74,76, 78-80, 88, 94- 95, 102, 103, 110, 112, 113 | 3633 | |
| | Түбән Чыршылы | Кварталлар: 18-20, 24, 28, 31, 32, 35 , 36, 38-56, 58-65, 67, 71-80,82, 86- 98, 101-104, 118-121, 123,125-127, квартал өлешләре: 21-23, 25-27, 29, 30, 33, 34, 37, 57, 66, | 9322 | |

| | Орлыклык имән, корычагач | Барысы да | 121-140 |
| | Үсентеле имән | III һәм югарырак | 71-80 |
| | | IV һәм түбәнрәк | 61-70 |
| | Карама, өрәңге | Барысы да | 71-80 |
| | Йомшак яфраклылар | | |
| | Бал бирүче (нектарлы) юкә | Барысы да | 81-90 |
| | Каен, кара зирек, юкә (товарлык), | Барысы да | 71-80 |
| | Усак, тирәк, кара тирәк, соры зирек, агачсыман тал | Барысы да | 51-60 |
| | Тирәк (культуралар) | Барысы да | 36-40 |
| | Куаклыклар | | |
| | Таллык | Барысы да | 5 |
| Яклаучы урманнар (Су объектлары буйларында урнашкан тыюлыклы урман полосалары), эксплуатация урманнары. | ылыслы | | |
| | Нарат, чыршы, карагач | Барысы да | 81-100 |
| | Каты яфраклылар | | |
| | Орлыклык имән, корычагач | Барысы да | 101-120 |
| | Үсентеле имән | III һәм югарырак | 61-70 |
| | | IV һәм түбәнрәк | 51-60 |
| | Карама, өрәңге | Барысы да | 61-70 |
| | Йомшак яфраклылар | | |
| | Бал бирүче (нектарлы) юкә | Барысы да | 81-90 |
| | Каен, кара зирек, юкә (товарлык) | Барысы да | 61-70 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Усак, тирәк, кара тирәк, соры зирек, агачсыман тал | Барысы да | 41-50 |
| | Тирәк (культуралар) | Барысы да | 31-35 |
| | Куаклыклар | | |
| | Таллык | Барысы да | 5 |

### 2.1.5. Агачлыкларның тулылыгын һәм составын, диләнкеләрнең күләмнәрен, диләнкеләрнең тоташу чорларын, киртекләр санын, кисүләрнең кабатлану чорларын исәпкә алып, агач материалын сайлау проценты (ешлыгы)

Агач материалы әзерләүгә карата таләпләр РФ УК 23 ст. күрсәтелгән урманчылыкларда, урман паркларында агач материалы әзерләү үзенчәлекләре РФ ТРЭМның 2016 ел, 13 сентябрь, № 474 боерыгы, «Диләнке эшләре төрләрен, аларны уздыру тәртибен һәм эзлеклелеген, диләнке эшләренең технологик картасы формасын, диләнкене карау акты формасын һәм диләнкене карау тәртибен раслау турында» 2016 ел, 27 июнь, № 367 боерыгы белән расланган Агач материалы әзерләү кагыйдәләрендә билгеләнгән.

Өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисү буенча төп оештыру-техник элементларның параметрлары 10.1 таблицада китерелде.

10.1 таблица

Өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисүләрдә төп оештыру-техник элемент параметрлары

| № п/п | Агач материалы әзерләү параметрлары. Кисү ысуллары | сайланма кисүләр | Тоташ кисүләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Урман үсемлекләре зонасы: Урман-дала зонасы<br>Урманлы район: Россия Федерациясе Европа өлеше Урман-дала районы | | | |
| 1. | **Сайланма кисүләр ешлыгы, %**<br>Бик зәгыйфь<br>Зәгыйфь<br>Уртача<br>Уртача-югары<br>Югары<br>Бик югары (сайланма санитар кисүләр өчен) | <br>10 кадәр<br>11-20<br>21-30<br>31-40<br>41-50<br>51-70 | |

| № п/п | Агач материалы әзерләү параметрлары. Кисү ысуллары | сайланма кисүләр | Тоташ кисүләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Урман үсемлекләре зонасы: Урман-дала зонасы<br>Урманлы район: Россия Федерациясе Европа өлеше Урман-дала районы | | | |
| 2. | **Диләнкеләрнең (сайланма кисүләрдә) чик мәйданы, га**<br>Яклаучы урманнар:<br>Ирекле-сайланма кисүләр<br>Төркемле-сайланма кисүләр<br>Тигез-эзлекле кисүләр<br>Төркемле-эзлекле кисүләр<br>Полоса аша эзлекле кисүләр<br>Эксплуатация урманнары:<br>Ирекле-сайланма кисүләр<br>Төркемле-сайланма кисүләр<br>Тигез-эзлекле кисүләр<br>Төркемле-эзлекле кисүләр<br>Полоса аша эзлекле кисүләр | <br><br><br>25<br>15<br>15<br>10<br>5<br><br>50<br>30<br>30<br>25<br>15 | |
| 3. | **Тоташ кисүләрдә диләнкеләрнең чик мәйданы, га**<br>нарат, карагач<br>Чыршы, пихта<br>орлыктан яңартылганда имән<br>шытымнан яңартылганда имән һәм башка каты яфраклылар<br>йомшак яфраклылар | | <br>5<br>5<br>2,5<br>10<br>10 |
| 4. | **Тоташ кисүләрдә диләнкеләрнең чик киңлеге, м**<br>нарат, карагач<br>Чыршы, пихта<br>орлыктан яңартылганда имән<br>шытымнан яңартылганда имән һәм башка каты яфраклылар<br>йомшак яфраклылар | | <br>50<br>50<br>50<br>100<br>100 |
| 5. | **Диләнкеләр тоташу чоры, ел**<br>нарат, карагач<br>Чыршы, пихта<br>орлыктан яңартылганда имән<br>шытымнан яңартылганда имән һәм башка каты яфраклылар<br>йомшак яфраклылар | | <br>4<br>4<br>4<br>4<br>2 |
| 6. | **Кисүләр кабатлану чоры, ел**<br>Ирекле-сайланма кисүләр<br>Төркемле-сайланма кисүләр<br>Тигез-эзлекле кисүләр<br>Төркемле-эзлекле кисүләр<br>Полоса аша эзлекле кисүләр | <br>8-30<br>8-30<br>4-8<br>30-40<br>4-8 | |

| № п/п | Агач материалы әзерләү параметрлары. Кисү ысуллары | сайланма кисүләр | Тоташ кисүләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Урман үсемлекләре зонасы: Урман-дала зонасы<br>Урманлы район: Россия Федерациясе Европа өлеше Урман-дала районы | | | |
| 7. | **Урман кварталының 1 км ягына хисаплаганда киртекләр саны**<br>диләнкеләр киңлеге (озынлыгы) 50 м кадәр булганда<br>диләнкеләр киңлеге (озынлыгы) 51-150 м булганда<br>диләнкеләр киңлеге (озынлыгы) 151-250 м булганда<br>диләнкеләр киңлеге (озынлыгы) 250 м артыграк булганда | | 4тән артык түгел<br>3тән артык түгел<br>2дән артык түгел<br>1 |
| 8. | **Төяү пунктлары, җитештерү һәм көнкүреш объектлары өчен гомуми мәйдан (диләнкенең гомуми мәйданыннан)**<br>- алга таба ясалма урман торгызып<br>Мәйданы 10 га артык булган диләнкеләрдә<br>- сезонара агач материалы запаслары булдыру өчен<br>- туфракка зыян салып<br>Мәйданы 10 га һәм аннан азрак булган диләнкеләрдә:<br>- алга таба яңартып<br>- алдан торгызып<br>- эзлекле кисүләрдә<br>- сайланма кисүләрдә | 3% артык түгел<br><br>0,3 га кадәр<br>0,25 га кадәр | чикләнми<br>5% артык түгел<br>15% артык түгел<br>иң күбе 3%<br><br>0,4 га кадәр<br>0,3 га кадәр |
| 9. | **Сөйрәмә җир трассалары һәм диләнкедәге юллар мәйданы, (диләнке мәйданыннан %)**<br>- күп операцияле техника кулланып<br>- алга таба ясалма урман торгызып | 15% артык түгел | 20% артык түгел<br>30% кадәр<br>чикләнми |

Өлгереп җитмәгән урман утыртмалары арасында урнашкан, диләнкеләрнең билгеләнгән күләмнәрен 1,5 мәртәбәдән кимрәк дәрәҗәдә артып китүче урмантаксалы бүлендекләр тулысынча кисүгә билгеләнә.

Урманнардан рациональ файдалануны, урман утыртмаларының үзләренең тирәлек хасил итүче, су саклаучы, санитария-гигиена, савыктыру һәм башка төрле файдалы үзлекләрен югалта башлаган табигый структурасын торгызу һәм саклау максатларында, – агач материалы әзерләү өчен аренда яисә даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукларында тапшырылган урман кишәрлекләрендә аерым диләнкеләрнең мәйданнары тоташ кисүләрдә арттырылырга мөмкин, ләкин 1,5 мәртәбәдән артыграк түгел.

Барлык урманнарда да тоташ кисүләрдә кыска ягы буйлап та, озын ягы буйлап та диләнкеләр өчен турыдан-туры тоташу урыны билгеләнә, ә елга

үзәннәрендә үсә торган урманнарда, – диләнкеләрнең полоса аша тоташу урыннары.

Турыдан-туры тоташкан очракта чираттагы диләнке алдагы диләнкедән соң тоташу срогын исәпкә алып киселә.

Полоса аша тоташкан очракта чираттагы диләнке диләнкеләрнең чик дәрәҗәдәге киңлегенә тигез булган киңлектәге урман полосасы аша урнаштырыла.

Тоташ кисүләрдә диләнкеләрнең тоташу срогы, кисү елларын санамыйча, агач токымнарының җимеш бирү ешлыгын исәпкә алып, аларның табигый рәвештә уңышлы гына яңаруын тәэмин итеп яки урман культуралары утырту, урманнарның экологик үзлекләрен саклау өчен шартлар тудырып билгеләнә.

Диләнкедә урманнарны ясалма торгызган вакытта яисә хуҗалык буенча кыйммәтле токымнарның шытымын саклаганда диләнкенең теләсә кайсы ягы буйлап тоташу вакытын кимендә 2 ел итеп билгеләү рөхсәт ителә.

Өлгергән, картайган урман утыртмаларын сайланма кискән вакытта диләнкеләрнең тоташу чорлары билгеләнми.

Өлгергән, картайган урман утыртмаларын сайланма кискән вакытта диләнкеләр 30 процентлы ешлык белән тоташканда һәм аларның өлгергән, картайган урман утыртмаларын тоташ кисү диләнкеләренә аннан да югарырак процентлы ешлык белән тоташуы очрагында өлгергән, картайган урман утыртмаларын тоташ кискәндәге кебек тоташу чорлары билгеләнә.

Өлгергән, картайган урман агачларын кискәндә агач материалын әзерләү диләнкеләрнең тоташу киңлеген, мәйданын һәм срокларын саклап гамәлгә ашырыла.

## 2.1.6. Урман торгызу методлары

10.2 таблица.

Урман типлары һәм урман торгызу ысуллары

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Ирекле утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Нарат өстенлек итүче урман типлары<br>1 төркем. Лишайниклы-мүкле наратлыклар | | | | | | | | | | | |
| 1. | Наратлык Лишайник-лы-мүкле Лм белән ТУМ: А1-2 Бонитеты: 1-3 Коры наратлык | 10С +Б | Аз калкулыклы яисә дулкынлы Коры (калкулыкларда) белән сафның (калкулык битендә) чиратлашуы | Аз күләмдә көлсу, комлы коры. Гориз. А1 юк | Наратлы сирәк | Сирәк: миләш, өянкелек | Песи тәпие, сирәк нарат җиләге һәм турак уты, Маршалл кукчәчәге, агулы сәхрә борычы, түбәнлекләрдә яшел мүкләр, дарулык бөре җиләге | Лишайник Кладония ыру Кладония | Нарат катнашындагы каеннар аз үсә | Хасил булмый | Тоташ кисүләр. Нарат культуралары |
| 2 төркем. Яшел мүкле нарат урманнары | | | | | | | | | | | |
| 2. | Наратлык мүкле (нарат җиләклеге) Мүк белән ТУМ: А2,В2 Бонитеты: 1-2 Саф наратлык | 10С + Б 9С 1Б +Ос, чыршы таралган җирдә 8С2Е | Биег. плато Рельефы тигез яисә аз гына дулкынлы, болын өсте террасалары | Өлешчә көлсу, комсыл саф туфрак – тирән комнар | Наратлы төркемле яраклашкан тәрәзәләргә сирәк чыршы | Сирәк – миләш, буяу куагы, ар-тыш, өянкелек | Нарат җиләге, ландыш, дарулык бөре җиләге, кара абага, аралыкларда һәм аланлыкларда чәчбай | Яшел мүкләр, калкулыкларда лишайниклар | Канәгатьләндерерлек, каен, усак, нарат белән | каенлы | Шытымны саклап, тоташ кисүләр. Тәрәзәләрдә нарат культуралары |
| 3. | Наратлык каражиләклек | 7С 2Б1Е + Ос | Яссылыклы яисә өлешчә дулкынлы | Урт. һәм куе көлсу комсыл | Чыршылы, сирәгрәк | Эт шомырты, куаклы тал, | Каражиләк, кара абага, | Яшел мүкләр, | Канә-гать- | Каенлы, сирәк усак | Шытымны саклап, тоташ кисүләр. |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Ирекле утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | Кж белән ТУМ: А3,В3 Бонитет:1- 2 (3) | | рельеф, елга террасалары | дымлы глей билгеләре белән | нарат | миләш, артыш | нарат җиләге, каеш яфрак, чәчбай | түбәнл. кәккүк җитене, | ләндерерлек, нарат, каен, усак белән | | Нарат культуралары |
| 3 төркем. Катлаулы нарат урманнары | | | | | | | | | | | |
| 4. | Куаклы наратлыклар Кн ТУМ:С2 Бонитеты:1-1а | 9С 1Б +Ос | Тигез калку плато, өске һәм болын өсте террасалары | Кәсле-көлсу җиңелчә балчыксыл сыл саф | Сирәк, нарат | Юкә, төрле-төрле куаклыклар, кабар агачы, зелпе, миләш | Сәрдә, күкебаш, keлəнчел, каеш яфрак, кара абага, кызыл бөрлегән, ике яфраклы май чәчәге, талакдар | Юк | Канәгатьләндерерлек, каен, усак һәм юкә катнашуы белән | Каенлы усаклы | Тоташ кисүләр. Нарат культуралары |
| 5. | Юкәле наратлык Ю белән ТУМ: С2-3 Бонитеты: 1а (еш кына культуралар) | 9С 1Б + Ос,Лп | Тигез калку плато, болын өсте террасалары | Кәсле-көлсу комсыл саф | Сирәк чыршылы | Урт. куелыкта яисә юкә күп булган куе, аз күләмле зелпеле, миләшле, эт шомыртлы | Төрле-төрле: күрәннәр, сәрдә, йолдызак, карга күзе, таштояк һәм башкалар | Юк | Йомшак яфраклыларга алмашынып | Каенлы усак-лы | Тоташ кисүләр. Нарат, чыршы культуралары |
| 6. | Наратлык чыршылы Се ТУМ: С2-3 Бонитеты: 1б | 10 С | Плато, тигез рельеф яисә сөзәк ярлар | Көлсу комсыл яисә җиңелчә балчыксыл саф һәм дымлы | Куе чыршылы | Сирәк юкә, өрәңге | Сәрдә, келәнчел, каеш яфрак, кызыл бөрлегән, аконит, җилдәк, күп чәчәкле бүре җиләге | Юк | Чыршыга алмашынып | чыршылы | Эзлекле кисүләр. Үсенте булмаганда – тоташ кисүләр һәм чыршы культуралары |
| 7. | Чикләвек куаклы наратлык СЛЩ | 10С +Д,Лп | Субүләр калкулыклары | Соры урман балчыксыл саф | Сирәк наратлы, имәнле | Куе – чикләвек куагы, миләш | Куе: Сәрдә, урман тугае, каеш яфрак, бөрлегән, | Юк | Яфраклыларга алмашынып яисә | Өрәңгеле, юкәле | Тоташ кисүләр. Имән культуралары |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы |  | Яңарышы | Ирекле утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
|  |  |  |  |  |  |  | Үләнле | Мүкле |  |  |  |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|  | ТУМ: Д2-3 Бонитеты: 1а |  |  |  |  |  | җилдәк, карга күзе |  | чикләвек куагы үсә башлый |  |  |
| 8. | Өрәңгеле наратлык СКЛ ТУМ: Д1 Бонитеты: 2-3 | 9С1Б +Кл | Субүләрләрнең текә ярлары, текә ерганаклы елга ярлары һәм чокыр сөзклекләре | Кәсле-карбонатлы азкуәтле коры | Сирәк имәнле | Урт. куелыкта: чикләвек куагы, кабар агачы | Чәчле күрән, Сәрдә, күкебаш, кызыл бөрлегән, аралыкларда бөртекләләр | Юк | Яфраклыларга алмашынып | Өрәңгеле, юкәле | Тоташ кисүләр. Имән культуралары |
| Искәрмә: Яфраклы утыртмаларның урман типлары С эндификаторы белән наратлы урман типларына карата тасвирлана (мисал өчен, куаклы карагай һ.б.) |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |
| Чыршы өстенлек итүче урман типлары |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |  |
| 9. | Чыршы урманы кымызлыклы Ч к ТУМ: С2 Бонитеты: 1 | 5Е1П 2С 1Лп 1Б +Ос | Субүләрләрдәге таулар һәм сөзәклекләр. | Уртача көлсу балчыксыл саф балчык түшәмәле | Сирәк чыршылы пихта катыш | Уртача куелыкта: юкә, миләш, зелпе, кабар агачы | Кымызлык, май чәчәге, урман наратбашы, талакдар, таштояк, каеш яфрак, икеөйле кычыткан | Сирәк - яшел мүкләр | Канәгатьләндерерлек, йомшак яфраклыларга алмашынып, кайчак шытым хисабына – чыршы белән | Каенлы усаклы | Эзлекле кисүләр. Үсенте булмаганда – тоташ кисүләр һәм чыршы культуралары |
| 10. | Чыршы урманы юкәле Ч юк ТУМ: С2-3 Бонитеты: 1 | 6Е1П 2Лп1Б +Ос | Тигез, өлешчә Таулы, сөзәклекләр | Уртача һәм бик аз күләмдә көлсу, балчыксыл саф | Төркем-ле, чыршы, пихта, юкә | Уртача куелыкта яки куе – юкә, миләш, зелпе, эт шомырты, кабар агачы, | Куе: сәрдә, сырмавык, күкебаш, таштояк, наратбаш, каеш яфрак, абага, кычыткан, келәнчел | Юк яки аз беленә үскән яшел мүкләр | Канәгатьләндерерлек гадәттә усакка алмашынып сирәк кенә юкәгә | Усаклы каенлы, юкәле | Эзлекле кисүләр. Үсенте булмаганда – тоташ кисүләр һәм чыршы культуралары |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Ирекле утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 11. | Чыршы урманы Елга буенда үсә торган (лог) Епр ТУМ: С3 Бонитеты: 2 Начар туфракта үсә торган дымлы чыршы урманы | 6Е1П2Б 1Ол | Елга, агымсу аша дымлана торган елгачык буйлары | Кәсле-көлсу, торфлы-глейлы, балчыксыл яки комсыл дымлы | Сирәк: Чыршы, пихта | Урт. куелыкта – шомырт, кара карлыган, миләш, юкә | Мул, тубылгы өстенлек итә, кычыткан, абага, сирәгрәк сәрдә, урман наратбашы, зеленчук, бохар кынасы, аю табаны, | Юк яки аз үскән, кәккүк житене, сирәк сфагнум, калкулыкларда яшел мүкләр | Чыршы үрентеләре хисабына яки йомшак яфраклыларга алмашынып | Зирекле каенлы | Эзлекле кисүләр. Үсенте булмаганда – тоташ кисүләр һәм чыршы культуралары |
| 12. | Имәнле чыршы урманы И ч ТУМ: Д2-3 Бонитеты: 2 | 7Е1Д1Б 1Ос + Лп | Югарылыклы плато һәм беленер-беленмәс таулыклар | Уртача һәм аз гына көлсу балчыксыл саф | Сирәк: чыршы, имән | Куе, чикләвек куагы, зелпе, кабар, юкә | Киң яфраклы үләннәр | Юк | Канәгать. йом. яфр. алмашынып яки үренте хисабына | Каенлы усаклы | Тоташ кисүләр. Имән культуралары |
| Искәрмә: Пихта утыртмаларның урман типлары Е индификаторы белән наратлы урман типларына карата тасвирлана (мисал өчен, юкәле пихта урманы һ.б.) | | | | | | | | | | | |
| Имән өстенлек итүче урман типлары | | | | | | | | | | | |
| 1 төркем. Коры өрәңгеле имән урманнары | | | | | | | | | | | |
| 13. | Чиялекле имәнлек Ч им ТУМ: Д0-1 Бонитеты: 5 | 8Д 2Б яки 10Д +Кл | Сөзәк таулар, шәрә таш токымнары белән | Кәсле-карбонатлы азкуәтле коры | Юк | Дала чиясе | Уртача куелыкта каурыйлы кыска сабак, чәчле күрән, чәчбай | Юк | Имәнле үрентеле | Хасил булмый | Тоташ кисүләр табигый үстерү |
| 14. | Калкулыклы имәнлек | 10Д +Б яки 7Д3Б +Лп | Сөзәк таулар, яр кырыйлары. | Кәсле-карбонатлы | Юк | Сирәк: чикләвек | Уртача куелыкта каурыйлы кыска | Юк | Имәнле үрентеле | Хасил булмый | Тоташ кисүләр табигый үстерү |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Ирекле утырт малар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | К им<br>ТУМ: Д 1<br>Бонитеты: 4 | | Рельефы калкулыклы | азкуәтле коры | | куагы,<br>Дала чиясе | сабак, чәчле күрән, чәчбай, кызыл бөрлегән | | | | |
| 15 | Өрәңгеле-каенлы имәнлек<br>Им өрк<br>ТУМ: Д 1<br>Бонитет:3-4 | 7Д2КИВ1Лп<br>яки<br>7Д3Б +Лп | Калкулыклы, сөзәк ярлар | Кәсле-карбонатлы азкуәтле коры | Сирәк: Имән | Уртача куелыкта: чикләвек куагы, кабар агачы | Уртача куелыкта: сәрдә, кычыткан, күкебаш, ирләр абагасы | Юк | Канәгать. Имән шыт., каенлы | каенлы | Тоташ кисүләр табигый үстерү Тагын да тирәнрәк туфракларда имән культуралары |
| 2 төркем. Имәнлекләр саф өрәңгеле-юкәле | | | | | | | | | | | |
| 16. | Имәнлек өрәңгеле-юкәле (дала янәшәсендә үсә торган)<br>Дклп<br>ТУМ: Д2-3<br>Бонитеты: 1-2 | 6Д3КИВ1Лп<br>яки<br>6Д3Лп1КИВ | Югарылыклы субүләрләр һәм сөзәклекләр | Соры урман һәм кәсле-көлсу балчыксыл саф, балчык түшәлә торган | Сирәк яки урт. куелыкта, юкә, каен, имән, урыны-урыны белән өрәңге | Урт. куелыкта: миләш, чикләвек куагы, сөялле кабар агачы, юкә, шомырт | Сәрдә, йолдызак, таштояк, сырмавык, кыңгырау, ландыш, кашыклы абага, күкебаш | Юк | Яфраклы-ларга алмашынып | Лп, Кл, Ос, Б | Тоташ кисүләр Үрентеле хуж-та таб. үсеш. – үрентеле. Орлыклыда – имән культуралары |
| 17. | Күрәнле имәнлек<br>Күр им<br>ТУМ: Д2<br>Бонитеты: 3 | 6Д2Лп1Кл1Б +Ос | Таулы плато, сөзәклекләрнең өске өчтән бер өлеше | Соры урман өлешчә көлсу, балчыксыл саф | Сирәк: имән | Сирәк: юкә, чикләвек куагы, сөялле кабар агачы, зелпе | Куе: сәрдә, келәнчел, таштояк, йолдызак, сырмавык, күкебаш, чәчле күрән | Юк | Яфраклы-ларга алмашынып | Лп, Б, Кл | Тоташ кисүләр Үрентеле хуж-та таб. үсеш. – үрентеле. Орлыклыда – имән культуралары |
| 18. | Абагалы имәнлек<br>Аб им<br>ТУМ: Д3<br>Бонитеты: 1-2 | 6Д3КИВ1Лп<br>яки<br>1 ярус- 10Д<br>2 ярус- 10КИВ | Плато һәм сөзәклекләр | Соры урман уртача көлсу балчыксыл дымлы | Төркемле, сирәк: имән | Урт. куелыкта: чикләвек куагы, кабар агачы, | Куе: Абага, сәрдә, таштояк, сырмавык, кырлы борчак, кымызлык, | Юк | Яфраклы-ларга алмашынып | Лп, КИВ, Б | Тоташ кисүләр Үрентеле хуж-та таб. үсеш. – үрентеле. Орлыклыда – |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Ирекле утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | Дымлы имәнлек | | | | | балан, эт шомырты, шомырт | күкебаш, йолдызак, миләүшә, урман кысыр тигәнәге, икеөйле кычыткан | | | | имән культуралары |
| 3 төркем. Имәнлекләр дымлы тугайлы | | | | | | | | | | | |
| 19. | Тугайлы имәнлек Туг им ТУМ:С4,Д4 Бонитеты: 3 (2) | 7Д 3Б +Лп | Елга тугайлары, өлешчә таулы урын, ел саен су баса | Кәсле-болынлы балчыксыл-глейлы юеш | Сирәк: имән, өрәңге, юкә | Сирәк – эт шомырты, шомырт, тал, зелпе, гөлҗимеш карлыган | Күрәннәр, тубылгы, кычыткан, кара бөрлегән | Юк | Канәгатьләнде рдерлек, имән һәм йомшак яфраклы токымнарның шытымнары белән | Лп, КИВ, Б | Тоташ кисүләр Үрентеле хуж-та таб. үсеш. – үрентеле. Тирәк культуралары ихтимал |
| Корычагач өстенлек итүче урман типлары | | | | | | | | | | | |
| 20. | Өрәңгеле-юкәле корычагачлык Кор өрю ТУМ:Д2 Бонитеты: 2(1) | 7Яс1Лп2КИВ | Таулы плато | Куе-соры урман балчыксыл саф балчык түшәлә торган | Уртача куелыкта: имән, корычагач, юкә | Уртача куелыкта: чикләвек куагы, юкә, зелпе | Сәрдә, keләнчел, таштояк, йолдызак, сырмавык, ирләр абагасы, күкебаш | Юк | Яфраклыларга алмашынып | Лп, Кл, Ос, Б | Тоташ кисүләр Корычагач (имән) культуралары |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Ирекле утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | Кайбыч урманчылыгының көньяк-көнбатыш өлешендә очрый | | | | | | | | | | |
| Юкә өстенлек итүче урман типлары | | | | | | | | | | | |
| 1 төркем. Төрле яфраклы юкәлекләр | | | | | | | | | | | |
| 21. | Төрле үләнле юкәлек Лп тр, ТУМ: С2-3,Д2-3 Бонитеты: 2-3 | 6Лп2Д2КИВ +Б,Ос 7Лп2Е1Б +Д | Таулы плато, сөзәклекләр, шулай ук болын өсте террасалары | Куе-соры урман балчыксыл саф балчык түшәлә торган | Уртача куелыкта: имән, өрәңге, юкә. Урыны-урыны белән Ч, П | Уртача куелыкта: чикләвек куагы, юкә, зелпе, миләш, кабар агачы | Сәрдә, келәнчел, күкебаш, казаяксыман җилдәк, урман наратбашы, кара абага | Юк | Үрентеле юкә | Өрәңге, каен, усак | Тоташ кисүләр Табиг. үсеш. – үрентеле юкә, имән культурасы уңышсыз булганда |
| 2 төркем. Калкулыклы юкәлекләр | | | | | | | | | | | |
| 22. | Өрәңгеле юкәлеклек Өр юк ТУМ:Д1 Бонитеты:3(4) | 8Лп 2КИВ +Д | Таулы, калкулыклы, «сыртлы» таулар | Кәсле-карбонатлы азкуәтле коры | Уртача куелыкта: Д,КИВ | Уртача куелыкта: чикләвек куагы, юкә, зелпе, кабар агачы | Уртача куелыкта: куык абага, сәрдә, сырмавык | Юк | Үрентеле юкә | Өрәңге, каен, усак | Тоташ кисүләр Табиг. үсеш. – үрентеле юкә, имән культурасы уңышсыз булганда |
| Каен өстенлек итүче урман типлары | | | | | | | | | | | |
| 23. | Каенлык наратлы (нарат урманы) К нар, ТУМ: А2-3,В2-3 | 9Б 1С | Таулы, сөзәклекләр | Көлсу комсыл яисә җиңелчә балчыксыл саф һәм дымлы | Сирәк: нарат | Сирәк: өянкелек, миләш, буяу куагы | Урт. куелыкта: чәчбай, кара абага, нарат җиләге, май чәчәге, | Яшел мүк мендәрләре | Шытымлы каен | Хасил булмый | Тоташ кисүләр. Нарат культуралары |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Иректе утырт малар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | Бонитеты:2(3) | | | | | | | | | | |
| 24. | Күрәнле каенлык Күр к ТУМ:С2-3 Бонитеты: 1 | 7Б2Ос1С бер. Лп, Д | Таулы. Рлф. тигез | Соры урман балчыксыл саф балчык түшәлә торган | Сирәк: юкә | Сирәк: миләш, зелпе, кабар агачы | Чәчле күрән, ике яфраклы май чәчәге, тубылгы, кычыткан, наратбаш | Юк | Шытымлы каен | Усаклы | Тоташ кисүләр. Ылыслы культуралар |
| 25. | Сырламыклы усак-лык Сырк ТУМ:Д2-3 Бонитеты:1-1а | 9Б 1Ос +Д, КИВ | Таулы яссы | Куе-соры урман балчыксыл саф балчык түшәлә торган | Сирәк: имән, юкә | Сирәк: чикләвек куагы, миләш, зелпе, кабар агачы | Сырламык, чәчле күрән, ике яфраклы май чәчәге, тубылгы, кычыткан, наратбаш | Юк | Шытымлы каен | Усаклы | Тоташ кисүләр Табиг. үсеш. – үсентеле каен. Ч культуралары |
| 26. | Тубылгылы каенлык Бтв ТУМ:С3-4Д4 Бонитеты:2 | 7Б2Ол1Ос | Платога тозаклар, шулай ук елгалар буйлап уйсулыклар | Торфлы глейлы балчыксыл, ләмле-торфлы юеш | Юк | Сирәк: эт шомырты, куаклы тал | Тубылгы, кычыткан, хатын-кызлар абагасы, наратбаш | Юк | Шытымлы каен | Зирек ле | Тоташ кисүләр. Табиг. үсеш. – үрентеле каен |
| 27. | Өрәңгеле каенлык Өр клк ТУМ: Д1 Бонитеты:2(3) | 7Б2КИВ1Ос +Д | Таулы, рлф. калкулыклы, «сыртлы» таулар | Кәсле-карбонатлы азкуәтле коры | Сирәк: имән, өрәңге | Урт. куелыкта: чикләвек куагы, кабар | Куык абага, сәрдә, сырламык, плющсыман будра, күкебаш | Юк | Үренте ле каен, өрәңге белән | Өрәңгеле | Тоташ кисүләр Табиг. үсеш. - үрентеле Имән культуралары |
| Усак өстенлек итүче урман типлары | | | | | | | | | | | |
| 1 төркем. Төрле үләнле усаклыклар | | | | | | | | | | | |
| 28. | Күрәнле усак урманы Күр ус, ТУМ: В2-3, С2-3 Бонитеты: 1(2) | 7Ос2Б1С +Д 7Ос2Б1Лп | Таулы, тигез рельеф һәм сөзәклекләр | Соры урман балчыксыл саф балчыклар белән түшәлә торган | Сирәк: имән, өрәңге | Сирәк: миләш, зелпе, кабар агачы | Чәчле күрән, Сәрдә, сырламык, күкебаш, табак яфраклы | Юк | Усаклы үрентеле | Хасил булмый | Тоташ кисүләр. Табиг. үсеш.- бонитет 1 Ылыслы культуралар |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Ирекле утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | | | | | | | йолдызак | | | | |
| 29. | Сырламыклы усаклык (имәнле) Сыр ус ТУМ: Д2-3 Бонитеты:1-1а | 9Ос1Б +Лп, КИВ 8Ос1Лп1Д | Таулы, тигез рельеф һәм сөзәклекләр | Куе-соры урман балчыксыл саф балчык түшәлә торган | Сирәк: имән, өрәңге | Уртача куелыкта: чикләвек куагы, кабар агачы, миләш, зелпе | Сырмавык, сәрдә, күкебаш, йолдызак | Юк | Усаклы үрентеле | Хасил булмый | Тоташ кисүләр. Табигый үсеше үрентеле, И культурасы уңышсыз булганда |
| 2 төркем. Таулы усаклыклар | | | | | | | | | | | |
| 30. | Өрәңгеле усаклык Өр ус ТУМ: Д1 Бонитеты:2(3) | 8Ос1Кл1Лп | Таулы, рлф. калкулыклы, «сыртлы» таулар | Кәсле-карбонатлы азкуәтле коры | Сирәк: имән, өрәңге | Уртача куелыкта: чикләвек куагы, кабар агачы | Куык абага, сәрдә, сырламык, плющсыман будра, күкебаш | Юк | Усаклы үрентеле | Өрәң-геле | Тоташ кисүләр. Табиг. үсеш. үрентеле. Имән культуралары |
| Өрәңге, элмә, карама агачы өстенлек итүче урман типлары | | | | | | | | | | | |
| 1 төркем. Коры өрәңгеле имән урманнары | | | | | | | | | | | |
| 31. | Таулы өрәңгелек Т өр ТУМ: Д1 Бонитеты: 4(3) | 7Кл2В1Лп +Б | Таулы, рлф. калкулыклы, «сыртлы» таулар | Кәсле-карбонатлы азкуәтле коры | Сирәк: имән, өрәңге | Уртача куелыкта: чикләвек куагы, кабар агачы | Каурыйлы кыска сабак, чәчле күрән, кызыл бөрлегән, чәчбай | Юк | Үрентеле КИВ | Хасил булмый | Тоташ кисүләр. Табиг. үсеш. үрентеле, тагын да тирәнрәк туфракларда - И. культ. |
| 2 төркем. Саф өрәңгеле-юкәле имәнлекләр | | | | | | | | | | | |
| 32. | Имәнле өрәңгелек (төрле үләнле) | 6КИВ2Д2Лп | Таулы, тигез рельеф һәм сөзәклекләр | Куе-соры урман балчыксыл саф балчык түшәлә | Сирәк: имән, өрәңге | Уртача куелыкта: чикләвек | Сәрдә, келәнчел, таштояк, йолдызак, | Юк | КИВ үрентеле | Хасил булмый | Тоташ кисүләр Имән культуралары |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Ирекле утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| | Им өр<br>ТУМ: Д2-3<br>Бонитеты: 3 | | | торган | | куагы, кабар агачы, зелпе, шомырт | сырмавык, күкебаш, ирләр абагасы. | | | | |
| Карамалы төркем | | | | | | | | | | | |
| 33. | Тугай янәшәсендә үсә торган карамалык<br>Туг кар<br>ТУМ: Д4<br>Бонитеты: 3 | 7ВИ2Кл1Лп +Б | Түбәнлектә, хәзерге елга тугайлары | Торфлы глейлы балчыксыл, ләмле-торфлы юеш | Сирәк: Өрәңге | Кара җиләк, кара карлыган, шомырт | Тубылгы, кычыткан, күрәннәр, болын наратбашы | Юк | Үрентеле ВИК | Хасил булмый | Тоташ кисүләр. Тирәк культуралары |
| Зирек өстенлек итүче урман типлары | | | | | | | | | | | |
| Тубылгылы зиреклек төркеме | | | | | | | | | | | |
| 34. | Тубылгылы зирек урманы<br>Туб зир<br>ТУМ:В4,С4<br>Бонитеты:2(3) | 8Ол2Б ед. ВИ | Платога тозаклар, шулай ук су ага торган түбәнге урыннар | Торфлы глейлы комсыл ләмле - торфлы дымлы | Юк | Эт шомырты, куаклы тал, кара карлыган | Тубылгы, кычыткан, күрәннәр, болын наратбашы | Юк | Зирекле үрентеле | Хасил булмый | Тоташ кисүләр Табиг. үсеш.- үрентелеге зирек (Т культуралары) |
| Таллык, кара тирәк өстенлек итүче урман типлары | | | | | | | | | | | |
| Таллык төркеме | | | | | | | | | | | |
| 35. | Тугайлык таллыгы<br>Туг тал<br>ТУМ: В3-4<br>Бонитеты: 2-3 | 10 Тал (таллык) | Түбән. Хәзерге елга тугайлары | Торфлы глейлы комсыл ләмле - торфлы дымлы | Юк | Кара җиләк, кара карлыган | Тубылгы, кычыткан, күрәннәр, болын наратбашы | Юк | Канәгатьләндерерлек, шытымлы тал белән | Хасил булмый | Тоташ кисүләр. Табиг. үсеш.- үрентеле таллык белән |
| Кара тирәк төркеме | | | | | | | | | | | |

| № п/п | Урман тибы, үсеш алган урыны шартлары, бонитет классы | Утыртмаларның уртача составы | Рельефтагы торышы | Туфрагы | Шытымы | Вак агачлары | Туфрак өсте катламы | | Яңарышы | Иректе утыртмалар | Кисү ысулы урм. торгызу ысулы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | Үләнле | Мүкле | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| 36. | Тугайлыкта үсә торган кара тирәклек<br>Туг кт<br>(тирәк культуралары)<br>ТУМ: С4<br>Бонитеты: 1 | 10 Оск<br>(кара тирәк) | Түбән. Хәзерге елга тугайлары, елгаларның иске үзән төбе | Торфлы глейлы балчыксыл, ләмле-торфлы юеш | Юк | Гөлҗимеш, кара җиләк | Сирәк: болын үләннәре | Юк | Начар: Карама | Хасил булмый | Тоташ кисүләр. Тирәк культуралары |
| Искәрмә: Тирәк утыртмалары (культуралары) урман тибы кара тирәкле һәм усак типларына карата сурәтләнә | | | | | | | | | | | |

## 2.1.7. Урманнардан агач материалы әзерләү өчен файдалану чорлары һәм башка мәгълүматлар

Урман агачларын кисү, тарттыру, өлешчә эшкәртү, саклау, әзерләнгән агач материалын алып чыгу агач материалы әзерләү максатларында урман кишәрлегеннән файдаланучы зат тарафыннан урман декларациясе буенча декларацияләнә торган чор башланган датадан 12 ай эчендә гамәлгә ашырыла. Агач материалы урман агачларын сату-алу шартнамәсе яисә Россия Федерациясе Урман кодексының 19 статьясының 5 өлешендә күрсәтелгән контракт нигезендә әзерләнгән очракта, агачларны кисү, тарттыру, өлешчә эшкәртү, саклау, алып чыгу эшләре шартнамәдә яисә контрактта билгеләнгән срок эчендә тиешенчә гамәлгә ашырыла.

Урман утыртмаларын кисүнең, агач саклауның, тарттыруның, алып чыгуның әлеге пунктта күрсәтелгән вакытларын озынайту күрсәтелгән таләпләрне вакытында үтәүгә юл калдырмаган начар һава шартлары барлыкка килгән очракта рөхсәт ителә.

Урман агачларын, тарттыруның, өлешчә эшкәртүнең, саклауның, алып чыгуның вакытлары урманнан файдаланучы затның язмача гаризасы нигезендә, вәкаләтле орган тарафыннан иң күбе 12 айга арттырылырга мөмкин.

Урман агачларын кисү, тарттыру, өлешчә эшкәртү, саклау, алып чыгу срокларын үзгәртүгә рөхсәт язмача рәвештә диләнкенең (кишәрлек урманчылыгын, урман кварталы номерын, урман-таксация бүлемтеге номерын, диләнке номерын) урнашкан урынын, диләнкенең мәйданын, агач материалының күләмен һәм агачларны кисү, тарттыру, өлешчә эшкәртү, саклау, алып чыгу буенча билгеләнгән (озынайтылган) срокны (датаны) күрсәтеп бирелә.

Агач материалы әзерләгәндә:

а) елга һәм чишмә үзәннәрен сөйрәмә җир трассалары һәм урман юллары сыйфатында куллану рөхсәт ителми;

б) диләнкедән читтә, алар белән чиктәш булган 50 метрлы полосаларда урман утыртмаларын, үсемчелек катламын һәм туфракларны зарарлау, урманнарны сәнәгать һәм башка төрле калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;

в) юлларга, күперләргә, урман ызаннарына, киптерү челтәренә, юл, гидромелиоратив һәм башка төрле корылмаларга, елга һәм чишмә үзәннәренә зыян салу рөхсәт ителми;

г) аударылыган һәм асылынып төшкән, киселгән агачларны (киселгән һәм диләнкедә калдырылган агачларны исәпкә алып) калдыру, сакланырга тиешле яшь шытымны зарарлау яисә һәлак итү тыела.

д) чиктәш булып торучы, кварталлардагы, диләнкеләрдәге һәм башка баганаларны һәм тамгаларны юк итү тыела;

е) кисүгә тиешле булмаган һәм Россия Федерациясенең Агач материалы әзерләү кагыйдәләре һәм урман законнары нигезендә сакланырга тиешле

агачларны, шул исәптән орлык бирү чыганакларын һәм плюс агачларын кисү һәм зарарлау тыела;

ж) рөхсәт ителгән чоры (рөхсәт ителгән кичектереп тору чорын да исәпкә алып) тәмамлангач агач материалы әзерләү, шулай ук файдалану хокукы туктатылгач яисә тәмамлангач агач материалы әзерләү рөхсәт ителми;

з) билгеләнгән вакытына (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) алып чыгылмаган агачны диләнкедә калдыру рөхсәт ителми;

и) урман үзләштерү проектында яисә диләнке ясауның технологик картасында каралмаган урыннарга агач материалын чыгару, тарттыру рөхсәт ителми;

к) диләнке чистарту эшләрен үтәмәү яисә үз вакытында үтәмәү рөхсәт ителми;

л) сөйрәмә җирләрдән һәм төяү мәйданнарыннан кала, туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми;

Исемлеге РФ ТРЭМның «Россия Федерациясе Кызыл китабына яисә Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән, сирәк очрый торган һәм юкка чыгу куркынычы янаган агачларны, куакларны, лианаларны, бүтән урман үсемлекләрен саклау үзенчәлекләрен раслау турында» 2017 ел, 29 май, № 264 боерыгы белән расланган агачларның һәм куаклыкларның төрләренең (токымнарының) агач материалын әзерләү рөхсәт ителми.

Агач материалы әзерләгәндә урман утыртмалары агачлары составында 3 һәм аннан да күбрәк берәмлектә кедр катнашучы өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисү рөхсәт ителми.

Агач материалы әзерләгәндә урманнарның биотөрлелеген арттыру максатларында теләсә кайсы ярусында һәм аларның төркемнәрендә аерым кыйммәтле агачлар (карт агачлар, куышлы, кош оялары булган, шулай ук оя кору һәм вак җәнлекләрнең качу урыны һ.б. өчен яраклы агачлар) сакланырга мөмкин.

Агач материалы әзерләү максатларында урман кишәрлеге мәйданының кисү өчен билгеләнгән өлеше (алга таба – диләнке) аерып алына, шулай ук урман утыртмаларының сан һәм сыйфат сыйфатламалары һәм әзерләнергә тиешле агач материалы күләмен билгеләүче диләнке таксациясе ясала. Диләнкеләрне аерып алганда җирлектә диләнкеләрнең чикләре билгеләнә һәм тамгалана, сайланма кисүләрдә киселергә тиешле агачлар билгеләнә.

Диләнкеләрнең чикләрен җирлектә билгеләмичә диләнкеләр эшләү гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен коры-сары, җил аударган һәм давыл сындырган агачларны әзерләгәндә һәм урманнарны чүпләнүдән чистартканда рөхсәт ителә. Бу вакытта кислерегә тиешле агачларга тамгалар ясала (ачык төсле лента, скотч, буяу, юнып алу).

Диләнкеләрне аерып чыгарганда һәм, диләнке почмакларында баганалар утыртуны да кертеп, файдаланып карау мәйданнарын ясаганда чик буендагы визирларда агачларны кисү рөхсәт ителә.

Диләнкене аерып алу һәм таксацияләү түбәндәгеләр тарафыннан башкарыла:

1) урман кишәрлекләренең аренда шартнамәләре нигезендә агач материалы әзерләүче гражданнар һәм юридик затлар;

2) үзләренә даими (дәвамлы) файдалануга тапшырылган урман кишәрлекләрендә агач материалы әзерләүне гамәлгә ашыручы федераль дәүләт учреждениеләре;

3) Россия Федерациясе Урман кодексының 82-84 статьяларына туры китереп билгеләнгән вәкаләтләре кысаларында, – дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә агач материалы әзерләү өчен, – гражданнар һәм юридик затлар.

Урман кварталында бер үк вакытта өлергән һәм картайган агачлар үсеп утыручы берничә чиктәш урман-таксация бүлендекләре кисүгә аерып чыгарылырга мөмкин, әгәр аларның суммар мәйданы РФ Урман кодексының Агач материалы әзерләү кагыйдәләрендә һәм 23 статьясында күрсәтелгән урманчылыкларда, урман-паркларында РФ ТРЭМның 2016 ел, 13 сентябрь, № 474 боерыгы белән расланган Агач материалы әзерләү үзенчәлекләрендә күрсәтелгән диләнкеләрнең чик дәрәҗә (максималь) зурлыкларыннан артып китмәсә.

Урман үрентеләрен кисүләр сайланма кисүләр яки тоташ кисүләр рәвешендә башкарыла.

Тиешле җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә агачларның һәм куаклыкларның бер өлеше киселә торган кисүләр сайланма кисүләр була (РФ УК 17 статьясының 2 өлеше).

Тиешле җирләрдә яки җир кишәрлекләрендә, урманнарны үстерү өчен аерым агачларны һәм куаклыкларны яисә агачларның һәм куаклыкларның төркемнәрен саклап, урман утыртмаларын кисүләр тоташ кисүләр дип таныла (РФ УК 17 статьясындагы 3 өлеше).

Агач материалы әзерләү өчен билгеләнгән урман кишәрлекләрендә тоташ кисүләр аталган урман кишәрлекләрендә урманнарны торгызу шарты белән генә рөхсәт ителә (РФ УК 17 статьясындагы 5 өлеше).

Бер тапкырда киселә торган агач күләмен (кисү интенсивлыгын) исәпкә алып, сайланма кисүләрне түбәндәге төрләргә бүләләр: бик аз ешлыклы – киселә торган агач күләме аның гомуми запасында 10 процентка, аз ешлыклы – 11-20 процентка, уртача ешлыклы – 21-30 процентка, уртача югары ешлыклы – 31-40 процентка, югары ешлыклы – 41-50 процентка, бик югары ешлыклы – 51-70 процентка кадәр җитә.

Өлгергән, картайган урман утыртмаларын сайланма кисүләр икенче ярустан һәм төп (максатчан) токым шытымнарыннан булган тотрыклы урман утыртмаларын формалаштыруны тәэмин итәрлек ешлык белән уздырыла. Бу очракта өлгергән һәм картайган агачларның бер өлеше киселә, икенче ярусы һәм шытымнары саклана.

Икенче яруска беренче ярусының 0.5 башлап 0.8 кадәр тәшкил итә торган биеклектәге агачлар өлеше керә. Беренче яруста үсеп калган калган (картайган) агачлар икенче яруска һәм шытымга керми.

Ирекле-сайланма кисүләрдә, агач токымнарының яңадан үсеп чыгуын тәэмин итү, урманның яклаучы һәм тирәлек хасил итүче үзенчәлекләрен саклау шарты белән, иң беренче чиртта, мәйданы буйлап тигез рәвештә зарарланган, картайган, үсеше акрынайган өлгергән агачлар киселә. Урман утыртмаларына карата әлеге төр сайланма кисүләрне үткәргәннән соң агачларның тулылыгы кимендә 0,5 булырга тиеш.

Төркемле-сайланма кисүләр төркемле-төрле яшьтә булган урман утыртмаларына карата башкарыла, аларда картайган һәм өлгергән агачлар, диләнке мәйданы буйлап урнашуларына карап, төркемнәре белән киселә. Киселүче төркемнәрнең мәйданы 0,01дән 0,5 гектарга кадәр тәшкил итә.

Ешлык һәм кабатланучанлык буенча кисү нормативлары ирекле-сайланма кисүләрнеке кебек.

Тигез-эзлекле кисүләрдә бер үк яшь классына караган агачлар диләнкедә, икенче ярустагы урман утыртмаларын һәм шытымнарын кисү процессында алдан ук яки алга таба урман торгызуны формалаштырып, тигез рәвештә сирәкләү юлы белән, берничә мәртәбә киселә.

Тигез-эзлекле кисүләр шулай ук тереклек итү сәләте зәгыйфьләнгән шытымы яки икенче ярусы булган югары һәм уртача тулылыклы агачларга, төрле өлгергәнлек яшенә ия булган агач токымнарыннан хасил булган катнаш агачлыкларга (ылыслы-яфраклы, усаклы-каенлы һ.б.) карата гамәлгә ашырыла.

Кисүләрне беренче мәртәбә башкарганда агачларның тулылыгы 0,5кә кадәр кими. Тиешле үсеп китү шартларында шытымнары булмаганда яки утыртмаларны формалаштыру өчен җитәрлек санда булмаганда тигез-эзлекле кисүләр процессында урманны торгызуга булышлык итү чаралары гамәлгә ашырыла.

Төркемле-эзлекле (чокыр-чокыр) кискәндә агачлар берничә алымда, ике яшь классына тигез булган чор дәвамында үсемлекнең чәчәклекләре булган урыннарда төркемле-төркемле итеп (чокыр-чокыр) киселә, шулай ук аларның яңадан шытып чыгуы тәэмин ителә, бер яшьле агачлар арасында шытымны төркемләп урнаштырып башкарыла. Өлгергән агачларны кисү эзлекле рәвештә 0,01 гектардан 1,0 гектарга кадәрге мәйданнарда (тирән сөзәк чокырлар хасил итеп) 30-40 ел дәвамында 3-5 мәртәбә шытым төркемнәре тирәли гамәлгә ашырыла.

Озаклап-эзлекле итеп кисүләр, әлеге шартларда тотрыклы булып кала торган, өлгереп җитмәгән, эксплуатация күләмнәренә җиткән агачлар өлешен икенче алымга калдырып, ике тапкырда төрле яшьтәге урман утыртмаларында башкарыла. Беренче мәртәбә кискәннән соң чагыштырма тулылыгы куе төстәге ылыслы утыртмаларда кимендә 0,5 һәм ачык төстәге ылыслы урман утыртмаларында кимендә 0,4 булырга тиеш. Кисүләрне кабатлау чоры – 30-40 елдан соң.

Полоса аша эзлекле кисүләрне башкарганда агачлар яшьнең бер классына тигез булган чор дәвамында, ике-дүрт алым белән киселә. Агачларның метр ярымлы озынлыгыннан узмаган киңлектәге полосаларда, ә имән урманнарында – агачларның икеләтелгән озынлыгыннан артмаган киңлектәге полосаларда агачлар кисү, алга таба имән культуралары булдыру шарты белән, 4-8 ел саен кабатлана торган ешлык алымнары белән гамәлгә ашырыла.

Йомшак яфраклы, җилгә каршы торучан агачлыкларда яшьнең ике классына тигез булган чор дәвамында полоса аша эзлекле кисүләрне уздыру рөхсәт ителә.

Агачларны полоса аша эзлекле кисүләрнең беренче алымы башкарылганнан соң, шытымнар булмаганда яисә җитәрлек күләмдә булмаса һәм икенче ярусы күренмшсш, РФ ТРЭМның 2016 ел, 29 июнь, № 375 боерыгы белән расланган Урман торгызу кагыйдәләренә ярашлы рәвештә урман торгызу чаралары күздә тотыла

Кисүнең киләсе һәр алымы алдагы чорда киселгән полосаларда ышанычлы рәвештә урманның яңартылуы тәэмин ителгәннән соң башкарыла.

Кисүнең чираттагы алымын уздыру вакыты килеп җиткәч урман табигый рәвештә яңармаганда яисә бу эш җитәрлек дәрәҗәдә күзәтелмәгәндә, кисү алымнары аралыгын 3-5 елга арттырып, ясалма яисә катнаш урман торгызу чараларын уздыру рөхсәт ителә.

Шытымы һәм икенче ярусы нык зәгыйфьләнгән агачлыкларда өч алымда катнаш сайланма кисүләр билгеләнергә мөмкин, алар барышында беренче алымда запас буенча 30-35 проценты ешлык белән тигез-эзлекле кисүләр башкарыла, ә инңе яшь агачларның торышы яхшыртылгач – ике алымда полоса аша эзлекле кисүләр.

Эзлекле кисүләрнең йомгаклау алымы бары тик диләнкедә яшәргә сәләтле, максатчан урман утыртмаларын формалаштыруны тәэмин итәрлек шытымнар һәм (яисә) икенче ярус формалашканнан соң гына башкарыла.

Урманнарны бер үк вакытта агач материалы әзерләп кискәндә киселгән урыннарны (диләнкеләрне) кисек калдыкларыннан чистартырга кирәк (РФ Хөкүмәтенең 2007 ел, 30 июнь, № 417 карары).

Урманнардан файдаланучы гражданнар һәм юридик затлар үрентеләрне һәм яшь агачларны сакларга бурычлы булганда, күп очракта кисенте урыннарын (диләнкеләрне) кисек калдыкларыннан чистарту буенча ялкынсыз ысуллар кулланыла.

Кисенте урыннарын (диләнкеләрне) чистартканда түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) кышкы чорда кискәндә – язын җыештырып бетерү;

б) кисенте калдыклары күчләргә яисә киңлеге 3 метрдан артмаган валларга черү, яндыру яисә вакланган рәвешендә аларны урман утыртмаларына якын урнашкан җирләрдән кимендә 10 метр аралыкта кисенте урыннары (диләнкеләр) мәйданы буйлап сибеп чыгу өчен урнаштырыла. Валлар

арасындагы аралык кимендә 20 метр булырга тиеш, әгәр ул диләнке эшләренең технологиясенә бәйле булмаса;

в) кисенте урыннары (диләнкеләр) янгын чыгу куркынычы янаган сезон башланыр алдыннан кисенте калдыкларыннан яндыру ысулы белән чистартыла. Җәйге чорда агач материалы әзерләүдән һәм агач кисүдән калган, язгы чорда кисенте урыннарын (диләнкеләрне) чистартып бетерү барышында җыелган калдыкларны яндыру эше көзен, янгын чыгу куркынычы янаган сезон тәмамланганнан соң гамәлгә ашырыла. – РФ Хөкүмәтенең 2007 ел, 30 июнь, № 417 карарында язылганнар курсив белән күрсәтелә.

## 2.2. Урманнардан чәер әзерләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

РФ УК 31 ст. һәм «Чәер әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2012 ел, 24 гыйнвар, № 23 Рослесхоз боерыгы белән регламентлана.

Чәер әзерләү ылыслы өлгергән һәм картайган агачлыкларда гамәлгә ашырыла, алар кирт ясау буенча билгеләнгән чор тәмамлангач агач материалы әзерләү өчен билгеләнә.

### 2.2.1. Агачларга кирт салу фонды

11 таблица.

Агачларга кирт салу фонды

мәйданы, га

| № п/п | Күрсәткечләр | Кирт салу | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Урманнарның максатчан билгеләнеше | | |
| | | Яклаучы урманнар | Эксплуатация урманнары | Җәмгысе |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Кирт салуга яраклы, өлгергән һәм картайган утыртмалар, барлыгы: | - | 2 | 2 |
| 1.1 | Алардан: | | | |
| | - кирт салуга җәлеп ителмәгәне | - | 2 | 2 |
| | - кирт салуга табышлы түгел | | 2 | 2 |
| 2. | Ел саен кирт салу күләме | – | – | – |

Урманчылыкта кирт салу фонды ачыкланмады һәм киләсе хисап чорында проектланмый һәм таблица тутырылмый. Шуңа бәйле рәвештә, урманчылык буенча урман хуҗалыгы регламентында кирт салу төрләре, агачларда каррлар күләме һәм агачларның диаметрына карап, каррлар арасындагы каешларның киңлеге, урманнардан чәер әзерләү өчен файдалану чорлары каралмый.

## 2.3. Урманнардан агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану РФ УК 32 ст., «Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 5 декабрь, № 512 Рослесхоз боерыгы, «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 ел, 22 май № 22-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән регламентлана.

Агач булмаган урман ресурсларына түмәрләр, каен тузы, агач һәм куак кайрылары, чыбык-чабык, ботаказык, чыршы, ак чыршы, нарат ботаклары, чыршылар һәм (яки) яңа ел бәйрәме өчен башка ылыслы агач токымнары, мүк, урман түшәмәсе, камыш, кыяклылар һәм шуңа охшаш урман ресурслары керә.

Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу гражданнар, юридик затлар тарафыннан эшкуарлык максатларында, шулай ук гражданнар тарафыннан – шәхси ихтыяҗлар өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Эшкуарлык эшчәнлеге максатларында агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе 10 елдан 49 елга кадәрге чорга төзелә.

Шәхси ихтыяҗларда агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу РФ УК 11 ст. 1 өлешенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю өчен урманнардан файдалану рөхсәт ителгән кварталларның исемлекләре 5 таблицада күрсәтелде.

Урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе яки урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе нигезендә агач материалы әзерләгәндә кисүдән калган агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өстәмә шартнамә төзүне таләп итми һәм урманнан файдалануның аерым төре булып саналмый.

Гражданнарга төрләре Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән, кыргый үсә торган гөмбәләрне һәм үсемлекләрне, шулай ук «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» 1998 ел, 8 гыйнвар, № 3-ФЗ федераль закон нигезендә наркотик чаралар дип танылган кыргый үләннәрне һәм гөмбәләрне әзерләү һәм җыю тыела.

Урман кишәрлекләрен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен арендалаучы гражданнарның һәм юридик затларның хокуклары:

1) урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе (урман утыртмаларын сату-алу шартнамәсе) шартлары нигезендә файдалануны гамәлгә ашыру;

2) урман инфраструктурасы төзү (урман юллары, урман саклыкханәләре һәм башкалар);

3) Россия Федерациясе Урман кодексының 32 статьясының 3 өлеше нигезендә тапшырылган урман кишәрлекләрендә эвеслекләр һәм башка төрле вакытлы корылмалар торгызу.

Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен файдаланучы гражданнарның һәм юридик затларның бурычлары:

5) РФ УК 88 ст. 1 өлешенә ярашлы рәвештә урманнарны үзләштерү проекты төзергә;

2) урманнардан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә файдалану;

3) урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе шартларын үтәү;

4) санитар-савыктыру чараларын гамәлгә ашырырга (корыган һәм зарарланган урман үсентеләрен кисү, урманнарны чүптән, пычранудан һәм башка тискәре йогынтыдан яклау).

5) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 ел, 30 июнь, № 417 карары белән расланган Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең 13 пунктындагы таләпләрне үтәргә;

6) РФ УК 26 ст. 2 өлешенә ярашлы рәвештә ел саен урман декларациясе тапшырырга;

7) РФ УК 49 статьясының 1 өл. нигезендә урманнардан файдалану турында хисап тапшырырга;

8) РФ УК 60.11 ст. 1 өлеше нигезендә урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшырырга;

9) РФ УК 91 ст. 4 өлешенә ярашлы рәвештә дәүләт урман реестрына билгеләнгән тәртиптә РФ УК 91 ст. 2 өлешендә каралган документлаштырылган мәгълүматларны тапшырырга.

### 2.3.1. Урманнардан агач булмаган урман ресурсларын төрләре буенча әзерләү һәм җыю өчен файдалану нормативлары (ел саен рөхсәт ителгән күләмнәре) һәм параметрлары

Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу өчен урманнардан рөхсәтле файдалануның ел саен рөхсәт ителгән күләмнәре 12 таблицада китерелде.

12 таблица

Агач булмаган урман ресурслары әзерләү өчен урманнардан рөхсәтле файдалану параметрлары

| № п/п | Агач булмаган урман ресурсы төре | Үлчәү берәмлеге | Әзерләүгә ел саен рөхсәт ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Туз | т | 20 |
| 2. | Агачлар кайрысы, мунчала | т | 0,5 |
| 3. | Озын корыган ботак | т | 8 |
| 4. | Ботак азыгы (каен, юкә, усак) | т | 25 |
| 5. | Чыршы һәм нарат (нарат) ботаклары | т | 14,5 |
| 6. | Чыршылар һәм (яки) яңа ел бәйрәмнәре өчен башка ылыслы токым агачлары | мең данә | 0,5 |

| №<br>п/п | Агач булмаган урман ресурсы төре | Үлчәү берәмлеге | Әзерләүгә ел саен рөхсәт ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 7. | Мунчала | т | 8,5 |

Агач булмаган урман ресурсларының классификациясе бар, аның нигезендә ресурсларны, барлыкка килү (әзерлек) урынына, ресурсны исәпкә алу (бәяләү) ысулына, файдалану холкына карап, 3 төркемгә бүлү каралган (12.1 таблица).

12.1 таблица.

Агач булмаган урман ресурслары классификациясе

| Агач булмаган урман ресурслары | Билгеләмәсе, ГОСТ, ОСТ, ТУ |
|---|---|
| 1 | 2 |
| **Агачның биомасса компонентлары (диләнке калдыклары)** | |
| Калын ботаклар | Нигезендә 3 см артык юанлыктагы, кәүсәдән чыгучы агачланган ян-як агач шытымнары, ГОСТ 17462-84 |
| Нечкә ботаклар | Агач төбеннән 3 см һәм аннан азрак юанлыктагы агач ботакларыннан чыгучы аз агачланган яки агачланмаган ян-як шытымнар, ГОСТ 17462-84 |
| Агач яшеле | Ылыслары, яфраклары, бөреләре һәм агач-куаклык үсемлекләренең агачланмаган шытымнары, түбәндәгеләрдән гайре: эт шомырты, агулы сумаха, бүре җиләге, кара аю баланы, еламсар тал, чикләвек, бук, кабар агачы, имән, чикләвек куагы – нигезендә 1 см кимрәк юанлыкта, ГОСТ 21769-84 |
| Чыршы, каен, юкә, башка токым кайрылары | Агач материалын каплаучы кәүсәнең, калын ботакларның, нечкә ботакларның тышкы өлеше, ГОСТ 17462-84 |
| Наратның, башка токымнарның түмәр өлеше | Сәнәгатьчелектә эшкәртүгә һәм ягулык сыйфатында файдалануга билгеләнгән агачның тамыр өлеше һәм тамырлары, ГОСТ 17462-84. |
| Озын корыган ботак | 4 см кадәр юанлыкта нечкә агач кәүсәләре, ТУ 463-8-766-79 |
| **Урманнардан тере чагында файдалану ресурслары** | |
| Чәер | Сагызлы матдә, ылыслы агачларны җәрәхәтләгәндә бүленеп чыга, ОСТ 13-428-82 |
| Баррас | Куеланган (катыланган) чәер – түбән бонитетлы нарат утыртмаларын киртләгәндә бүленеп чыгучы төп продукт, ОСТ 13-197-84 |
| Чыршы чәере | Ябышучан (уалучан) чыршы чәере, кәүсәләр зарарланганда бүленеп чыга, ТУ 13-284-80 |
| **Башка төрле урман ресурслары** | |
| Тал һәм башка токым | Җиһаз ясау, үрү өчен  (ТУ56-44-86), дуплау матдәләре (ГОСТ 6663-74) әзерләү һ.б. өчен файдаланыла торган агач-куаклык токымнары |

| Агач булмаган урман ресурслары | Билгеләмәсе, ГОСТ, ОСТ, ТУ |
|---|---|
| 1 | 2 |
| үрентеләре | шытымнары. |
| Яңа ел чыршылары | ТУ 56 РСФСР 41-81 |

Чыгарылган 1000 м$^3$ агачтан агач булмаган урман ресурсларының якынча беренчел продукциясен исәпләү мисалы 12.2 таблицада күрсәтелде.

12.2 таблица.

1000 м$^3$ күләмендә чыгарылган агачтан агач булмаган урман ресурсларының беренчел продукциясе (исәпләмә мисалы)

| Агач булмаган урман ресурслары | Табигый чагылышындагы нормативлар, м$^3$ | | Беренчел продукция | Продукция берәмлегенә сарыф ителгән чимал нормасы | Ресурслардан табигый чагылышында алынган продукциянең чагыштырма авырлыгы, % | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Калдыклар барлыкка килү (потенциаль ресурслар) | Файдалануга яраклы (икътисадый мөмкин ресурслар) | | | Потен-циаль | Икътисадый мөмкин булган |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| Калын ботаклар | 110 | 24 | Чимал технологик, м$^3$ | 1,3 | 84,6 | 18,5 |
| Нечкә ботаклар | 90 | 20 | Агач яшеле, т | 2,7-3,3 | 30,0 | 6,7 |
| Кайрысы | 100 | 70 | Дуплау кайрысы, т | 2,1-3,6 | 39,2 | 24,8 |
| Түмәрләр | 30 | 15 | Түмәр сумаласы, т | 5,4 | 5,6 | 2,8 |
| Озын корыган ботак | 110 | 77 | Төрле токым һәм озынлыктагы чыбык-чабык, м$^3$ | 1,1 | 100,0 | 70,0 |

Агач яшеле – саф азык (ботаказык) яки терлекчелек өчен витаминлы азык продуктлары әзерләү чималы сыйфатында кулланылучы ылыслар, яфраклар (бөреләр) һәм төрле агач һәм куак токымнарының 0.8 см кадәр диаметрлы агачланмаган ботаклары (шытымнары).

Техник яшеллек – агач яшеленең эшкәртү өчен кулланылучы масса өлеше. Наратта ул агач яшеленең гомуми массасыннан 35%ын, чыршыда – 50%ын, каенда – 20 %ын тәшкил итә.

***Ылыс яшеле запасларын билгеләү.***

Агач яшелен әзерләү агачларны кисү нәтиҗәсендә аударылган барлык яшь төркемнәрендәге утыртмалар буенча башкарыла. Агач яшелен диаметры (d=1,3 м) кимендә 18 см булган, үсеп утыручы өлгергән өлешеннән агач кәүсәсенең 30%ы озынлыгында нәзек ботакларын кисеп алу юлы белән әзерләү рөхсәт ителә.

Агач (техник) яшеле запасларын билгеләү төбәк норматив-белешмә таблицасын кулланып башкарыла.

1 гектарда техник яшеллек запасын билгеләү өчен әлеге утыртманың 1 гектар агачларының уртача санын һәм аларның юанлык баскычлары буенча урнашуын белергә кирәк. Әгәр андый белешмәләр булмаса, 0,5 га зурлыгында тәҗрибә мәйданнары ясарга һәм, агачларны санап, 1 га һәр юанлык баскычындагы агачларның уртача санын ачыкларга кирәк. Килеп чыккан санга бер агачтан чыккан техник яшеллек күләмен тапкырлап, аның 1 гектарлык запасын, ә аннан соң чимал базасының барлык мәйданы буенча ресурсларын да ачыклыйлар. Хисап эшләрен алып барганда шулай ук билгеле агач токымының 1 м$^3$ кәүсә массасыннан чыгучы уртача техник яшеллек саныннан чыгып та эш итәргә мөмкин.

Кабыгы, ылыс яфраклары, үзагачы, органик булмаган һәм органик агач кушылмаларының торышына карап агач яшеле ГОСТ 21769-84 таләпләренә җавап бирергә тиеш.

Терлек азыгы максатларында агач яшеле әзерләнгәндә эт шомыртын, бүре җиләген, аю баланын, еламсар талны, кабар агачын, имәнне куллану рөхсәт ителми.

***Нарат һәм чыршы ботаклары запасларын билгеләү.***

Пихта, нарат һәм чыршы ботаклары запаслары төбәкнең 12.3, 12.4 норматив-белешмә таблицалары ярдәмендә билгеләнә.

12.3 таблица.

Нарат ботаклары массасы

| D=1.3 м, см | Бер чыршы агачыннан ылыслы ботаклар массасы, кг, биеклекләр разрядына карап | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ia | I | II | III | IV |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 12 | 13 | 12 | 11 | 10 | 9 |
| 16 | 20 | 18 | 17 | 15 | 14 |
| 20 | 28 | 25 | 23 | 21 | 19 |
| 24 | 34 | 31 | 29 | 27 | 25 |
| 28 | 41 | 38 | 36 | 32 | 29 |
| 32 | 48 | 44 | 41 | 37 | 34 |
| 36 | 54 | 48 | 46 | 42 | 38 |
| 40 | 61 | 56 | 51 | 48 | 43 |
| 44 | 66 | 60 | 57 | 52 | 47 |

| D=1.3 м, см | Бер чыршы агачыннан ылыслы ботаклар массасы, кг, биеклекләр разрядына карап | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ia | I | II | III | IV |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 48 | 72 | 67 | 61 | 56 | 52 |
| 52 | 77 | 72 | 66 | 60 | 56 |
| 56 | 82 | 76 | 70 | 66 | 59 |

12.4 таблица.

Чыршы ботаклары массасы

| D=1.3 м, см | Бер чыршы агачыннан ылыслы ботаклар массасы, кг, биеклекләр разрядына карап | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | Ia | I | II | III | IV |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| 8 | 10 | 9 | 8 | 7 | 7 |
| 12 | 21 | 18 | 16 | 15 | 13 |
| 16 | 38 | 31 | 44 | 24 | 20 |
| 20 | 63 | 53 | 29 | 37 | 31 |
| 24 | 86 | 72 | 60 | 50 | 42 |
| 28 | 125 | 104 | 80 | 67 | 56 |
| 32 | 150 | 126 | 105 | 88 | 67 |
| 36 | 195 | 163 | 125 | 104 | 87 |
| 40 | 229 | 192 | 146 | 123 | 103 |
| 44 | 269 | 224 | 172 | 144 | 110 |
| 48 | 289 | 239 | 200 | 167 | 128 |
| 52 | 331 | 276 | 232 | 177 | 148 |

### *Түмәр сагызы*

Нарат түмәре сагызы дип өлгергән нарат түмәренең һәм тамырларының сәламәт, сагыз матдәләрен алу өчен чимал буларак файдаланыла торган өлеше атала. Агачларны кискәннән соң түмәрләр тора-бара бозыла башлыйлар. Бу процесс, барыннан да элек, иң аз сагызлы түмәр өлешләрен колачлый. Сагыз матдәләре агачка черүгә каршы торуда тотрыклылык бирә. Башта төчлегән өлеше һәм вак-вак тамырлары чери. Аз сагызлы түмәр өлешенең черү процессы, бер үк вакытта, алга таба түмәр сагызын әзерләүдә файдалану күзлегеннән чыгып фикер йөрткәндә, түмәрнең өлгерү процессы да булып тора.

Түмәрнең өлгерү дәрәҗәсе торышына карап билгеләнә. Төчлегән өлеше череп беткәч һәм үзәк өлешеннән җиңел каерыла башлагач, түмәрне файдалану өчен өлгергән дип санарга мөмкин. Өлгергән түмәрләр җиңел аралана һәм чистартыла. Түмәр өлгергән вакытта ул сагызлы матдәләргә байый, сагызы азрак булган түмәрләр тизрәк череп бетә. Әйтик, 15 елдан соң түмәр сагыз әзерләү өчен өлгергән дип санала, бу вакытта диләнкедә барлык түмәрләрнең 70%ы тирәсе кала. Әгәр дә әзерлек эшләре агачны кискәннән соң 25 ел узгач алып барылса, ул вакытта элеккеге диләнкедә түмәрләрнең башлангыч

санынннан нибары 40%ы тирәсе генә сакланып калачак. Иң зур һәм эчендә сагыз матдәләре аеруча югары булган түмәрләр генә кала.

Агачны кискәннән соң түмәрнең җирдә утырган вакытына карап, яңа (5 яшькә кадәрге) өлгереп килүче (5-10 яшь) һәм өлгергән (10 яшьтән олы) түмәрләрне аерып чыгаралар.

Нарат сагызының өлгерү процессы туфрак-климат һәм урманчылык факторларына бәйле һәм, кагыйдә буларак, 10-15 елга кадәр дәвам итә. Көньяк районнарда өлгерү тизрәк бара, төньякта – акрынрак. Коры туфракларда, җитәрлек дымы булган туфракларга караганда, өлгерү акрынрак бара.

Киселгән җирләрдә барыннан да бигрәк эре үзәкле түмәрләр озаграк саклана, андый түмәрләрнең саны кисеп ташланган агач сыйфатламасына бәйле.

### *Түмәр сагызы запасларын билгеләү.*

Түмәр сагызын әзерләү буенча чимал базасы буларак түбәндәгеләр хезмәт итә:

1) саф һәм коры туфраклы торгызылмаган нарат кисентеләре;

2) нарат агачлары киселгән урыннарда 13 яшькә кадәрге, I-IV бонитет класслы, ылыслы утыртмаларда тулылыгы – 0,3-0,7 һәм яфраклы утыртмаларда 0,3-0,8 булган ылыслы һәм яфраклы яшь агачлар, махсус яклanучы кишәрлекләрдән тыш;

3) рәт араларының киңлеге 2,5 метрдан артык булганда, – 40-50% дәрәҗәсендә үтеп китүчән 4-5 яшьлек нарат кисентеләрендә (тоташмаган культуралар өчен) һәм тулылыгы 0,4-0,6 булган 6-12 яшьлек урман культуралары;

4) бонитетның I-IV классларының ревизия чорына караган нарат диләнкеләре.

1 гектарда әзерләргә рөхсәт ителә торган түмәрләр саны (данә) урман культураларының булуына һәм торышына карап билгеләнә.

Әзерләнә торган түмәрләр саны:

| | | |
|---|---|---|
| 1. 0,5 метрга кадәрге биеклектә: | 5 мең данә/га кадәр | 175 |
| | 5-8 мең данә/га | 100 |
| 2. 0,5-1,5 метр биеклектә: | 3 мең данә/га кадәр | 100 |
| | 3-5 мең данә/га | 75 |
| | 5 мең данә/га артык | – |
| 3. 1,5 метрдан биегрәк булганда: | 5 мең данә/га кадәр | 50 |
| | 5 мең данә/га артык | – |

Табигый чыгышлы яшь үрентеләре белән берлектә яфраклы токымнарны кисеп ташлау:

| | |
|---|---|
| 1 метрга кадәрге биеклектә: | чикләмәләрсез |
| 3 метрдан биегрәк каен агачлары: | 100 |
| 1,5-3 метрдан биегрәк каен агачлары: | 125 |

Нарат агачларын иң күбе 20 ел элек кискәндә һәм 1 гектарда кимендә 50 түмәр булганда урманнарның коры дала типларының югарыда китерелгән җир категорияләрендә урманнарга таксация уздыру барышында түмәр сагызын

исәпкә алу эше башкарыла. Шул ук вакытта 1 гектарга түмәрләр саны, түмәрләрнең уртача диаметры һәм сагызлылыкның өлгерү классы (киселгәннән соң узган вакыт) исәпкә алына. Түмәр сагызының өлгергәнлек класслары 12.5 таблицада китерелде.

12.5 таблица.

Түмәр сагызының өлгергәнлек классы

| Кисүдән соң узган вакыт, ел | Өлгерүчәнлек классы | Сагызга сыйфатлама | Түмәрләрнең өлгергәнлек классының тышкы билгеләре |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1-5 | I | Яшь | Төчлегән череми һәм үзәк белән бербөтенне тәшкил итә |
| 6-10 | II | Өлгереп килүче | Төчлегән күп яки аз дәрәҗәдә черегән, түмәрнең җир өстендәге өлешендә үзәгеннән көч белән аерыла, җир асты өлешендә – аерылмый |
| 11-15 | III | Өлгергән | Төчлегән сизелерлек черегән һәм үзәгеннән җиңел аерыла |
| 16-20 | IV | Картайган | Төчлегән тулысынча черегән, үзәге чери башлаган |

1 гектарга түмәрләр саны тәҗрибә мәйданчыкларында тоташ санап чыгу, тасмалы санап чыгу яисә исәпкә алу адымнары (21 түмәр арасындагы аралар буенча билгеләнә торган уртача ераклык буенча) белән билгеләнә.

Түмәр сагызы ресурслары, түмәрләр саныннан һәм диаметрыннан чыгып, төбәк норматив-белешмә таблицаларын исәпкә алып билгеләнә.

### *Мунчала запаслары билгеләү*

Нормаль юкә агачларының 1 га мунчала чыгышы 12.6 таблицада күрсәтелде.

12.6 таблица

Нормаль юкә агачларының 1 гектарыннан мунчала чыгышы

| Уртача диаметры, см | Агачның тулылыгы | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 0,3 | 0,4 | 0,5 | 0,6 | 0,7 | 0,8 | 0,9 | 1,0 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 16 | 53 | 58 | 62 | 64,6 | 65,4 | 66,4 | 67 | 67,5 |
| 18 | 48,8 | 51,2 | 54,8 | 57 | 57,8 | 58,6 | 59,2 | 59,6 |
| 20 | 42 | 45,9 | 49,1 | 51,2 | 51,3 | 52,6 | 53,4 | 53,5 |
| 22 | 38 | 41,6 | 44,5 | 45,3 | 46,9 | 47,6 | 48 | 48,4 |
| 24 | 34,9 | 38,2 | 40,9 | 42,6 | 43,1 | 43,8 | 44,2 | 44,5 |
| 26 | 31,8 | 34,8 | 37,2 | 38,9 | 39,3 | 39,9 | 40,3 | 40,6 |
| 28 | 29,4 | 32,2 | 34,4 | 35,9 | 36,3 | 36,9 | 37,2 | 37,5 |
| 30 | 27,1 | 29,7 | 31,7 | 33,1 | 33,5 | 34 | 34,3 | 34,6 |

искәрмә. Мунчала запаслары кисүгә тапшырылучы утыртмалар өчен билгеләнә, түбәндәге формула буенча:

V=0,1KxMxL

Биредә:

V – чыккан мунчала;

К – утыртмадагы юкәнең состав коэффициенты;

М – утыртма запасы;

L – 1 м$^3$ юкәгә мунчала чыгышы (таблица билгесе).

### *Агач кайрысы*

Агач үрентеләренең күпчелек төрләренең кабыгы дуплау сыйфатында күн сәнәгатендә кулланыла. Үсемлек рәвешендәге дуплау матдәләре арасында тал кайрысы беренче урыннарның берсен алып тора. Тал кайрысы белән эшкәртелгән күн эластик, йомшак һәм югары механик сыйфатларга ия була.

Талның кайбер төрләре (ак, кәҗә, уалучан, әйлән-бәйлән, кызгылт) кайрысыннан йонны, ефәкне, лайка күнен, җитен һәм мамык җепләрен буяу өчен буяулар әзерлиләр, салицил һәм гликозид алалар.Талның яшь кайрысы капчык материалы, баулар, шпагат әзерләү өчен кулланыла.

Тал кайрысының дуплау матдәләре – таннидлар – билгеле бер эрү ноктасы булмаган аморф (кристаллик булмаган) кушылмалардан гыйбарәт. Таннидлар күләменең проценты зуррак булган саен, кайрының да дуплау матдәсе буларак сыйфаты югарырак була.

Кайрыдагы таннидлар саны, асыл рәвештә, талның төренә бәйле. Таннидлыкка тәэсир итүче факторлар – үсемлекнең яше, талда кайрының урнашкан җире, әзерләү чоры, үскән урынына бәйле шартлар.

Агач рәвешендәге аеручы кыйммәте кайрыга ия булучылар булып кәҗә, уалучан, биек, саз һәм биш яфрак таллары санала, аларның кайрысында 8%тан алып 12%ка кадәр таннид бар. Агач-куак рәвешендәге төрләрдән таннидлар иң күп булганы – өчьяфрак, коры кайрылы, соры һәм йонлач таллар аерып чыгарыла. Кайрысында 7%тан кимрәк таннидлары булган тал төрләре кайрысыз төркемгә кертелгән.

Картаеп бөкеләнгән кайрыда, бер еллык яшь ботаклардагы кайрылардагы кебек үк, таннидлар бик аз күләмдә була. Талларның күпчелек төрләре өчен таннидлар 4 яшьтән 15 яшькәчә булган талларга хас. Кәүсәнең аскы өлешендәге кайрысында таннидлар өске өлешенә караганда күбрәк була.

Суты йөргәндә талда таннидлар кышкы чор белән чагыштырганда шактый күп була, тал кайрысында дуплау матдәләренең иң зур күләме суты иң зур ешлык белән йөргән чакта – май башыннан алып июль уртасына кадәрге чорда була.

Таннидларның күләменә тал үрентеләренең үсеп утыру урынына бәйле шартлар да йогынты ясый. Аеручы уңдырышлы туфраклар дуплау матдәләренең гомуми туплануына яхшы тәэмир итә.

### *Каен тузын исәпкә алу һәм әзерләү үзенчәлекләре*

Ике төрле каен тузы әзерләнә. Сутлы килеш – үсеп утыручы агачлардан һәм шомарткыч ярдәмендә (ышкып алу) – каенның аскы өлешеннән, утыннардан һәм аударылган агачлардан. Үсеп утыручы агачлардан туз әзерләү, кисү башланырга 1-2 ел кала, урман бүлемтегендәге агачлардан рөхсәт ителә, диаметры кимендә 12 см һәм фанер әзерләү өчен билгеләнгән махсус сортлы агачлар моңа керми.

Үсеп утыручы агачлардан каен тузын салдыру язгы-җәйге чорда, агачның кайры астына һәм материалга китә торган өлешенә зыян китермичә генә, гомуми биклегенең яртысыннан артмаган өлешендә башкарыла.

Аударылган һәм корыган агачлардан шомарткыч ярдәмендә каен тузы әзерләү урман фондының барча территориясендә ел буе башкарылырга мөмкин.

Әзерләнгән каен тузының сыйфаты «Дегет җитештерү өчен каен тузы» ТУ 13-707-83 таләпләренә җавап бирергә тиеш. Агач кәүсәсенең 1 м$^3$ күләмендәге материалыннан килограммнарда чыккан каен тузы дәрәҗәсе 12.7 таблицада китерелде.

12.7 таблица.

Каен тузы чыгышы, кәүсәле агачның 1м$^3$ кг

| Сортиментлар исемлеге | Диаметры, см | Каен тузы чыгышы | |
|---|---|---|---|
| | | Әле яңа сыдырылган рәвешендә | Җиңелчә-коры рәвешендә |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Эре | 26 һәм аннан күбрәк | 6,3 | 3,8 |
| Уртача | 14-24 | 7,2 | 4,3 |
| Вак | 13 | 2,2 | 1,3 |
| Утын | 13 һәм аннан күбрәк | 2,2 | 1,3 |

### *Тал кайрысының запасларын билгеләү*

Тал кайрысының чимал базасы елга үзәннәрендәге һәм дымлы урыннардагы куаклы үзәннәрнең, сазланган урманнардагы, ягъни дымга мул һәм уңдырышлы туфраклы урыннардагы табигый таллыклардан гыйбарәт.

Тал кайрысын әзерләү кайрысында дуплау матдәләре 7%тан да ким булмаган талларда башкарыла (дымлылык 16%).

Агачсыман таллар: кәҗә талы – кайрының таннидлыгы 16%; уалучан, бишьяфрак – 10%.

Куаклы: соры, миндальсыман - кайрының таннидлыгы 17%; көлсыман, колаклы – 11; куе кызыл – 9.6; рус талы – 7-15; чыбыклы – 10; йонлач – 11; озын яфраклы, кара тал – 10.5; лапландия талы – 8-14; киң яфраклы – 11%. Түбән таннидлы таллар: ак тал һәм еламсар тал – кайрының таннидлыгы 6-7%.

Тал кайрысын әзерләү өчен 5 яшьлек һәм аннан олырак тал куаклары, 15 яшьлек һәм аннан олырак тал агачлары яраклы. Агач запасы кимендә 5 $м^3$/га булган, югарыда күрсәтелгән тал төрләре исәпкә алынырга тиешле.

Яңа киселгән 1 $м^3$ агачтан уртача 65 кг тал кайрысы чыга.

Тал кайрысы запаслары, 1 гектарга тал агачы запасыннан чыгып, 12.8 таблицага туры китереп билгеләнә.

12.8 таблица.

1 гектарга тал агачы запасыннан чыгып, җиңелчә-коры тал кайрысы массасы

| Запас санында меңнәрчә йөз, дистәләрчә һәм берәмлек күләме, $м^3$ | Кабык-кайры массасы, саннарга бүлеп, т | | | | Запас санында меңнәрчә йөз, дистәләрчә һәм берәмлек күләме, $м^3$ | Кабык-кайры массасы, саннарга бүлеп т | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | меңнәр | йөзләр | дистәләр | берәмлекләр | | меңнәр | йөзләр | дистәләр | берәмлекләр |
| | Куаклы таллар | | | | | Агачсыман таллар | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1 | 70 | 7 | 0,7 | 0,1 | 1 | 60 | 6 | 0,6 | 0,1 |
| 2 | 140 | 14 | 1,4 | 0,1 | 2 | 119 | 12 | 1,2 | 0,1 |
| 3 | 210 | 21 | 2,1 | 0,2 | 3 | 178 | 18 | 1,8 | 0,2 |
| 4 | 280 | 28 | 2,8 | 0,3 | 4 | 238 | 24 | 2,4 | 0,2 |
| 5 | 350 | 35 | 3,5 | 0,4 | 5 | 298 | 30 | 3,0 | 0,3 |
| 6 | 420 | 42 | 4,2 | 0,4 | 6 | 357 | 36 | 3,6 | 0,4 |
| 7 | 490 | 49 | 4,9 | 0,5 | 7 | 416 | 42 | 4,2 | 0,4 |
| 8 | 560 | 56 | 5,6 | 0,6 | 8 | 476 | 48 | 4,8 | 0,5 |
| 9 | 630 | 63 | 6,3 | 0,6 | 9 | 536 | 54 | 5,4 | 0,5 |

Мисал: 10 гектар мәйданлы бүлемтектә куаклы талдан агач запасы – 175 $м^3$/га. Җиңелчә-коры кайрының авырлыгы, таблица нормативларыннан чыгып, түбәндәгегә тигез: 7+4,9+0,4=12,3 т/га; 12,3 т/га*10 га=123 т.

### *Чыршы кайрысын исәпкә алу*

Дуплау матдәләрен алу максатында чыршы кайрысын әзерләү диләнкеләрдә чыршыларны кисү чорында, сут бирү вакытында, 20 см кадәр диаметрлы өлгергән һәм картайган утыртмаларга карата башкарыла. Әзерләнгән 1 $м^3$ чыршы гачыннан уртача 40 кг дуплау кайрысы чыга.

## 2.3.2. Урманнардан агач булмаган урман ресурслары җыю өчен файдалану чорлары

### Түмәрләр әзерләү (түмәр сагызы әзерләү)

Түмәр сагызын әзерләү теләсә нинди максатчыл билгеләнештәге, ул утыртмаларга, яңа үсеп килүче һәм яшь агачларга зарар китерә алмый торган урманнарда рөхсәт ителә.

Түмәр сагызын әзерләү ысулы (кул белән, трактор белән, шартлатып h.б.) аренда килешүендә күрсәтелә.

Эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары ярларындагы, тау һәм чокыр сөзәклекләрендәге ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч урман кишәрлекләрендә, һәм шулай ук 0,8-1,0 тулылыклы яшь агачлардан түмәр сагызы әзерләү рөхсәт ителми. Түмәр әзерләүдән калган чокырларны күмәргә һәм тигезләргә кирәк.

**Туз әзерләү.**

Туз әзерләү эшләре кисү өчен арып чыгарылган утыртмалар арасында, чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал ызаннарында, минераллаштырылган полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман ташу юлларында һәм башка, агачларны саклау таләп ителми торган мәйданнарда) үсеп утыручы агачлардан, шулай ук сайланма һәм тоташ кисүләр уздырылганда диләнкеләрдәге яңа кисеп аударылган агачлардан рөхсәт ителә.

Үсеп утыручы агачлардан туз әзерләү язгы-җәйге һәм көзге чорда төп кабыкка зыян китерелмичә башкарыла. Шул ук вакытта әзерләү өчен кулланыла торган кәүсәнең өлеше агачның гомуми биеклегенең яртысыннан артмаска тиеш.

Ел дәвамында корыган һәм ауган агачлардан туз әзерләнә.

Агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела.

**Агач кайрылары һәм куаклар әзерлә.**

Агачларның кабыгын һәм кайрысын әзерләү ел дәвамында агачларны һәм куакларны кисү белән берлектә башкарыла. Тал кайрысы язгы-җәйге чорда әзерләнә.

Тал кайрысын әзерләү өчен 5 яшьлек һәм аннан олырак тал куаклары, 15 яшьлек һәм аннан олырак тал агачлары яраклы.

**Чыбык-чабык әзерләү.**

Чыбык-чабык әзерләгәндә төп башындагы диаметры 4 см кадәрле нечкә кәүсәләр, шулай ук агачларның һәм куаклыкларның киселгән ботак һәм сабак очлары җыела. Чыбык-чабык әзерләү ел дәвамында гамәлгә ашырыла.

**Ботак азыгы әзерләү**.

Ботаказык әзерләгәндә, 1,5 см кадәр юанлыктагы, яфраклы һәм ылыслы кайбер агачларның яшь ботакларыннан әзерләнгән һәм терлек азыгы буларак кулланыла торган урман материалы җыела.

Ботаказыкны яфраклы токымнардан гадәттә җәен, ылыслы токымнардан – ел дәвамында әзерлиләр.

Ботаклардан терлек азыгы әзерләү сайланма һәм тоташ кисүләрне үткәргәндә кисеп аударылган агачлардан гамәлгә ашырыла.

Ботак азык әзерләү өчен яфраклы (каен, усак, өрәңге, чикләвек куагы, юкә, тирәк, корычагач һ.б.) һәм ылыслы (нигездә чыршы) токымнарының ботаклары кулланыла.

**Чыршы, пихта, нарат ботаклары әзерләү.**

Ак чыршы, нарат, чыршы ботакларын әзерләү бары тик сайланма һәм тоташ урман кисүләре барышында диләнкедә киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

**Чыршылар һәм (яки) яңа ел бәйрәмнәре өчен башка ылыслы токым агачлары әзерләү.**

Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршылар һәм (яисә) башка төрле ылыслы токым агачларын юридик затлар, гражданнар тарафыннан әзерләү Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган искәрмәле очракларда, РФ Урман кодексының 32 статьясының 4.1 өлеше нигезендә урман кишәрлекләрен бирмичә урман утыртмаларын сату-алу шартнамәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Яңа ел бәйрәмнәре өчен чыршыларны һәм (яисә) ылыслы бүтән агачларны әзерләү, беренче чиратта, махсус плантацияләрдә, чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минеральләштерелгән полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман хуҗалыгы юлларында һәм яшь үрентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда) рөхсәт ителә.

Агач материалы әзерләгән вакытта чыршылар һәм (яисә) бүтән ылыслы агачларны әзерләү, шул исәптән киселгән агачларның очларыннан рөхсәт ителә.

**Мүк, урман түшәмәсе әзерләү.**

Мүк, коелган яфраклар катламын, урмандагы аяк асты япмасын, камыш әзерләү төзелеш, шулай ук авыл хуҗалыгы терлекләре өчен азык һәм асларына салу материалы сыйфатында ярдәмче материал буларак һәм компост әзерләү өчен аларны куллану максатларында башкарыла. Аларны әзерләгәндә әйләнә-тирә мохиткә зыян китерелмәскә тиеш.

Мүкне әзерләү һәм җыеп алу вакытлары урман кишәрлегенең аренда килешүендә күрсәтелә.

Бензопычкы ярдәмендә мүк әзерләү бары тик урманчылык яки урман паркы хезмәткәрләре контролендә генә башкарыла.

Урмандагы аяк асты япмасын җыю бер үк мәйданда биш елга бер мәртәбә генә рөхсәт ителә. Урмандагы аяк асты түшәмәсен җыю өлешчә, бөтен катламын алмыйча гына гамәлгә ашырылырга тиеш.

Урмандагы аяк асты япмасын җыю, бу елда коелачак яфраклар һәм ылыс, шулай ук япма табигый ашлама хасил итсен өчен, җәй азагында, әмма яфраклар коела башлаганчы ук башкарылырга тиеш.

Урманнардагы табигый һәм башка объектларны саклау функциясен башкаручы түшәмәләрне җыеп алу тыела.

**Агачлар әзерләү (казып алу).**

Урман кишәрлекләрендә агачларны әзерләү (казып алу) I яшь классындагы ылыслы утыртмаларда, I һәм II яшь классындагы яфраклы утыртмаларга карата гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлекләрендә вак агачлардан торучы куаклыкларны әзерләү (казып алу) 20 яшькә кадәрле ылыслы һәм яфраклы утыртмалар арасында, 40 яшькә кадәрле кедр һәм орлыктан үскән каты яфраклы токым утыртмалары арасында, урта һәм артык куе һәм составында әзерләнә торган төр өстенлек

итүче вак агач утыртмалары арасында гамәлгә ашырыла. Әзерләнә торган төрнең калган куаклары саны бер гектарга кимендә 1000 данә булырга тиеш.

**Яфраклы токымнардан себеркеләр, ботаклар һәм куаклыклар әзерләү.**

Чистартылырга тиешле урман кишәрлекләрендә (квартал араларында, минераллаштырылган полосаларда, янгынга каршы чокырларда, янгынга каршы трассаларда һәм урман хуҗалыгы юлларында, печән чабу урыннарында, электр үткәргеч линияләрдә, су баскан зоналарда, автомобиль юлларына бүлеп бирелгән полосаларда, торбаүткәргечләрдә һәм яшь үсентеләрне саклау таләп ителми торган башка мәйданчыкларда), шулай ук сайланма яисә тоташ урман кискәндә диләнкеләрдә киселгән агачлардан яфраклы токымнардан (каен, усак, тал һ.б.) мунча себеркесе, себерке һәм кисәкләргә турау өчен ботаклар һәм куаклыклар әзерләнә.

**Агач яшеле әзерләү.**

Агач яшеллегенә яфраклы һәм ылыслы токымнарның яфраклары, бөреләре, ылыслары һәм нигезендә диаметры 8 мм га кадәр булган яңа чыккан ботаклары керә.

Ылыслы-витаминлы он җитештерү өчен үзагач яшеллеген әзерләү бары тик сайланма һәм тоташ урман кисүләр барышында диләнкедә киселгән агачлардан рөхсәт ителә.

Ак чыршы маен җитештерү өчен агач яшелен (пихта ботакларын) әзерләү өлгергән пихта үрентеләрендә язгы-җәйге чорда диаметры кимендә 18 см булган үсеп утыручы агачлардан тере ябалдашының бары тик 30%ы озынлыгында гына үткен корал белән кисеп алу юлы белән кулдан әзерләү рөхсәт ителә. Бу чакта ботаклар кыеклап яисә тип-тигез итеп, тирәсен мунчалалатмыйча гына киселергә, ботакларның агачта калдырылган өлешенең озынлыгы кимендә 30 см ким булмаска тиеш.

Ак чыршы ботакларын бер үк урман утыртмалары буенча әзерләү 4-5 елдан соң гына рөхсәт ителә.

Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыю тәртибе.

Агач булмаган урман ресурсларын шәхси ихтыяҗлар өчен гражданнар тарафыннан әзерләү һәм җыеп алу, чыршылардан һәм яңа ел бәйрәмнәре өчен башка ылыслы токымнардан кала, РФ УК 11 ст. нигезендә гамәлгә ашырыла.

Агач булмаган урман ресурсларын шәхси ихтыяҗлар өчен гражданнар тарафыннан әзерләүне һәм җыеп алуны чикләү РФ УК 27 ст. белән билгеләнә.

Агач булмаган урман ресурсларын шәхси ихтыяҗлар өчен гражданнар тарафыннан әзерләүгә һәм җыеп алуга карата РФ УК 32 ст. 1, 3 һәм 4 өл. кагылмый.

Агач булмаган урман ресурсларын шәхси ихтыяҗлар өчен гражданнар тарафыннан әзерләү һәм җыеп алу тәртибе Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнә.

Шәхси ихтыяҗлар өчен агач булмаган урман ресурсларының аерым

төрләрен әзерләгәндә һәм җыйганда урман кишәрлекләреннән файдалануга карата таләпләр «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 ел, 22 май, № 22-ТРЗ Татарстан Республикасы законында билгеләнгән.

## 2.4. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен урманнардан файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 34, 35 статьялары, 2011 ел, 5 декабрь, № 511 Рослесхоз боерыгы белән расланган Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу кагыйдәләре, «Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында» 2008 ел, 22 май, № 22-ТРЗ Татарстан Республикасы законы белән регламентлана.

Азык-төлек урман ресурсларына кыргый җимешләр, җиләкләр, чикләвекләр, гөмбәләр, орлыклар, каен суты һәм башка урман ресурслары керә.

Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу гражданнар, юридик затлар тарафыннан эшкуарлык максатларында, шулай ук гражданнар тарафыннан – шәхси ихтыяҗлар өчен гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Эшкуарлык эшчәнлеге максатларында азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе 10 елдан 49 елга кадәрге чорга төзелә.

Шәхси ихтыяҗларда азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу РФ УК 11 ст. 1 өлешенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

Чикләрендә азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен урманнардан файдалану рөхсәт ителгән кварталлар исемлеге 5 таблицада күрсәтелде.

Гражданнарга төрләре Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән, кыргый үсә торган гөмбәләрне һәм үсемлекләрне, шулай ук «Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» 1998 ел, 8 гыйнвар, № 3-ФЗ федераль закон нигезендә наркотик чаралар дип танылган кыргый үләннәрне һәм гөмбәләрне әзерләү һәм җыю тыела.

Урман кишәрлекләрен азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен арендалаучы гражданнар һәм юридик затларның хокуклары:

1) урманнардан аренда шартнамәсе шартлары нигезендә файдалануны гамәлгә ашыру;

2) зарурлык туганда урман инфраструктурасы төзү (урман юллары, урман саклыкханәләре һәм башкалар);

3) бирелгән урман кишәрлекләрендә киптергечләр, гөмбә кайнаткычлар, саклыкханәләр һәм башка вакытлы корылмалар урнаштырырга;

4) әгәр аларны тормышка ашыру Россия Федерациясенең урман законнары таләпләренә каршы килмәсә, башка хокукларга ия булу.

Урман кишәрлекләрен азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен арендалаучы гражданнарның һәм юридик затларның бурычлары:

1) Россия Федерациясе Урман кодексының 88 статьясының 1 өлеше нигезендә урманнарны үзләштерү проектын төзергә;

2) урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе шартларын үтәү;

3) Россия Федерациясе Урман кодексының 55 статьясының 1 өлеше 4 пункты нигезендә санитар-савыктыру чараларын гамәлгә ашырырга (һәлак булган һәм зыян салынган урман утыртмаларын кисәргә, урманнарны чүп-чардан, пычранудан һәм башка төрле тискәре йогынтылардан чистартырга);

4) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 ел, 30 июнь, № 417 карары белән расланган Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең 13 пунктындагы таләпләрне үтәргә.

5) Россия Федерациясе Урман кодексының 26 статьясының 2 өлеше нигезендә ел саен урман декларациясе тапшырырга;

6) Россия Федерациясе Урман кодексының 49 статьясының 1 өлеше нигезендә урманнардан файдалану турында хисап тапшырырга;

7) Россия Федерациясе Урман кодексының 60 статьясының 1 өлеше нигезендә урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшырырга;

8) Россия Федерациясе Урман кодексының 91 статьясының 2 өлешендә каралган документлаштырылган мәгълүматларны билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Урман кодексының 91 статьясының 4 өлеше нигезендә дәүләт урман реестрына тапшырырга;

9) Россия Федерациясе законнарында каралган башка вазыйфаларны үтәү.

### 2.4.1. Урманнардан азык-төлек урман ресурсларын һәм дару үләннәрен төрләре буенча әзерләү һәм җыеп алу өчен файдалану нормативлары (ел саен рөхсәт ителгән күләмнәре) һәм параметрлары

Азык-төлек урман ресурслары әзерләгәндә һәм дару үләннәре җыйганда ел саен урманнардан рөхсәтле файдалануның рөхсәт ителгән күләмнәре 13 таблицада китерелде.

13 таблица

Азык-төлек урман ресурсларын әзерләгәндә һәм дару үләннәрен җыеп алганда урманнардан файдалану параметрлары

| № п/п | Азык-төлек урман ресурсларының, дару үләннәренең төре | Үлчәү берәмлеге | Әзерләүгә ел саен рөхсәт ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Азык-төлек ресурслары | | | |
| 1. | Җиләкләр: нарат җиләге | т | – |
| | мүк җиләге | т | – |
| | күк җиләк | т | – |
| | кура җиләге | т | 1,5 |
| | җир җиләге | т | 0,5 |
| | кара җиләк | т | – |
| | кызыл бөрлегән | т | – |
| | миләш, шомырт | т | 3,0 |
| | ҖӘМГЫСЕ: | т | 5,0 |
| 2. | Гөмбәләр: ак | т | 1,0 |
| | майлы | т | 10,0 |
| | ал гөмбә | т | 10,0 |
| | кызыл гөмбә | т | 5,0 |
| | каен гөмбәсе | т | 5,0 |
| | гөреҗдәләр | т | 2,0 |
| | этәч гөмбәсе | т | – |
| | баллы гөмбә | т | 10,0 |
| | ҖӘМГЫСЕ: | т | 42,0 |
| 3. | Агач сутлары: каен | т | 150,0 |
| Дару чималы | | | |
| 4. | Сары мәтрүшкә, икеөйле кычыткан, ландыш, аю табаны, дару ромашкасы, акбаш, эт тигәнәге, канлы үлән, песи үләне, сәдәп гөле, лапчатка, үги ана яфрагы, кыр наратбашы һ.б. | т | 0,13 (коры хәлендә) |
| 5. | Чага гөмбәсе | т | 1,0 |

Җиләкләрнең, гөмбәләрнең һәм дару чималларының 60% кадәр өлеше җирле халык тарафыннан үзләштерелә.

## 2.4.2. Кыргый үсүче җимеш-җиләкләрне әзерләү һәм җыю сроклары

Кыргый җимешләр һәм җиләкләр әзерләү катгый рәвештә билгеләнгән вакытларда гамәлгә ашырыла.

Кыргый җимешләрне һәм җиләкләрне әзерләү чорлары уңышның массакүләм өлгерү вакыты җитүгә бәйле.

Җимеш бирә торган агачларны кисү һәм җимешләр әзерләү өчен ботакларны кискәләү тыела.

Чикләвек әзерләү.

Чикләвек әзерләү ысуллары урман кишәрлегенең аренда шартнамәсендә күрсәтелә.

Чикләвек әзерләгәндә агачларны һәм куаклыкларны кисү, шулай ук агачларга һәм куаклыкларга зыян сала торган ысуллардан файдалану рөхсәт ителми.

Чикләвек әзерләү өчен урман кишәрлекләре арендага тапшырылган гражданнар, юридик затлар чикләвек бирүче утыртмаларның саклыгын тәэмин итә.

Гөмбәләрне әзерләү аларның ресурсларын саклауны тәэмин итүче ысуллар белән башкарылырга тиеш.

Аеруча таралган гөмбә төрләре, аларны җыеп алу вакыты һәм урыннары 13.1 таблицада күрсәтелде.

13.1 таблица.

Аеруча таралган гөмбә төрләре, аларны җыеп алу вакыты һәм урыннары

| Аталышы (гөмбә) | Җыеп алу вакыты | Җыеп алу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Җөйле гөмбәләр | Апрель-май | Агачлары киселгән, янгын чыккан, комлы туфраклы нарат урманнарында |
| Кәҗә гөмбәләре | Апрель-май | Нарат һәм яфраклы токым урманнарында, куаклыкларда |
| Ак гөмбә | Июнь-сентябрь | Нарат, чыршы, каен һәм имән урманнарында |
| Сары гөмбә | Август-сентябрь | Нарат һәм сирәк шытып чыккан чыршы урманнарында |
| Ал гөмбә | Июнь-октябрь | Барлык урманнарда, ләкин яфраклы урманнарда күбрәк |
| Каен гөмбәсе | Июнь-октябрь | Каен булган бөтен җирдә үсә |
| Кызыл гөмбә | Июль-сентябрь | Яшь усак урманнарында һәм усак катнашмалы катнаш урманнарда |
| Майлы гөмбә | Июнь-октябрь | Нарат урманнарында һәм яшь вак нарат урманнарында (культураларда) |
| Моховик | Июнь-сентябрь | Сай торфлы-комлы туфраклардагы нарат урманнарында |
| Баллы гөмбә | Август-октябрь | Нарат һәм яфраклы токым, аеруча зирек түмәрләрендә |
| Әтәч гөмбәсе | Июнь-сентябрь | Каен, ылыслы һәм катнаш урманнардагы дымлы урыннарда |
| Валуй | Июль-октябрь | Барлык урманнарда |
| Гөреҗдә | Июль-октябрь | Яфраклы һәм юкә белән чикләвек куаклыклары катнашкан урманнарда |
| Дуңгыз гөмбәсе | Июнь-октябрь | Ылыслы һәм яфраклы урманнарда урман кырыйларында, юл буйларында, паркларда |
| Йөнтәс гөмбә | Июль-октябрь | Катнаш һәм каен урманнарында |
| Ачы гөмбә | Май-октябрь | Нарат урманнарындагы дымлы урыннарда |
| Шампиньон | Июль-сентябрь | Яшелчә, җиләк-җимеш бакчаларында, паркларда, болыннарда, көтүлекләрдә, чүплекләрдә |

Дару үләннәрен әзерләү үсемлекләрнең үз вакытында терелүен һәм чимал запасының яңадан үсеп чыгуын тәэмин итәрлек күләмнәрдә рөхсәт ителә.

Бер үк аланда (урман утарында) дару үләннәре чималын кабат жыю бары тик билгеле бер үсемлек төренең чимал запасы тулысынча яңадан үсеп җиткәч кенә рөхсәт ителә.

Дару үләннәренең кайсы да булса төре өчен чималны кабат әзерләү чорлары турында белешмәләр булмаганда, түбәндәгеләргә таянып эш итәргә киңәш ителә:

1) берьеллык үләннәрнең чәчәк өлеше һәм җир өстендәге органнары («үләне») бер үк аланда 2 елга бер мәртәбә әзерләнә;

2) күпьеллык үләннәрнең җир өсте органнары («үләне») – 4-6 елга бер мәртәбә;

3) күпчелек дару үләннәре төрләренең җир өсте органнары – 15-20 елга бер мәртәбәдән ешрак түгел.

Төп дару үләннәре, аларны әзерләү урыннары һәм чорлары 13.2 таблицада күрсәтелде.

13.2 таблица.

Төп дару үләннәре

| Үләннәрнең аталышы | Әзерләнә торган өлешләре | Әзерләү вакыты, ай | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Саз сазанагы | Өске яшь ботаклары, яфраклары һәм җимешләре белән бергә | Август-сентябрь | Яшь нарат утыртмалары каплаган дымлы һәм юеш урыннарда |
| Еламсар каен | Бөреләре | Март-апрель | Утыртмалары |
| Ком меңьяфрагы | Чәчәкләре | Июль-август | Болын кырыйлары, калку урыннар, ярлар, коры мүклекләр һәм ак мүклекләр һәм коры наратлыклар |
| Җете кызыл дүләнә | Чәчәкләре һәм җимешләре | Май, август-сентябрь | Утыртмалары |
| Гади нарат җиләге | Яфраклары | Апрель-май | Наратлык көртмәлекләре |
| Дарулык песи үләне | Тамыр өлеше | Апрель, сентябрь-октябрь | Көртмәлек аланнары |
| Өчъяфрак | Яфраклары | Май-август | Урман кырыйлары, болыннар, түбәнге печән чабу урыннары, дымлы урыннар |
| Елан үләне | Тамыры | Май-сентябрь | Урман кырыйлары, болыннар, түбәнге печән чабу урыннары, дымлы урыннар |
| Борычлы тау үләне | Җир өстендә үсә | Июль- | Юеш һәм дымлы каен |

| Үләннәрнең аталышы | Әзерләнә торган өлешләре | Әзерләү вакыты, ай | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | торган өлеше | сентябрь | утыртмалары, түбәнлектәге сазлык, сазланган печәнлекләре |
| Язгы утчәчәк | Җир өстендә үсә торган өлеше | Май-сентябрь | Дымлы сирәкләнгән утыртмалар, үзәннәрдәге болыннар |
| Биек сары чәчәк | Тамыр өлеше | Май, сентябрь | Дымлы урман кырыйлары, үзәннәр, аланнар |
| Дарулык кандала | Чәчәк ату чорында үсемлекнең өске өлеше | Июнь-июль | Коры болыннар, көтүлекләр, ярлар |
| Гади нарат | Кайрысы | Апрель-июль | Утыртмалары |
| Дарулык сыбызгы үлән | Чәчәк атмаучы нөсхәләренең тамыр өлешләре | Апрель, сентябрь-октябрь | Үзәнлекләр, елга буйларындагы утыртмалар |
| Гади мәтрүшкә | Үләне | Июль-август | Ачык урыннар, печәнлекләр, яфраклы урманнар |
| Эч йомшарта торган эт шомырты | Җимешләре | Август-сентябрь | Ачык урыннар, печәнлекләр, яфраклы урманнар |
| Тишек яфраклы сары мәтрүшкә | Үләне | Июль-август | Ачык урыннар, печән чабу җирләре. Урман аланлыклары һәм болыннар |
| Ак алтынбаш | Үләне | Июль-август | Ачык урыннар, печән чабу җирләре. Урман аланлыклары һәм болыннар |
| Гади балан | Кайрысы, җимешләре | Август-сентябрь | Үзәнлекләр, урман авызлары |
| икеөйле кычыткан | Яфраклары | Май-сентябрь | Үзәнлекләр, бушлыклар, дымлы һәм юеш урыннарда сирәкләнгән урманнар |
| Дарулык кан үләне | Тамыр өлеше | Август-сентябрь | Үзәннәрдәге сирәкләнгән урыннар, болыннар |
| Зирексыман эт шомырты | Кайрысы | Март-май | Елга буйларындагы һәм ярлардагы яфраклы урманнар |
| Сары эт шомырты | Тамыры | Май-октябрь | Сулыклар |
| Май ландышы | Чәчәк ату чорында үләне | Май-июнь | Яфраклы һәм катнаш урманнар |
| Калган | Тамыры | Апрель, сентябрь-октябрь | Яфраклы урманнар, аланлыклар |
| Вак яфраклы юкә | Чәчәкләре | Июнь-июль | Утыртмалары |
| Үги ана яфрагы | Яфраклары | Май-июль | Сазланган печәнлек урыннары |
| Гади кура | Җимешләре | Июль-август | Агач киселгән урыннар, сирәкләнгән утыртмалар |
| Гади артыш | Күркәсе-җимешләре | Сентябрь-октябрь | Ылыслы утыртма куакларында |

| Үләннәрнең аталышы | Әзерләнә торган өлешләре | Әзерләү вакыты, ай | Әзерләү урыны |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Дарулык тузганак | Тамырлары | Май-октябрь | Печәнлекләр, көтүлекләр, ташландык урыннар, аланлыклар |
| Соры зирек | Тәлгәшләре | Август-октябрь | Елгалар буенда үсүче утыртмаларда |
| Гади гөлбадран | Чәчәкләре | Июль-сентябрь | Сирәкләнгән үләнле наратлыклар, аланлыклар, болыннар |
| Зур көтүче яфрагы | Яфраклары | Июль-сентябрь | Юллар буенда, аланнарда, болыннарда |
| Ачы әрем | Өске чәчәк атучы өлеше, яфраклары | Июнь-август | Тик яткан урыннар, юллар, ташландык урыннар |
| Сукыр кычыткан | Үләне | Июнь-август | Юл, яр буйларында, ташландык урыннарда |
| Гади миләш | Җимешләре | Сентябрь-октябрь | Яфраклы һәм катнаш урманнар |
| Кара карлыган | Җимешләре, яфраклары | Май-август | Елга тугайлары |
| Гади нарат | Бөреләре, ылысы | Май-октябрь | Ылыслы диләнкеләр |
| Коры үлән | Үләне | Июнь-август | Аланнар, ачыклыклар, сазлы болыннар |
| Гади әнис | Җимешләре | Июль-август | Болыннар, елга буйлары |
| Гади турак уты | Яфраклары | Май-сентябрь | Коры наратлыклар |
| Гади меңьяфрак | Җир өстендәге өлеше (үләне) | Май-август | Агач киселгән урыннар, аланнар, ачыклыклар, печәнлекләр |
| Өч чәчәкле миләүшә | Җир өстендәге өлеше (үләне) | Май-август | Урман авызлары, аланнар, урман юллары |
| Кыр наратбашы | Үләне | Май-сентябрь | Үзәнлекләр, урман авызлары |
| Чага (каен гөмбәсе) | Орылары | Гыйнвар-декабрь | Каен утыртмалары |
| Лобель аксыргагы | Тамыр өлеше | Май-сентябрь | Үзәнлекләр, түбәнлектәге көтүлекләр һәм печәнлекләр |
| Өч өлешле эт тигәнәге | Үләне | Май-сентябрь | Дымлы елга ярлары, печәнлекләр |
| Гади шомырт | Җимешләре | Июль-сентябрь | Елга тугайлары |
| Зур канлы үлән | Үләне | Май-август | Диләнкеләр, чүп үләне үскән урыннар |
| Коңгырт гөлҗимеш | Җимешләре | Август-сентябрь | Сирәкләнгән урманнар, киселгән урыннар |

### 2.4.3. Агач сутлары әзерләгәндә нормативлар һәм параметрлар

Каен суты әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә 5 елдан да ким булмаган вакыт кала рөхсәт ителә.

Каен сутын әзерләү агач материалының техник үзлекләрен саклауны тәэмин итә торган ысуллар белән башкарылырга тиеш, бу вакытта сайланма кисүләр уздырыла, кисүгә билгеләнгән агачлардан рөхсәт ителә.

Кисеп җибәрү өчен тулылыгы кимендә 0,4 һәм бер гектарга кимендә 200 данә агачлы, бонитетның I-III классларына караган урманның сәламәт өлеше сайлап алына. Кисеп җибәргәндә күкрәк биеклегендәге диаметры 20 см һәм аннан да юанрак булган агачларны билгелиләр.

Агач тамыры башланган җирдән 20-35 см биеклектә канал бораулау эшләрен башкаралар. Агачта бер һәм аннан да күбрәк кирт салу тишекләре ясалган очракта, алар кәүсәнең бер ягында бер-берсеннән, сут бер савытка агып төшәрлек итеп, 8-15 см ераклыкта урнаштырыла.

Агач диаметрына карап, бораулана торган каналларның сан нормативлары13.3 таблицада китерелде.

13.3 таблица.

Агач кәүсәсенең диаметрына карап, бораулана торган каналларның сан нормативлары

| Агачның күкрәк биеклегендәге диаметры, см | Кирт салганда каналлар саны | Искәрмә |
|---|---|---|
| 20-22 | 1 | Диаметры 16 см булган агачларга кисәргә бер ел калгач кирт салу рөхсәт ителә, түбәндәгечә басым нормалары булганда:<br>16-20 см – 1 канал<br>21-24 см – 2 канал<br>25 см һәм күбрәк – 3 канал |
| 23-27 | 2 | |
| 28-32 | 3 | |
| 33 һәм аннан күбрәк | 3 | |

Кирт салу чоры тәмамланганнан соң, агачларның чирләп китүен кисәтү максатларында, тишекләр сагыз пастасы белән сылап куелырга яисә агач бөке белән ябылырга һәм вар, бакча замазкасы яисә известьлы балчык белән сылап куелырга тиеш.

Калган елларда каналлар беренче елгы кисеп җибәрү каналлары дәрәҗәсендә 10 см интервал белән агач кәүсәсе әйләнесенең теге яисә бу ягына таба бораулана.

Әзерләү агачның техник сыйфатларын саклап калырлык итеп гамәлгә ашырылырга тиеш.

Абага-кара абага әзерләү

Абаганың яшь ботакларын әзерләү аларның үрентеләренә зыян китермәслек алымнар белән гамәлгә ашырылырга тиеш. Абаганы тамыры белән йолкып алу, яфракларына һәм тамыр үзәгенә зыян китерү тыела.

Кара абага-абага очында иң күбе өчтән артмаган, «өчәрләнгән» дип аталучы, ачылмаган яфраклары булган, бөтенлекле, зыян китерелмәгән яшь ботагы ашарга яраклы дип санала.

Җыярга яраклы яшь ботакларының оптималь биеклеге – әзерләү районына һәм үсү шартларына карап, 20-25 см алып 30-40 см кадәр. Шытымнарын нигезеннән үк ваклыйлар.

Урман абагасы чималын әзерләү бер үк кишәрлектә 3-4 ел буена алып барыла. Аннары үсентеләр торгызылсын өчен тәнәфес ясарга кирәк: чималны бер мәртәбә җыйганда (бер чорга) – 2-3 ел, ике мәртәбә – 3-4 ел.

### 2.4.4. Абага-кара абага әзерләү

Кыр сарымсагын, кузгалак, кара абаганың яшь ботакларын әзерләү аларның үсентеләренә зыян китермәслек алымнар белән гамәлгә ашырылырга тиеш. Абаганы тамыры белән йолкып алу, яфракларына һәм тамыр үзәгенә зыян китерү тыела.

Кара абага-абага очында иң күбе өчтән артмаган, «өчәрләнгән» дип аталучы, ачылмаган яфраклары булган, бөтенлекле, зыян китерелмәгән яшь ботагы ашарга яраклы дип санала.

Җыярга яраклы яшь ботакларының оптималь биеклеге – әзерләү районына һәм үсү шартларына карап, 20-25 см алып 30-40 см кадәр. Шытымнарын нигезеннән үк ваклыйлар.

### 2.4.5. Урманнардан азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу өчен файдалану чорлары

Дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттә торган урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе РФ УК 72 ст. 3 өл. нигезендә урманнарны азык-төлек урман ресурсларын әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу өчен файдалану максатларында, РФ УК 36, 43-46 ст., 73.1 ст. 3 өл. 3 п. каралган очраклардан тыш, тугыз елдан кырык тугыз елга кадәрге чорга төзелә.

Урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе срогы урман хуҗалыгы регламентында урманнардан файдалану буенча каралган срокка туры китереп билгеләнә.

## 2.5. Урманнардан аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Аучылык хуҗалыгы кыргый хайваннарның популяцияләре белән рациональ идарә итү һәм ел саен продукция алу рәвешендә урманнардан комплекслы файдалануга үз өлешен кертә.

Ау «Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 24 июль, № 209-ФЗ федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнардан аучылык хуҗалыгы алып бару һәм ауны гамәлгә ашыру өчен файдалану РФ УК 25, 36 статьялары белән регламентлана.

Урманнардан аучылык хуҗалыгын алып бару өчен файдалануны хокукый җайга салу Россия ТРЭМның «Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану кагыйдәләрен һәм Урман кишәрлекләрен бирмичә аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану очраклары исемлеген раслау турында» 2017 ел, 12 декабрь, № 661 боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Аучылык биләмәләре чикләренә хокукый режимында аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен башкару рөхсәт ителә торган җирләр кертелә.

Аучылык биләмәләре түбәндәгеләргә бүленә:

1) федераль законнарда каралган нигезләрдә юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан файдаланыла торган аучылык биләмәләре (алга таба – беркетелгән аучылык биләмәләре);

2) ау максатларында физик затлар ирекле йөри алу хокукына ия булган аучылык биләмәләре (алга таба – гомуми файдаланудагы аучылык биләмәләре).

Гомуми файдаланудагы аучылык биләмәләре Россия Федерациясе субъектындагы аучылык биләмәләренең гомуми мәйданында кимендә егерме процентын тәшкил итәргә тиеш.

Аучылык биләмәләре ауның бер яки берничә төрен гамәлгә ашыру өчен кулланылырга мөмкин.

### 2.5.1. Биотехник чаралар исемлеге һәм аларны үткәрү нормалары

Ел саен үткәрелә торган биотехник чаралар күләме 13.4 таблицада китерелде.

13.4 таблица

Аучылык хуҗалыгын алып барганда урманнардан файдалану параметрлары

| № п/п | Чараларның төрләре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен рөхсәт ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Куяннар өчен ашату мәйданнары ясау | данә | 100 |
| 2. | Пошилар, кыр кәҗәләре өчен җимлекләр урнаштыру | данә | 45 |
| 3. | Пошилар, кабан дуңгызлары, куяннар өчен тоз салынган катырлар урнаштыру | данә/кг | 140/2,7 |
| 4. | Пошины, кыр кәҗәсен, куяннарны ашату өчен усак, тал кисү | кбм | 100 |
| 5. | Аучы манаралары урнаштыру | данә | 3 |

| № п/п | Чараларның төрләре | Үлчәү берәмлеге | Ел саен рөхсәт ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 6. | Ашату өчен печән әзерләү | тонна | 11,5 |
| 7. | Суерлар һәм божырлар өчен чуер ташлыклар кору | данә | 30 |
| 8. | Гөрелдәвекләр кору | данә | 30 |
| 9. | Кабан өчен ашату кырлары ясау | га | 3 |
| 10. | Ауны чикли һәм тыя торган аншлаглар, күрсәткечләр урнаштыру | данә | 40 |

## 2.5.2. Аучылык инфраструктурасы урнаштыру өчен рөхсәт ителгән объектлар исемлеге

Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалануга урман кишәрлекләре бирелгән затларның хокуклары:

а) урманнарны үзләштерү проектына уңай дәүләти яисә муниципаль экспертиза алганнан соң һәм урман декларациясен тапшырганнан соң урман кишәрлегеннән файдалануга керешү;

б) урман законнары һәм аучылык өлкәсе һәм аучылык ресурсларын саклау законнары таләпләренә туры китереп, урман кишәрлегендә урман инфраструктурасы һәм аучылык инфраструктурасы булдыру;

в) ау өлкәсендә һәм аучылык ресурсларын саклау законнары таләпләренә туры китереп, аучылык ресурсларын карап тоту һәм ярымирекле шартларда һәм ясалма рәвештә булдырылган тереклек итү тирәлегендә үрчетү.

Ау хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урман кишәрлекләре бирелеп, урманнардан файдаланучы затларның бурычлары:

а) урман кишәрлегеннән Урман кодексына, Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларына, урман хуҗалыгы регламентына, урманнарны үзләштерү проектына һәм урман кишәрлегенең аренда шартнамәсенә туры китереп файдалану;

б) урман кишәрлегенең аренда шартнамәсендә билгеләнгән күләмнәрдә һәм срокларда урман кишәрлегеннән файдаланган өчен аренда түләвен кертү;

в) РФ Урман кодексының 88 статьясының 1 өлеше нигезендә урманнарны үзләштерү проектын төзү;

г) РФ Урман кодексының 26 статьясының 2 өлеше нигезендә ел саен урман декларациясен тапшыру;

д) РФ Урман кодексының 49 статьясының 1 өлешендә, 60 статьясының 1 өлешендә, 60.11 статьясының 1 өлешендә, 66 статьясының 1 өлешендә каралган белешмәләрне тапшыру;

е) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән урман кишәрлегендә янгынга каршы корылыш буенча РФ Урман кодексының 53.1 статьясының 2 өлешендә каралган чараларны гамәлгә ашыру;

ж) зарарлы организмнар таралуын кисәтү буенча РФ Урман кодексының 60.7 статьясының 1 өлешендә каралган чараларны гамәлгә ашыру;

з) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урманнан файдаланучы зат гаебе белән өске уңдырышлы туфрак катламына, ясалма һәм табигый су чыганакларына, елгаларга, чишмәләргә зыян салынган очракта яисә юкка чыгарылганда, аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен башкару өчен бирелгән урман кишәрлеген элеккеге, максатчан билгеләнеше буенча кулланырга яраклы торышына кайтару;

и) урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен туктаткан очракта, урман кишәрлеген урман кишәрлегенең аренда шартнамәсендә каралган торышында арендага бирүчегә кайтарып бирү;

к) урман законнарында, ау һәм аучылык ресурсларын саклау өлкәсендәге законнарда, ау хуҗалыгы килешүендә һәм урман кишәрлегенең аренда шартнамәсендә каралган бүтән вазыйфаларны башкарырга, – ау хуҗалыгы өлкәсендәге хокуклар һәм вазыйфалар РФ ТРЭМның 2017 ел, 12 декабрь, №661 боерыгында беркетелгән.

## 2.6. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану аларның урнашкан җирләренең билгеләнеше белән аңлатыла, бу эш урман фонды җирләрендә бары тик урман хуҗалыгы мәнфәгатьләренә туры килгәндә генә рөхсәт ителә, РФ УК 38 статьясы белән регламентлана, шул ук вакытта, авыл хуҗалыгында җитештерү дип авыл хуҗалыгы продукциясен, чималын һәм азык-төлеген үстерү генә түгел, аны җитештерү, эшкәртү буенча икътисадый эшчәнлек төрләре җыелмасы да санала. («Авыл хуҗалыгын үстерү турында» 2006 ел, 29 декабрь, № 264-ФЗ федераль законның 4 ст.).

Авыл хуҗалыгында җитештерүгә гадәттә авыл хуҗалыгы чималын беренчел эшкәртү генә кертелә. Сәнәгатьтә эшкәртү авыл хуҗалыгында җитештерү дип санала алмый.

Шушы максатта, РФ УК 38 статьясының 2 өлеше нигезендә авыл хуҗалыгын алып бару өчен бирелгән урман кишәрлекләрендә умарта оялары һәм чүнникләр урнаштыру, коймалар торгызу, әвеслекләр һәм башка төрле вакытлы корылмалар, шул исәптән товарлык аквакультура (товарлык балыкчылык) башкару өчен билгеләнгәннәрен дә, ясау рөхсәт ителә.

Әлеге норма авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану кысаларында авыл хуҗалыгы продукциясен сәнәгатьтә эшкәртүне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирми, еш кына хәтта беренчел эшкәртергә дә.

Капиталь төзелеш объектларын төзергә кирәк булганда авыл хуҗалыгы товар җитештерүчесенә урманнардан авыл хуҗалыгы максатлары өчен генә түгел, ә агач материалы һәм башка төрле урман ресурсларын эшкәртү өчен дә урманнардан файдалану таләп ителә (РФ УК 46 ст.).

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдаланганда алынган продукция бер үк вакытта урман ресурсы булып та саналырга мөмкин.

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалану урманчылык территориясендә түбәндәгеләр тарафыннан гамәлгә ашырыла:

1) гражданнар, шул исәптән әйдәүче крестьян (фермер) хуҗалыклары, бакчачылык, яшелчәчелек, терлекчелек белән шөгыльләнүче шәхси ярдәмче хуҗалыклар;

2) хуҗалык итүче ширкәтләр һәм җәмгыятьләр, җитештерү кооперативлары, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, бүтән коммерция оешмалары;

3) коммерциясез оешмалар, шул исәптән кулланучылар кооперативлары, дини оешмалар.

Авыл хуҗалыгы алып бару өчен гражданнар, юридик затлар урманнардан урман кишәрлекләренең аренда шартнамәләре нигезендә файдалана.

Шәхси ихтыяҗлар өчен урман хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыру (шул исәптән умартачылык) максатларында җир кишәрлекләре гражданнарга түләүсез нигездә файдалануга тапшырыла яисә Россия Федерациясе Җир кодексында һәм Россия Федерациясе Граждан кодексында билгеләнгән очракларда сервитут билгеләнә.

Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләре РФ ТРЭМның «Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2017 ел, 21 июнь, № 314 боерыгы белән билгеләнә.

Әлеге Кагыйдәләрдә авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалануның теләсә кайсы төренә кагыла торган гомуми нигезләмәләр һәм урманнарда алып барыла торган авыл хуҗалыгы эшчәнлегенең аерым төрләрен билгеләүче махсус таләпләр бар.

Авыл хуҗалыгы алып бару тыела:

су саклау зонасында урнашкан урманнарда, печән чабу һәм умартачылыктан гайре;

урман паркы зоналарында;

яшел зоналарда, печән чабу белән умартачылыктан гайре. Яшел зоналарда шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында корылмалар торгызу тыела;

шәһәр урманнарында;

тыюлыклы урман кишәрлекләрендә;

Россия Федерациясе Урман кодексының 107 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән махсус яклanучы урман кишәрлекләрендә, печән чабу һәм умартачылыктан гайре.

Яклагыч полосаларның яр буе чикләрендә җирләрне казу, авыл-хуҗалыгы терлекләрен көтү һәм алар өчен җәйге аланнар, ванналар оештыру тыела.

## 2.6.1. Печән чабу, авыл хуҗалыгы терлекләре көтү, умартачылык, төньяк боланчылык, марал үрчетү, авыл хуҗалыгы культуралары үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеге, балыкчылык мөмкин булган урман кишәрлекләре мәйданнары турында белешмәләр, шулай ук тиешле нормативлар

*Печән чабу*

Печәнлекләрне классификациялэгәндә түбәндәгеләр билгеләнә: печәнлекләрнең тибы (су баса торган, коры җирдәге, сазланган), табигыймы ул яисә яхшыртылганмы, агач-куаклар басып китү дәрәҗәсе, печән әзерләүне кыенлаштыра торган факторлар, үләннең төп төрләре, аның проектив капламы, куелыгы, уңышлылыгы, сыйфаты. Печәнлекләр мәйданының 20%ын агач-куаклар басып алган булса, ул агач-куак басып киткән дип, 20%тан артыгын түмгәкләр каплаган булса – түмгәкле дип, табигый һәм чәчелгән үләннәр каплап алган булса – яхшыртылган печәнлекләр дип санала, анда үләннәрне механика ярдәмендә җыярга мөмкин.

Печән уңышын бәяләү:

10 ц/га һәм аннан да күбрәк – яхшы,

6-9 ц/га – уртача,

1-5 ц/га – начар.

*Печән чабу җирләрен бәяләү.*

Печәнлекләр өчен түбәндәгеләр кулланыла:

урман утыртылмаган диләнкеләр, ачыклыклар һәм урман җире капламаган һәм урман культуралары утыртып, урманнарны торгызу мөмкин булмаган җирләр;

яхшыртуга мохтаҗ, печән чабу өчен яраклы җирләр;

реконструкция өчен билгеләнмәгән, кыйммәте аз булган урман үрентеләре кишәрлекләре.

13.5 таблица.

Печән чабу җирләренә сыйфатлама

| Печән чабу тибы | Урнашу урыны | Үләне | Печән чабу чорының тип сыйфаты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Вакытлыча дымы артып киткән коры җирләр | Сизелер-сизелмәс субүлү урыннары | Карчыга үләне, тубылгы, гравилат, тузгак кылган, башаклы үлән, түмәрлек, эт үләне, бөтнек | Уртача |
| Коры үзәнлекле, үзәнлекле-чокырлы | Кече елга үзәннәре, үлән баскан тар яр сөзәкләре һәм төбе тигез булмаган уйсулыклар | Тимофеевка, солыча, кылчыклы үлән, төлке койрыгы, бөтнек | Яхшы |
| Түбән уртача-артык | Киң үзән ясаучы түбәнлекләр | Кыяклы, башаклы үлән, кузаклылар | Уртача |

| Печән чабу тибы | Урнашу урыны | Үләне | Печән чабу чорының тип сыйфаты |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| дымланган | | | |
| Сазлыкланган түбәнлекләр | Грунт сулары якын булган сазлыкланган түбәнлекләр | Дым яратучы кыяклылар, эре башаклы үләннәр | Начар |

## Урманнардан авыл хуҗалыгы терлекләрен көтү өчен файдалану

*Терлек көтү җирләрен исәпкә алу.*

Махсус саклanучы табигать территорияләрендә, су саклау зоналарында, яшел зоналарда, эрозиягә каршы урманнарда һәм махсус якланучы кишәрлекләрдә урнашкан урманнардан кала, бөтен урманнарда да терлек көтү рөхсәт ителә.

Терлек көтү түбәндәгеләрдә рөхсәт ителми:

үсемлек очларына терлек буе җитмәслек булганчы (1.5-2.0 м) урман культуралары кишәрлекләрендә;

урман орлыклары үстерү, чыршы, тал, тирәк һәм чикләвек плантацияләрендә;

табигый торгызуга ярдәм итү чаралары уздырыла торган кишәрлекләрдә;

очларына терлек буе җитмәслек булганчы (1.5-2.0 м.) яшь урман утыртмаларында;

ылыслы һәм каты яфраклы токымнарны торгызу өчен билгеләнгән, урман утыртмалары белән капланмаган җирләрдә;

су һәм җир эрозиясе белән зарарлаган җирләрдә.

Авыл хуҗалыгы терлекләренең хуҗалары түбәндәгеләрне тәэмин итә:

урман культураларын, питомникларны, үзе шытып чыккан яшь урман үрентеләрен һәм башка кыйммәтле урман кишәрлекләрен зарарламас өчен киртәләп ала;

авыл хуҗалыгы терлекләрен көтүче көтә (коймалы көтүлекләрдән һәм бәйләп куюдан гайре).

Кәҗә көтү бары тик авыл хуҗалыгы терлекләренең хуҗалары тарафыннан алдан киртәләнгән урман кишәрлекләрендә һәм бәйләгән килеш кенә рөхсәт ителә.

*Көтүлек категорияләре һәм аларның азык продуктлылыгы*

Көтүлекләрне төрләргә бүлгәндә, төбәк шкалаларыннан файдаланып, үләннәрнең проект капланышын, төп төрләрен, аның куелыгын, өстенлек итүче үсемлек төрләрен һәм аларның сыйфатын күрсәтәләр. Алар булмаганда түбәндәгеләргә нигезләнергә мөмкин:

яхшы җирләр – яхшыртылган һәм су баса торган, кузаклы-бөртекле компонентлар (60% һәм аннан да күбрәк) өстенлек итүче кишәрлекләр; үләннең проект капламы – 60% һәм аннан да күбрәк;

начар җирләр – табигый һәм каты сабаклы үлән басып алган (60% аннан да күбрәк) (эре башаклы үлән, камышлык, ситник) кишәрлекләр; башка үлән компонентларының проект капламы 50%ка кадәр.

13.6 таблица.

Терлек көтүнең 1 баш терлеккә якынча чор нормалары, га

| Көтү территориясе | Утлавыклар саны |
|---|---|
| 0.5-0.6 тулылыктагы каен өстенлек итә торган яфраклы урманнар | 2 |
| 0,5 тулылыктагы саф каенлыклар | 1,5 |
| Көтүлек өчен яраклы башка урман утыртмалары (1 баш мөгезле эре терлеккә яисә 7 сарыкка) | 4-5 |
| Куаклыклар һәм шытымнар булмаган кисенте урыннарында | 0,75 |

*Умартачылык*

Бал бирүче бал кортлары өчен азык сыйфатында агачлары, куаклары яисә үләнле-куаклы ярусы составында бал бирә торган үләннәре булган урман кишәрлекләре кулланыла.

Умарта ояларын һәм умарталыкларны урнаштыру өчен урман кишәрлекләре иң беренче чиратта урман читләреннән, ачык урыннарда һәм урман үрентеләре капламаган башка җирләрдән бирелә.

1000нән артык төрле күпләгән сандагы чәчәк үсемлекләреннән бал кортлары нектар һәм серкә җыя. Аларның бер ишесе – беренче дәрәҗәле, икенчеләре икенче дәрәҗәле бал бирүчеләр. Алга таба аеруча киң таралган бал бирүче үсемлек төрләренә тасвирлама ясала (13.7 таблица).

13.7 таблица.

Бал бирүче үсемлекләрнең бал продуктлылыгы

| Бал бирүчеләр | Уртача чәчәк ату чорлары | | Бал продуктлылыгы, кг/га |
|---|---|---|---|
| | башлана (датасы) | продуктивлыгы (көн) | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Үги ана яфрагы | 12.04 | 30-60 | И* |
| урман чикләвеге | 20.04 | 6-9 | И* |
| Җилдәк | 20.04 | 30 | И* |
| Кызыл тал | 22.04 | 5-30 | 150 |
| Даруханә күкебашы | 23.04 | 30 | И* |
| Кәҗә талы | 28.04 | 10 | 150 |
| Бүре җиләге | 30.04 | 15 | И* |
| Үрмәләк үлән | апрель | 90 | И* |
| Үткен яфраклы өрәңге | 08.05 | 7-10 | 200 |
| Мурт тал | 10.05 | 5-10 | 150 |
| Ак тал | 11.05 | 15-20 | 150 |
| Карлыган | 20.05 | 10-20 | 50-140 |
| Шомырт | 21.05 | 12 | И* |

| Бал бирүчеләр | Уртача чәчәк ату чорлары | | Бал продуктлылыгы, кг/га |
|---|---|---|---|
| | башлана (датасы) | продуктивлыгы (көн) | |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| Сукыр кычыткан | 24.05 | 45 | 100 |
| чия | 23.05 | 10-12 | 30-40 |
| Сары сәрви | 25.05 | 10-14 | 350 |
| Алмагач | 26.05 | 10-12 | 20-30 |
| Дүләнә | май | 15 | И* |
| Нарат җиләге | май | 30 | И* |
| Татар өрәңгесе | май | 7-10 | 100 |
| миләш | май | 10 | 30-40 |
| Күгән | май | 15 | 25 |
| зелпе | май | 20 | И* |
| Гади чамбыр | май-июнь | 34 | 140 |
| Кара җиләк | май-июнь | 30 | 30 |
| Кыр шалфее | май-июнь | 30-60 | 110 |
| Мурт эт шомырты | 06.06 | 14 | 35 |
| Балан | 11.06 | 30-45 | И* |
| Урман курасы | 15.06 | 25-40 | 60-100 |
| Кырлыган | 22.06 | 45-60 | 350-400 |
| Зур яфраклы юкә | 23.07 | 14 | 500-600 |
| Ике еллык ак кандала үләне | 25.06 | 30 | 200-300 |
| җир җиләге | июнь | 20 | 10 |
| Тычкан борчагы | июнь-июль | 30-40 | 180-370 |
| Дарулык шалфей | июнь-июль | 47 | 117-133 |
| Сары кандала үләне | июнь-июль | 30-40 | 150-200 |

Искәрмә. П*– табыш алу буенча тотрыклылык тибы билгеләнде.

13.8 таблица.

Юкә чәчәк атканда җыеп алырга мөмкин булган бал, кг/га (гомуми бал продуктлылыгыннан 30%)

| Яше, ел | I-II бонитет | | III бонитет | | IV-V бонитет | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тулылыгы | | | | | |
| | 0,3-0,5 | 0,6-1,0 | 0,3-0,5 | 0,6-1,0 | 0,3-0,5 | 0,6-1,0 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 20 | 29 | 32 | 22 | 25 | 11 | 14 |
| 30 | 115 | 137 | 86 | 104 | 65 | 76 |
| 40 | 155 | 187 | 133 | 162 | 104 | 126 |
| 50 | 190 | 223 | 169 | 198 | 137 | 162 |
| 60 | 216 | 248 | 198 | 227 | 166 | 191 |
| 70 | 227 | 270 | 205 | 245 | 184 | 216 |
| 80 | 227 | 270 | 216 | 259 | 194 | 230 |
| 90 | 205 | 248 | 209 | 252 | 187 | 223 |
| 100 | 198 | 230 | 198 | 230 | 173 | 198 |

| Яше, ел | I-II бонитет | | III бонитет | | IV-V бонитет | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | тулылыгы | | | | | |
| | 0,3-0,5 | 0,6-1,0 | 0,3-0,5 | 0,6-1,0 | 0,3-0,5 | 0,6-1,0 |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| 110 | 176 | 209 | 173 | 205 | 137 | 166 |
| 120 | 162 | 190 | 155 | 184 | 115 | 137 |
| 130 | 140 | 165 | 133 | 155 | 97 | 115 |
| 140 | 126 | 148 | 112 | 133 | 83 | 97 |
| 150 | 108 | 130 | 94 | 115 | 68 | 83 |

Башка токым утыртмаларындагы юкәлекләрнең һәм юкәнең бал продуктлылыгы

13.9 таблица.

Нормаль юкәлекләрнең продуктлылыгы (Муратханов буенча)

| Яше | Утыртмаларның тулылыгы | | |
|---|---|---|---|
| | 1,0-0,8 | 0,7-0,6 | 0,5-0,3 |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 20 | 6.45 | 6.24 | 5.04 |
| 30 | 28.12 | 27.73 | 22.87 |
| 40 | 43.35 | 42.49 | 35.32 |
| 50 | 53.09 | 52.04 | 42.98 |
| 60 | 61.52 | 60.25 | 49.93 |
| 70 | 66.44 | 65.14 | 54.03 |
| 80 | 59.04 | 67.25 | 56.05 |
| 90 | 67.29 | 65.96 | 54.50 |
| 100 | 62.11 | 60.65 | 50.57 |
| 110 | 55.49 | 54.24 | 45.13 |
| 120 | 48.72 | 47.71 | 39.57 |
| 130 | 41.30 | 40.43 | 33.67 |
| 140 | 35.18 | 34.47 | 28.63 |
| 150 | 30.08 | 29.34 | 24.46 |

Төрле утыртмалар составындагы юкәнең бал бирүчәнлеген хисаплау буенча түбәндәге формула тәкъдим ителә:

$M = N x\ 0.1 K x C x S$,

биредә

N – 1 гектарга карата бал продуктлылыгы (табл.);

K – утыртмалар составында юкә коэффициенты;

C – юкәнең чәчәк ату озынлыгы, көннәр (14 көнгә тигез кабул ителә);

S – бүлемтек мәйданы.

Гомуми мөмкин булган нектар запасын билгеләгәндә бал кортларының нектарның иң күбе 30%ын гына җыеп алуын исәпкә алырга кирәк.

Тагын шунысын да искәртергә кирәк, районнарда нектар пробалары сайлап алу һәм үсемлекләрнең һәм биләмәләрнең бал продуктлылыгын ачыклау белән берлектә алып барылучы умарталык кишәрлекләренең бал продуктлылыгын

исәпләү эше, – бары тик фәнни хезмәткәрләр яки шушы максатлар өчен әзерләнгән эзләнү экспедицияләре белгечләре тарафыннан гына башкарылырга мөмкин булган, гаҗәеп рәвештә бик катлаулы хезмәт.

*Авыл хуҗалыгы культуралары үстерү*

Авыл хуҗалыгы культуралары үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеге алып бару өчен, аларда урман торгызу эшләрен үткәргәнчегә кадәр, урманныкы булмаган җирләр, шулай ук урман утыртылмаган диләнкеләр, ачык урыннар һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр файдаланыла.

Авыл хуҗалыгы культуралары үстерү һәм башка төрле авыл хуҗалыгы эшчәнлеген алып бару өчен кулланыла торган урман кишәрлекләрендә химик һәм биологик препаратлар «Пестицидлар һәм агрохимикатлар белән сак эш итү турында» 1997 ел, 19 июль, № 109-ФЗ федераль закон нигезендә кулланыла.

Әлеге өлештә авыл хуҗалыгы алып бару өчен урманнардан файдалануның гамәлдәге хокукый җайга салынышына урманнарда авыл хуҗалыгы эшчәнлеген гамәлгә ашыручы затларга түбәндәге бурычлар йөкләнү турындагы нормалар өстәмә булып санала:

1) гражданнарның сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян салынуга юл куймау;

2) урманнардан файдаланганда туфрак эрозиясен туктату, урманнарның торышына һәм аларны торгызуга карата, шулай ук су һәм башка төрле объектларга тискәре йогынтыны булдырмау яисә чикләү.

Урманчылык территориясендә төньяк боланчылык, марал үрчетү, балыкчылык гамәлгә ашырылмый.

## 2.6.2. Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану параметрлары

14 таблица

Урманнардан авыл хуҗалыгы алып бару өчен файдалану параметрлары

| № п/п | Файдалану төрләре | Берәмлек бер. | Ел саен рөхсәт ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Сөрүлектән файдалану | га | 51 |
| 2. | Печән чабу | га | 413 |
| 3. | Терлек көтү | | |
| | а) урманда | мең га/баш | 27,9 / 5580 |
| | н) утлавыкларда | га/баш | 142 / 570 |
| 4. | Умартачылык | | |
| | а) бал бирүчеләр: | | |
| | – юкә | га | 9050 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | – үләннәр | га | 1277 |
| | б) бал продуктлылыгы, шул исәптән: | | |
| | – юкә | кг/га | 300 |
| | – үләннәр | кг/га | 100 |
| | в) умарта оялары күләмен тәэмин итү мөмкинлеге | күләме | 480 |

## 2.7. Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Россия Федерациясе урман законнары нигезендә фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга, башка фәнни оешмаларга, белем бирү оешмаларына арендага бирелә.

Урман кишәрлекләрендә урманнарны, табигатьнең бүтән компонентларын өйрәнү, алардан файдалану, аларны саклау, яклау торгызу өлкәсендә укыту-тәҗрибә базасы объектлары (полигоннар, урман табигатен өйрәнү, урманнарны исәпкә алу алымнарына, урман үрентеләрен кисүгә, урманнарны торгызуга өйрәтү һәм башка чаралар өчен тәҗрибә мәйданчыклары), укучыларга тәҗрибәдә ныгыту өчен махсус белемнәр һәм күнекмәләр бирү өчен урман инфраструктурасының кирәкле объектларын төзү һәм алардан файдалану урманнардан фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалануга кирә.

Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану әлеге Урман хуҗалыгы регламенты һәм урманнарны үзләштерү проекты нигезендә тормышка ашырыла.

Урманнарны фәнни-тикшеренү эшчәнлеген һәм мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

махсус тамгалар, мәгълүмати һәм башка төрле, мәгариф эшчәнлеге, фәнни-тикшеренү эшләре гамәлгә ашырыла торган территорияне чикли торган күрсәтмәләр урнаштыру;

фән һәм мәгариф максатларында урман утыртмаларын кисү;

урман инфраструктурасын төзү;

фәнни-тикшеренү эшләнмәләрен һәм тәҗрибә-конструкторлык эшләрен әзерләү, аларның нәтиҗәләрен тәҗрибә-җитештерүдә тикшерү һәм гамәлгә кертү максатларында урманнарны саклау, яклау, торгызу һәм файдалану буенча эксперимент эшчәнлеген гамәлгә ашыру;

укыту-тәҗрибә базасы объектларын төзү һәм алардан файдалану;

урманнарны үзләштерү проектында каралган бүтән төрле эшләр.

Урманнарны фәнни-тикшеренү эшчәнлеге һәм мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланганда түбәндәге очраклар булмаска тиеш:

тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларына, үсемлекләр капламына һәм туфракка зыян салу;

тапшырылган урман кишәрлеген һәм аннан читтәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;

тапшырылган урман кишәрлеге мәйданын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;

Фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген башкару өчен урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып тора;

җитештерү эшчәнлеге барышында җимерелгән юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын, аншлагларны, урманнар территориясен төзекләндерү элементларын торгызуны;

әлеге затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын, урман янгыннарын булдырмый калу, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрә;

Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган, җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгаруга бәйле объектларны тиешле эшләрне үтәү чорлары тәмамлану белән консервацияләүне яисә юк итүне һәм күрсәтелгән объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм (яки) эксплуатацияләү өчен файдаланылган җирләрне рекультивацияли;

сейсмик разведка эшләрен планлаштыру һәм үткәрү, шулай ук хәрәкәт составын һәм йөкләрне яңа урынга күчерү максатларында квартал ызаннары, урман юллары билгән һәм урман утыртмалары белән капланмаган башка җирләрдән максималь рәвештә файдалануны.

Фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан рөхсәтле файдалану вакытлары әлеге Урман хуҗалыгы регламентының гамәлдә булу вакыты белән чикләнә.

Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланучы дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр, башка фәнни оешмалар, мәгариф оешмалары хокуклы:

урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе шартлары нигезендә урманнардан файдалануны гамәлгә ашырырга;

мәгариф эшчәнлеге, фәнни-тикшеренү эшчәнлеге гамәлгә ашырыла торган территорияне чикли торган махсус тамгалар, мәгълүмати һәм бүтән төрле күрсәткечләр куярга;

фәнни һәм мәгариф максатларында урман агачларын кисәргә;

РФ УК 13 ст. 1 өл. нигезендә урман инфраструктурасы (урман юллары, урман складлары һәм башкаларны) ясарга;

фәнни-тикшеренү, тәҗрибә-конструкторлык эшләре нәтиҗәләрен эштә сынау-тикшереп карау һәм гамәлгә кертү максатларында урманнардан файдалану, саклау, яклау, яңарту буенча тәҗрибәләр эшчәнлеген гамәлгә ашырырга;

урманның экологик системасына йогынтысын өйрәнү өчен химик, биологик һәм башка төрле чараларга сынаулар уздырырга;

фәнни һәм укыту-тәҗрибә базасы объектлары булдырырга һәм алардан файдаланырга;

әгәр аларны тормышка ашыру Россия Федерациясенең урман законнары таләпләренә каршы килмәсә, башка хокукларга ия булырга.

Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеге, мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланучы дәүләт учреждениеләре, муниципаль учреждениеләр, башка фәнни оешмалар, мәгариф оешмалары бурычлы:

РФ УК 88 ст. 1 өл. ярашлы рәвештә урманнарны үзләштерү проекты төзү;

урманнарны үзләштерү проекты нигезендә урманнардан файдаланырга һәм урманнарны саклау, яклау, торгызу буенча чаралар уздырырга; урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе шартларын үтәргә;

урманнардан туфрак эрозиясен чикли торган, урманнарның торышына һәм яңадан үсеп китүенә, шулай ук су һәм башка табигый объектларга тискәре йогынты ясамый торган яисә бу күренешләрне чикли торган ысуллар һәм технологияләр ярдәмендә файдалану;

урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен үтәү;

РФ УК 26 ст. 2 өл. ярашлы рәвештә ел саен урман декларациясе тапшыру;

РФ УК 49 ст. 1 өл. нигезендә урманнардан файдалану турында хисап тапшырырга;

РФ УК 60 ст. 1 өл. нигезендә урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшырырга;

РФ УК 91 ст. 4 өл. ярашлы рәвештә дәүләт урман реестрына билгеләнгән тәртиптә РФ УК 91 ст. 2 өл. каралган документлаштырылган мәгълүматларны тапшырырга;

## 2.8. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

### 2.8.1. Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары

Рекреация эшчәнлеге РФ УК ял итү, туристлык, физкультура-савыктыру һәм спорт эшчәнлеген оештыруга кагылышлы эшчәнлек буларак карала.

Урманнардан мондый файдалану (РФ УК 41 ст.) урман кишәрлекләре бирүне таләп итә, әмма урман ресурсларын җыймауны күз алдында тота торган эшчәнлек төренә кертелә, бирелгән урман кишәрлекләрендә кирәкле урман

инфраструктурасы, шул исәптән вакытлы корылмалар булдырыла, территория төзекләндерелә (РФ УК 13, 41 ст.).

Рекреация эшчәнлеген оештыру үзенчәлекләре 2012 ел, 21 февраль, № 62 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләрендә (алга таба – Кагыйдәләр) бәян ителә.

Урманчылык урманнары ландшафтларының төркемнәре һәм типлары буенча түбәндәгечә бүленгән, аның күрсәткечләре 14.1 таблицада китерелде.

14.1 таблица.

Ландшафт төркемнәре һәм типлары

| Төркемнәре | Типлары | Урман ябалдашының гомуми йомыклыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Ябык | Горизонталь йомык агачлар | 1,0-0,6 |
| | 1,5 метрдан артыграк биеклектә булган шытымнар һәм урманчык ярусын исәпкә алып, вертикаль йомылган агачлар | 1,0-0,6 |
| Яртымачык | Агачларын тигез урнаштырып сирәкләнгән, сирәк шытымлы һәм 1,5 метрдан артмаган үрентеләре булган яисә алардан башка урман | 0,5-0,3 |
| | Агачларын тигез урнаштырып сирәкләнгән, сирәк шытымлы һәм 1,5 метрдан артмаган үрентеләре булган яисә алардан башка урман | 0,5-0,3 (төркемнәрдә-0,7-0,6) |
| | 1,5 метрдан биегрәк үрентеләр | 0,5-0,4 |
| Ачык | Сирәклекләр, биеклегенә бәйсез рәвештә куаклар сирәк кенә шытып чыга башлаган, берән-сәрән агачлары булган кишәрлекләр | 0,2-0,1 |
| | 1,5 метрга кадәр биеклектә урман яисә куаклыклар торгызылган урыннары булган кишәрлекләр (куелыгына карап) | |
| | Агач-куаклык үсемлекләре булмаган кишәрлекләр | |

Урманда рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру түбәндәгеләрнең сан күрсәткечләре ярдәмендә бәяләнә:

1) рекреацион файдалану ешлыгы;

2) рекреация басымы, рөхсәт ителгән рекрация басымы;

3) объектның рекреация сыешлыгы.

Рекреация басымы билгеле бер вакыт эчендә (сәгать, көн, ай, чор, ел) урманнарның бер берәмлек мәйданында (1 гектарда) ял итүче кешеләр саны белән билгеләнә.

Аерым урман кишәрлекләре, бигрәк тә автомобиль юлларына, бакчачылык ширкәтләренә, ял йортларына һәм башка төрле савыктыру холкындагы учреждениеләргә тоташып үсүче нарат һәм нарат-каен урманнары юигрәк тә көчәйтелгән рекреация басымына дучар була. Шәһәр урманнарында

һәм аларга янәшә торучы территорияләрдә рекреация басымының һәм тулаем алганда антропоген йогынтының төп төрләре булып түбәндәгеләр санала:

1) шәһәр халкының кышын һәм җәен урманнарда йөрүләре;
2) спорт белән шөгыльләнүләр;
3) урманнарда пикниклар;
4) кыргый үсемлекләр (гөмбәләр, җиләкләр) әзерләү;
5) су коену һәм комлыкта кызынулар;
6) турист походлары;
7) пионер лагерьларында һәм ял йортларында сезонлы оештырылган ял;
8) бакчачылык һәм яшелчәчелек белән шөгыльләнү;
9) сәнәгый һәм көнкүреш калдыкларыннан чүплекләр;
10) оештырылмаган шәхси транспорт тукталышлары.

Рөхсәт ителә торган рекреация басымы – шактый вакыт аралыгында мондый йогынты нәтиҗәсендә урман биогеоценозларының үзлегеннән торгызылу үзенчәлекләреннән артып китмәгән басым. Ул гадәттә бик аз зәгыйфьләнүләргә китерә һәм биогеоценозларының аерым элементларына сизелер-сизелмәс үзгәрешләр кертә, аның төзелешен һәм вазыйфаи тотрыклылыгын үзгәртми. Антропоген йогынты нәтиҗәләрен бетерү өчен максатлы урманчылык катышуы таләп ителми.

Урман утыртмаларына иң көчле рекреация басымы елның җылы вакытына туры килә, гәрчә кайбер спорт төрләре кышын да гамәлгә ашырыла.

Түбәндә урман кишәрлекләрен бәяләү, утыртмаларга рөхсәт ителүче рекреация басымы шкалалары һәм урман кишәрлекләрен рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен арендага тапшырганда урман кишәрлекләрен әзерләгәндә территорияләрне төзекләндерү буенча файдалану зарурлыгы булган якынча нормалары китерелә.

14.1.1 таблица.

Урман тирәлегенең рекреация деградациясен бәяләү шкаласы

| Кишәрлеккә сыйфатлама | Рекреация деградациясе стадияләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Урман тирәлеге бозылу күренешләре юк, агачлар һәм куаклар үсеше нормаль, аларда механик бозылулар юк; шытып чыкканнары һәм куаклары (төрле яшьтәге) тереклек итәргә сәләтле. Мондый урман тибына хас булган мүк һәм үлән капламы; аяк асты түшәмәсе (сыгылмалы) бозылмаган. Рекреацияне җайга салу таләп ителми. | 1 |
| Урман тирәлеге сизелер-сизелмәс үзгәргән һәм агачлар һәм куаклар үсеше начарланган, аларда берән-сәрән механик бозылулар бар; шытып чыкканнары һәм куаклары (төрле яшьтәге) яшәрлек, уртача куелыкта, 20%ка кадәр зарарланган һәм кипкән нөсхәләре бар. Мүк белән проект капланышы – 20%ка кадәр, үлән капламы – 50%ка кадәр (шулардан 1/10 – | 2 |

| Кишәрлеккә сыйфатлама | Рекреация деградациясе стадияләре |
|---|---|
| 1 | 2 |
| болын үсемлекләре); аяк асты урман япмасы бераз бозылган,туфрак һәм аяк асты урман япмасы тыгызланган; агачларның аерым тамырлары шәрәләнгән, туфракның 5%ка кадәр мәйданы минераль өлешенә кадәр тапталган. Рекреация эшчәнлеген җайга салу таләп ителә. | |
| Урман тирәлеге шактый үзгәргән һәм агачлар һәм куаклар үсеше зәгыйфьләнгән, кәүсәләр 10% ка кадәр механик зарарланган; шытып чыкканнары һәм куаклары (бер үк яшьтәге) зәгыйфьләнгән, уртача куелыкта яисә сирәк, 21-50% зарарланган һәм зәгыйфьләнгән нөсхәләр. Агачларның кәүсәләре тирәсендә мүк, аларның проект капламы 70-60% (шулардан 2/10 – болын үсемлекләре, чүп үләннәре күренә). Түшәмә һәм туфрак җитәрлек тыгызланган, тамырлары шәрәләнгән агачлар бик күп, мәйданның 6-40%ында туфракның минерал өлешенә кадәр тапталган. Рекреация эшчәнлеген актив җайга салу таләп ителә. | 3 |
| Агач-болын тибындагы урман тирәлеге бик нык үзгәргән, агачлар шактый зәгыйфьләнгән, кәүсәләре 11-20% ка кадәр механик зарарланган; шытымнары һәм үрентеләре тереклек итәргә сәләтле түгел (башлыча чәчәклекләрдә), сирәк яисә бөтенләй юк, 50% артык нөсхәләре зарарланган яки корыган. Мүкләр бөтенләй юк, үләннең проект капламы 59-40% (шул исәптән 1/2 өлешенә кадәр болын үсемлекләре һәм чүп үләннәре тәшкил итә). Тамырлары шәрәләнгән агачлар күп, ачык урыннарда аяк асты түшәмәсе юк, мәйданының 41-60% өлешендә туфрак минерал өлешенә кадәр тапталган. Рекреация эшчәнлеген катгый рәвештә чикләү зарури | 4 |
| Урман тирәлеге деградацияләнгән; агачлары сирәкләнгән, чәчәклек-болын тибында, агачлары нык зәгыйфьләнгән яисә корый, 20%тан артык өлеше механик зарарланган; шытымнары, үрентеләре, мүкләре, аяк асты түшәмәсе юк, үләннең проект капламы 10%ка кадәр (шул исәптән 3/4 өлешендә диярлек болын үсемлекләре һәм чүп үләннәре), күп агачларның тамырлары шәрәләнгән һәм зарарланган. Мәйданының 60%ыннан артык өлешендә туфрагы минерал өлешенә кадәр тапталган. Рекреация рөхсәт ителми. | 5 |

14.1.2 таблица.

## Кишәрлеккә санитар-гигиена бәяләмәсе шкаласы

| Кишәрлеккә (бүлемтеккә) сыйфатлама | Классы (балл), санитария-гигена ягыннан бәяләү буенча |
|---|---|
| 1 | 2 |
| Кишәрлекнең торышы яхшы санитар хәлдә, һавасы чиста, аэрациясе яхшы,техноген шау-шулар, канэчкеч бөҗәкләр, үтеп чыкмаслык булып үскән куе үсемлекләр юк. Хуш исләр, урман авазлары, матур төсләр бар. | 1 |
| Кишәрлек шактый яхшы санитар хәлдә, бераз гына чүпләнгән, берән-сәрән кипкән агачлар бар, һава бераз пычрак, вакыт-вакыт техноген шау-шулар була | 2 |

| | |
|---|---|
| яисә бөтенләй юк | |
| Кишәрлек начар санитар хәлдә, черегән агач белән тулган, чүпләнгән. Чүп өелгән урыннар, карьерлар һәм чокырлар бар, һава бик нык пычранган (шул исәптән начар исләр килә). Җилле, бик күләгәле урын, техноген шау-шулар югары дәрәҗәдә, кан эчкеч бөҗәкләр бик күп, артык дымлы, үтеп чыкмаслык куелыклар бар | 3 |

Искәрмә. Билге кишәрлекнең санитар торышын даими рәвештә күзәтүләр нәтиҗәсендә бирелә.

14.1.3 таблица.

Утыртмаларның биологик тотрыклылыгын бәяләү шкаласы

| Бони-тотрыклылыгы буенча | Агымдагы коелу процессларының күләме һәм сыйфатламасы (корый торган агачлар һәм саф коры-сары) | Гомуми кору күләме (2 нче һәм 3 нче торыш төркеме агачлары + чүп-чар белән тулу) | Корткычлар һәм авырулар булу | Урман тирәлеге торышы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 – тотрыклы | 2%ка кадәр (урта өлешендә 1,3 м диаметрлы агачлар хисабына) | 5%ка кадәр | Юк яки берән-сәрән зәгыйфьләнү очраклары | Зәгыйфьлән мәгән |
| 2 – тотрыклылыгы зәгыйфьләнгән | Корып кубу күләме табигый кору күләменнән 2 һәм аннан күбрәк мәртәбә артып китә (уртасына якын өлешендә 1,3 м диаметрлы агачлар хисабына) | 6%-40% | Массакүләм таралырга һәм күп санда булырга мөмкин | Кагыйдә буларак, зәгыйфьлән гән, тулылыгы тигез түгел яки түбән |
| Бони-тотрыклылыгы буенча | Агымдагы коелу процессларының күләме һәм сыйфатламасы (корый торган агачлар һәм саф коры-сары) | Гомуми кору күләме (2 нче һәм 3 нче торыш төркеме агачлары + чүп-чар белән тулу) | Корткычлар һәм чир күренешләре булу | Урман тирәлеге торышы |

Искәрмәләр:

2 нче биологик тотрыклылык классына караган агачлыкларда – сайланма, 3 нчедә тоташ санитар кисүләр үткәрелә (башка хуҗалыкка бәйле әмерләр булмаганда).

2 нче һәм 3 нче биологик тотрыклылык классларына карый торган утыртмаларның суммар мәйданы санитар торышы канәгатьләндерерлек булмаган утыртмалар мәйданын тәшкил итә.

Үтүчәнлек: 1 – яхшы; 2 – уртача; 3 – начар.

Күрүчәнлек: 1 – яхшы; 2 – уртача; 3 – начар.

14.1.4 таблица.

Кишәрлеккә эстетик бәяләмә шкаласы

| Классы, | Утыртмалары | Ачык урыннар |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Озын һәм киң ябалдашлы, сәламәт һәм матур куаклары һәм уртача куелыкта шытымнары булган I-II бонитет класслы ылыслы һәм яфраклы утыртмалар. Яхшы үтеп керүчәнлекле, чүпләнмәгән кишәрлек | 1,0 га кадәр мәйданы (ачыклыклар, аланнар), яхшы дренажланган әйбәт һәм коры туфрак; катлаулы, борылмалы чикләре булган 1 гектардан 3 гектарга кадәр мәйданлы, яхшы билгеләнгән рельефлы, декоратив урман авызлары булган кишәрлекләр, берән-сәрән декоратив агачлары яисә формалашкан агач-куак төркемнәре; декоратив үсемлекләр белән әйләндереп алынган, ярлары күренеп торган зур булмаган матур сулыклары бар |
| 2 | Составында 5 берәмлек зирек һәм усак катнашындагы III бонитет классына караган утыртмалар, – ябалдашларының киңлеге һәм зурлыгы уртача, куе, яшь үрентеләре белән куаклыклары җәберләнгән булганда. Өлешчә чүпләнгән урын (5 $м^3$/га кадәр) | Чикләренең конфигурациясе гади рәвешле булган зур күләмле ачык урыннар; вак декоратив үсемлекләр белән әйләндереп алынган сулы урыннар; агач үсми торган, куаклыклар басып алган кишәрлекләр |
| 3 | Зирек һәм усак, шулай ук IV-V бонитет класслы ылыслылар өстенлек иткән үрентеләр. Агачларның ябалдашлары начар үсеш алган. Чүп-чар һәм коры-сары белән тулу дәрәҗәсе: 5 $м^3$/га һәм күбрәк | Урман утыртылмаган киселгән урыннар, сөрүлекләр, электрүткәргеч линияләр, хуҗалыклар, сазлыклар һәм башка ачык мәйданнар, декоративлыгы түбән булган сулыклар |

Искәрмәләр:

Ачык ландшафтларны эстетик бәяләү түбәндәге күрсәткечләрне исәпкә алып уздырыла:

1) җирлектәге торышы, туфрагының дымлылыгы, үтеп йөрүчәнлек дәрәҗәсе;

2) кишәрлекнең зурлыгы һәм конфигурациясе;

3) урман кырыйларының һәм җирлекнең, әйләнә-тирәдәге ачык урыннарның гүзәллеге;

4) агачларның һәм куакларның берән-сәрән яисә зур булмаган төркемнәре булу һәм аларның урнашу холкы;

5) үлән һәм мүк капламының сыйфаты;

6) сулыкларның күләме һәм конфигурациясе, ярларының һәм әйләнә-тирәсендәге үсемлекләрнең холкы, су өслегенең ял итүчеләр өчен коенырга

мөмкин булуы, сулыкның санитар торышы һәм ял итү һәм коену өчен аннан файдалану мөмкинлеге.

Рекреация басымына карап, урман кишәрлекләреннән ял итү өчен файдалану режимы түбәндәгечә булырга мөмкин:

1) ирекле – гектарына 5 кешелек басым булганда (тыныч ял итү өчен аз төзекләндерелгән зона);

2) уртача-җайга салына торган – гектарына 6-20 кешелек басым булганда (актив ял итү өчен рекреация объектлары белән җитәрлек дәрәҗәдә тәэмин ителгән зона);

3) катгый рәвештә җайга салына торган – гектарына 20 кешедән артык басым туры килгәндә (актив ял итү өчен аерым урман кишәрлекләре, алар максималь рәвештә төзекләндерелгән булырга тиеш).

14.1.5 таблица.

Рекреация билгеләнешендәге урманнарда төп хуҗалык чаралары һәм урманнардан файдалану төрләре

| № п/п | Чараларның аталышы | Вазыйфаи зоналар | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ял | Һава сулап йөрү | Фауна тынычлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| I. Урман хуҗалыгы чаралары | | | | |
| 1. | Урманнарны тәрбияви кисүләр, түбәндәге максатларда: | | | |
| | Ландшафтларны рәвешкә китерү | + | + | – |
| | Азкыйммәтле үсемлекләрне юк итү | + | + | + |
| | Табигый яңартылуга булышу | + | + | + |
| | үрентеләрне тәрбия кылу | + | + | + |
| | Гамәлдәге һәм ясалган урман ландшафтларын тәрбия кылу | + | + | + |
| | Утыртмаларның рәвешен үзгәртү һәм яңарту | + | + | – |
| 2. | Реконструкция кисүләре | + | + | – |
| 3. | Башка төрле кисүләр, түбәндәге максатларда: | | | |
| | Ачык ландшафтлар ясау, ерактагы күренешләрне чистарту | + | – | – |
| | Күренә торган урыннарда рекреацияләү ягыннан караганда тулы булмаган үсемлекләрне юкка чыгару | + | – | – |
| | Ял итү һәм төзекләндерү объектларын төзү өчен мәйданнарны чистарту | + | + | – |
| | Ачык ландшафтларны һәм күренеп тора торган урыннарны тәрбия кылу | + | + | – |
| 4. | Агачлар һәм куаклыклар утырту, түбәндәге максатларда: | | | |
| | Ландшафтларны рәвешкә китерү | + | + | – |
| | Урманның санитария-гигиена | + | + | – |

| № п/п | Чараларның аталышы | Вазыйфаи зоналар | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ял | Һава сулап йөрү | Фауна тынычлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | үзенчәлекләрен һәм утыртмаларның тотрыклылыгын арттыру | | | |
| | Урманны торгызу | – | + | + |
| | Ремизлар ясау | – | – | + |
| | Утыртмаларны реконструкцияләү | + | + | – |
| 5. | Болынлы газоннар булдыру | + | – | – |
| 6. | Ачык урыннарда үлән капламын карап тоту | + | + | – |
| 7. | Табигать саклау чаралары | + | + | + |
| 8. | Санитар-яклау чаралары, ш.и. санкисүләр | + | + | + |
| 9. | Янгынга каршы чаралар | + | + | + |
| 10. | Урманга хилафлык килүләрне һәм ял итүчеләр тарафыннан урманга зыян салынуларны профилактикалау | + | + | + |
| II. Биотехника чаралары һәм фаунаны саклау | | | | |
| 1. | Хайваннарның тереклек итү шартларын яхшырту | – | – | + |
| 2. | Ашату мәйданнары ясау һәм хайваннарны ашатып тору | – | + | + |
| 3. | Оялыклар ясау һәм элеп кую | + | + | + |
| 4. | Урман хуҗалыгы эшләрен регламентлау һәм чикләмәләр кертү | – | – | + |
| III. Территорияне төзекләндерү | | | | |
| 1. | Юл-сукмак челтәрләре, ясалма корылмаларга автотукталышлар ясау | + | + | – |
| 2. | Рекреация маршрутларын төзү | + | + | – |
| 3. | Күзәтү нокталарын һәм карау мәйданнарын ясау | + | + | – |
| 4. | Ял итү мәйданнары ясау һәм аларны җиһазлау | + | + | – |
| 5. | Кече архитектура рәвешләрен һәм урман-парк җайланмаларын төзү һәм урнаштыру | + | + | – |
| 6. | Визуаль мәгълүмат | + | + | + |
| 7. | Күрсәтмәле агитация | + | + | – |
| 8. | Куну урыны булган, җәйге, стационар типтагы ял урыннары ясау һәм җиһазлау | + | – | – |
| 9. | Төзекләндерү объектларын карау, аларны ремонтлау | + | + | + |
| IV. Урманнан файдалану | | | | |
| 1. | Өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын кисү | – | – | – |
| 2. | Урман торгызуга бәйле агач кисүләр | – | – | – |
| 3. | Печән чабу | + | + | – |
| 4. | Терлек көтү | – | – | – |
| 5. | Җиләкләрне, гөмбәләрне, чикләвекләрне | + | + | – |

| № п/п | Чараларның аталышы | Вазыйфаи зоналар | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Актив ял | Һава сулап йөрү | Фауна тынычлыгы |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| | һәвәскәр җыю | | | |
| 6. | Дару чималын һәвәскәр җыю | + | + | – |
| 7. | Умартачылык | – | – | – |

Искәрмәләр: «+» тамгасы – файдалану рөхсәт ителә;
«-» тамгасы – файдалану рөхсәт ителми.

### 2.8.2. Рекреация эшчәнлегенә бәйле зона кварталларының һәм (яки) аларның өлешләре исемлеге

Кишәрлек урманчылыклары буенча рекреация эшчәнлеге зонасының кварталлар исемлеге әлеге регламентның 5 таблицасында китерелде.

### 2.8.3. Рекреация эшчәнлегенә караган зона территориясен функциональ зоналарга бүлү

Рекреацияләү зоналары вазифаи зоналарга түбәндәгечә бүлгәләнә:
1) интенсив кулланылышлы;
2) уртача кулланылышлы;
3) концентрацияле ял итүгә бәйле;
4) резерватлы;
5) заказник;
6) катгый режимлы;
7) хуҗалыкка бәйле.

### 2.8.4. Урман кишәрлекләрендә вакытлы төзелгән корылмалар исемлеге һәм аларны төзекләндерү нормативлары

14.1.6 таблица.

Рекреация билгеләнешендәге урманнарда территорияләрне төзекләндерү нормалары (гомуми мәйданыннан 100 га)

| № п/п | Чараларның аталышы | Үлч. бер. | Күләме, м | Урнашкан урыны (кварталы, бүлемтеге) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1. | Күрсәтмә такталар урнаштыру | данә | 2 | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 2. | Җәяүле күперләре урнаштыру | данә | 2 | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 3. | Яңгырдан әвеслекләр, павильоннар урнаштыру | данә | 2 | Урманчылык ихтыяры буенча |

| № п/п | Чараларның аталышы | Үлч. бер. | Күләме, м | Урнашкан урыны (кварталы, бүлемтеге) |
|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 4. | Пикник өстәлләре урнаштыру | данә | 3 | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 5. | Утыргычлар һәм диваннар кую | данә | 30 | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 6. | Чүп җыйгычлар урнаштыру | данә | 3 | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 7. | Сукмаклар салу | км | 0,4 | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 8. | Автотукталыш урыннары ясау | данә | 3 | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 9. | Палаткалар өчен урыннар ясау | данә | – | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 10. | Учак урыннары ясау (азык әзерләү урыннары кору) | данә | 5 | Урманчылык ихтыяры буенча |
| 11. | Коеларны һәм чишмәләрне төзекләндерү | данә | 1 | Урманчылык ихтыяры буенча |

## 2.8.5. Урманнардан рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану параметрлары һәм чорлары

Урманнарда рекреацияләү эшчәнлеге урман законнарының хокукый-норматив актлары нигезендә расланган Урманнардан рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләре белән регламентлана, аларда түбәндәгеләр карала:

рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен аерып чыгарыла торган урман кишәрлекләренең зурлыгын билгеләгәндә, урман утыртмаларына зыян салынмау шартларын үтәп, урман экосистемаларына карата булган оптималь рекреация басымына таянып эш итәргә кирәк;

урманнардан ял итүне, туристлык, физкультура һәм спорт эшчәнлеген оештыру максатларында рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланучы затлар туристлык станцияләрен, туристлык сукмакларын һәм трассаларын ясарга, мәдәни-массакүләм чараларны, җәяүләп, велосипедта һәм чаңгыда шууларны, сынлы сәнгать белән шөгыльләнүләрне, кызыксындыргыч һәм экологик экскурсияләр үткәрүне оештырырга, аерым спорт төрләре буенча асылы урманда ярышлар үткәрүгә туры килә торган спорт ярышларын, физкультура-спорт фестивальләрен һәм күнегүләр ясау өчен җыелышуларны, шулай ук аерым рекреацияләү эшчәнлеге төрләрен оештырырга мөмкин;

рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясына караган объектлар, су объектлары сакланырга тиешле;

рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зыян китерми торган ысуллар ярдәмендә башкарыла;

вакытлыча корылмаларны, физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техника корылмаларын вакытлыча урнаштыру барыннан да элек агачсыз һәм куаксыз урыннарда, ә мондый урыннар булмаганда – артык кыйммәтле булмаган агачлар белән капланган, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә, әгәр бу хәл Татарстан Республикасы урман планында билгеләнгән булса;

халыкка масскүләм ял итү өчен, кече архитектура рәвешләрен урнаштыру һәм ял итү һәм тәмәке тарту урыннарын ясау юлы белән, уңайлы шартлар тудыру урман экосистемаларының экология шартларына тискәре рекреация йогынтысын киметергә мөмкинлек бирәчәк.

урман сукмакларыннан һәм гидротехника корылмаларыннан гайре, капиталь төзелеш объектларын урнаштырмыйча гына, урманчылык территориясендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру рөхсәт ителә.

Рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшырылырга, башка затларга – арендага бирелергә мөмкин.

Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдаланганда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 ел, 30 июнь, № 417 карары белән расланган Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 ел, 20 май, № 607 карары белән расланган Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре таләпләре үтәлүен тәэмин итәргә кирәк.

Янгын чыгу куркынычы янаган чорда урманнар территориясендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашырганда массакүләм чаралар үткәрү бары тик җирле үзидарә органнары белән килештереп, файдаланыла торган урман кишәрлекләрендә учак ягу һәм чүп җыю урыннары булдыру шарты белән рөхсәт ителә.

Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланучы затларның хокуклары:

урманнардан файдалануны урман кишәрлеген бирү турындагы документларга, шул исәптән урман кишәрлегенең аренда шартнамәсенә, урман кишәрлеген даими (вакытын чикләмичә) файдалануга тапшыру турында карарга туры китереп гамәлгә ашырырга;

Россия Федерациясе Урман кодексының 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы (урман юллары, урман складлары һәм башкаларны) ясау;

Россия Федерациясе Урман кодексының 41 статьясының 2 өлеше һәм 21 статьясының 7 өлеше нигезендә урман кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар торгызу һәм аларны төзекләндерү;

тиешле урман кишәрлекләрендә физкультура, спорт һәм спорт-техник корылмалар торыгызырга, әгәр Россия Федерациясе субъекты территориясендә урманнарны үзләштерү планында (Россия Федерациясе субъектының урман

планында) урманнарны үзләштерү буенча планлаштырылган зоналар билгеләнгән булса, аларның чикләрендә рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү күздә тотылса;

башка хокуклардан файдаланырга, әгәр аларны тормышка ашыру Россия Федерациясенең урман законнары таләпләренә каршы килмәсә.

Вакытлыча корылмаларны, физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техника корылмаларын вакытлыча урнаштыру барыннан да элек агачсыз һәм куаксыз урыннарда, ә мондый урыннар булмаганда – артык кыйммәтле булмаган агачлар белән капланган, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә.

Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланучы затларның бурычлары:

РФ УК 88 ст. 1 өл. ярашлы рәвештә урманнарны үзләштерү проекты төзү;

урманнардан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә файдалану;

урман кишәрлегенең аренда шартнамәсендәге һәм урман кишәрлеген даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшыру турында карарда билгеләнгән шартларны үтәү;

урманнардан туфрак эрозиясен чикли торган, урманнарның торышына һәм яңадан үсеп китүенә, шулай ук су һәм башка табигый объектларга тискәре йогынты ясамый торган яисә бу күренешләрне чикли торган ысуллар һәм технологияләр ярдәмендә файдалану;

РФ Урман кодексының 21 ст. 6 өл. нигезендә урман инфраструктурасын төзүгә бәйле булмаган гидротехника корылмаларын төзү, үзгәртеп кору һәм (яки) эксплуатацияләү өчен файдаланылган җирләрне рекультивацияләү;

урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен үтәү;

РФ Урман кодексының 26 ст. 2 өл. ярашлы рәвештә ел саен урман декларациясе тапшыру;

РФ Урман кодексының 49 ст. 1 өл. нигезендә урманнардан файдалану турында хисап тапшырырга;

РФ Урман кодексының 60 ст. 1 өл. нигезендә урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшыру;

РФ Урман кодексының 91 ст. 4 өлешенә ярашлы рәвештә дәүләт урман реестрына билгеләнгән тәртиптә РФ Урман кодексының 91 ст. 2 өлешендә каралган документлаштырылган мәгълүматларны тапшыру;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка йөкләмәләрне үтәү.

## 2.9. Урманнардан урман плантацияләре ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен рөхсәтле файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урман плантацияләре ясау һәм аларны эксплуатацияләү билгеле бер максатчан токымга карый торган урман үрентеләре үстерүгә бәйле эшкуарлык

эшчәнлегеннән гыйбарәт. Билгеле бер (максатчан токымнарга) токымга караган урман утыртмаларына ясалма үстерелгән, билгеләнгән сыйфатламаларына ярашлы агач үстерү алар хисабыннан тәэмин ителә торган урман утыртмалары кертелә. Урман плантацияләре урман фонды җирләрендә һәм башка категория җирләрендә (урман утыртмалары капламаган җирләрдә һәм урманныкы булмаган җирләрдә) ясалырга мөмкин. Урман плантацияләрендә урман утыртмаларын кисү һәм урман утыртмаларына кирт салу эшләрен башкару чикләмәләрсез рөхсәт ителә (РФ УК 42 ст.).

Гражданнарга, юридик затларга урман плантацияләрен ясау һәм аларны эксплуатацияләү өчен урман кишәрлекләре – РФ Урман кодексы нигезендә, җир кишәрлекләре – җир законнары нигезендә арендага тапшырыла.

Дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе урман плантацияләре ясау максатларында РФ Урман кодексының 72 ст. 3 өлеше нигезендә ун елдан алып кырык тугыз елга кадәр төзелә.

Плантация ясау максатларында түбәндәгеләрне файдалану рөхсәт ителми: су саклау зоналарында урнашкан урманнарны; табигый һәм башка объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнарны; кыйммәтле урманнарны; махсус саклanучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны.

## 2.10. Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану тәртибе «Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 5 декабрь, № 510 Рослесхоз боерыгы белән расланган.

Урман җимешләре, җиләкләр, декоратив үсемлекләр һәм дару үләннәре үстерү (РФ УК 39 ст.) җимешләр, декоратив үсемлекләр, дару үләннәре һәм башка шуңа охшаш урман ресурслары алуга бәйле эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Үстерү өчен файдаланыла торган урман кишәрлекләрендә вакытлы корылмалар урнаштыру рөхсәт ителә.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, шулай ук урман булып җитешмәгән диләнкеләр, аланнар һәм урман культураларын утыртканчыга кадәр урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман утыртмалары белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшкә яраклы үзлеге беткән торфлыклар һ.б.) җирләр файдаланыла.

Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен үзгәртеп коруга билгеләнмәгән, азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин.

РФ Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләреннән җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану тыела.

Яклаучы урманнардан һәм урманнардагы махсус яклана торган кишәрлекләрдән җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре һәм дару үләннәре үстерү өчен файдалану тыела.

## Азык-төлек урман продукциясен плантациядә үстерү перспективалары

Кыргый азык-төлек һәм дару үләннәре өлкәсендә шактый гына табигый запаслар булуга карамастан, соңгы 20-30 елда кайбер төр җиләкләрне, җимеш бирә торган үсемлекләрне һәм гөмбәләрне ясалма үстерү тенденциясе барлыкка килде. Моның сәбәбе – плантацияләрдә үстерелгән продукциянең үзкыйммәте халыктан җыелган шул ук төр кыргый үсемлекләрне сатып алу бәяләренә караганда кимрәк чыга.

Плантацияләрдә барлык төр эшләрне дә бергә туплап һәм механикалаштырып була, шул исәптән әзерләүне дә, бер берәмлек мәйданнан уңышны арттырып, һава шартларына бәйлелекне бетереп, селекция өчен шартлар тудырып, продукциянең сыйфатын арттырып була.

Аз гына чыгымнар белән табигый шартларда иң продуктив үсемлекләрне сайлап алырга һәм аларда җимеш бирү һәм эксплуатацияләү (ягъни культуралаштыру) өчен оптималь шартлар тудырырга мөмкин.

Культивацияләнергә мөмкин булган һәм культураны гамәлгә керткәндә үзлекләрен югалтмый торган үсемлек төрләре плантацияләрен булдыру максатка ярашлырак.

Өлкә шартлары түбәндәге плантацияләрне ясау өчен яраклы: кара миләш (арония), сырганак, гөлҗимеш, кара карлыган һәм башка азык-төлек үсемлекләре, дару үләннәре, гөмбәләрдән – шампиньон плантацияләре.

Хәзерге вакытта, сатып алу бәяләре бик югары булганда, акчаны плантацияләр булдыруга тотарга тәкъдим итәргә мөмкин.

Гөлҗимеш плантацияләре өчен иң яхшы туфрак – озак су баса торган елгаларның үзәннәрендәге органик матдәләргә бай кара туфрак һәм куе соры урман туфрагы. Плантацияләр ясау өчен сөргәннән, гектарына 100 т органик, 160 кг фосфор, 80 кг калий ашламалары кертелгәннән соң 3х1,5 м итеп казылган чокырларга яки буразналарга гөлҗимеш утырту эше башкарыла, шушы рәвешле башкарылган плантацияләрнең уңыш бирү дәрәҗәсе гектарына 5,0 тоннага җитә.

Урманчылыкларда ясалма алым белән гади вешенка гөмбәсе үстерергә мөмкин. Бер тонна гөмбә җитештерү өчен лабораторияләрдә үстерелә торган инокулянт йоктырырга һәм плантациягә 25-30 см озынлыктагы һәм 22 см диаметрлы 700 усак кисәге утыртырга кирәк, өч ел эчендә бер тонна гөмбә алырга мөмкин булачак.

## 2.11. Урманнардан урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урман утыртмаларының утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү РФ Урман кодексының 39.1 ст. һәм 2011 ел, 19 июль, № 308 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә урманнарны торгызу һәм урман үрчетү максатларында гамәлгә ашырыла торган эшкуарлык эшчәнлегеннән гыйбарәт.

Урман үрентеләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман кишәрлекләре дәүләт учреждениеләренә, муниципаль учреждениеләргә – даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга, башка затларга арендага тапшырыла.

Урман утыртмаларының утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдаланыла торган урман кишәрлекләрендә теплицалар, башка корылмалар һәм төзелмәләр кору рөхсәт ителә (РФ УК 39.1 ст. 2 өлеше).

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану урманчылыкның яисә урман паркының урман хуҗалыгы регламентлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

РФ Урман кодексының 24 статьясындагы 2 өлеше нигезендә урманнардан файдаланучы гражданнарның, юридик затларның урман хуҗалыгы регламентын һәм урманнарны үзләштерү проектын үтәмәве урман кишәрлегенең аренда шартнамәсен вакытыннан алда туктату, шулай ук урман кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукын мәҗбүри туктату өчен нигез була.

Урманнардан файдалану урман кишәрлекләрен биреп яки бирмичә, урман ресурсларын алып яки алмыйча гамәлгә ашырыла.

Урманнардан файдаланучы гражданнар, юридик затлар РФ Урман кодексының 25 статьясында каралган тәртиптә, гражданлык законнары нигезендә үзагачка һәм алынган башка урман ресурсларына карата милекчелек хокукына ия булалар.

Урман үрентеләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалану РФ Урман кодексының 27 статьясы нигезендә чикләнергә мөмкин.

Урман үрентеләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затларның хокуклары һәм бурычлары.

Урман үрентеләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затларның хокуклары:

1) урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе шартлары нигезендә файдалануны гамәлгә ашыру;

2) РФ Урман кодексының 13 статьясындагы 1 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы (урман юллары, урман складлары һәм башкаларны) ясау;

3) РФ Урман кодексының 39.1 ст. 2 өл. нигезендә тапшырылган урман кишәрлекләрендә теплицалар, башка корылмалар һәм төзелмәләр урнаштыру;

4) әгәр аларны тормышка ашыру Россия Федерациясенең урман законнары таләпләренә каршы килмәсә, башка хокукларга ия булу.

Урман үрентеләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдаланучы затларның бурычлары:

1) РФ Урман кодексының 88 ст. 1 өл. ярашлы рәвештә урманнарны үзләштерү проекты төзергә;

2) урманнардан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә файдалану;

3) урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе шартларын үтәү;

4) урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалануны туфрак эрозиясе барлыкка килүне чикли торган, урманнарны алга таба торгызуга карата, шулай ук су объектларына һәм башка табигать объектларына тискәре йогынтыны юкка чыгара яки чикли торган ысуллар ярдәмендә гамәлгә ашыру;

5) урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен, урманнарда санитар иминлек кагыйдәләрен үтәү;

6) РФ Урман кодексының 26 ст. 2 өл. нигезендә ел саен урман декларациясе тапшыру;

7) РФ Урман кодексының 49 ст. 1 өл. нигезендә урманнардан файдалану турында хисап тапшыру;

8) РФ Урман кодексының 60 ст. 1 өл., РФ Урман кодексының 91 ст. 4 өл., РФ Урман кодексының 91 ст. 2 өл. шул ук пункты нигезендә урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшыру;

9) РФ Урман кодексының 91 ст. 2 һәм 4 өл. нигезендә билгеләнгән тәртиптә документлаштырылган мәгълүматларны дәүләт урман реестрына тапшыру;

10) Россия Федерациясе законнарында каралган башка йөкләмәләрне үтәү.

***Урман үсентеләренең утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урманнардан файдалануга карата таләпләр***

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен, иң беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урман белән капланмаган җирләрне, шулай ук урмансыз диләнкеләрне, аланнарны һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган, урман урнашкан бүтән категория җирләре файдаланыла.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары, яки, әгәр андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла.

Урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең районнарга бүленмәгән орлыкларын, шулай ук сыйфаты тикшерелмәгән урман үсемекләре орлыкларын, чәчүлекләрен һәм башкаларын куллану тыела.

Россия Федерациясе Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман утыртмаларының утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә тыела.

## 2.12. Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урман кишәрлекләреннән җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен файдалану урманчылыкның урман хуҗалыгы регламенты (РФ УК 43 ст.) нигезендә гамәлгә ашырыла.

РФ УК 21 статьясы нигезендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен урманнардан файдаланганда урман фонды җирләрендә урман инфраструктурасын төзүгә бәйле объектларны төзү, аларны үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү рөхсәт ителә. Урман инфраструктурасын төзүгә бәйле булмаган объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла. Урман урнашкан башка категория җирләрендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкаруга, файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгаруга бәйле объектларны төзү, аларны үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү башка федераль законнарда билгеләнгән очракларда шушы җирләрнең максатчан билгеләнешенә туры китереп рөхсәт ителә.

Урман инфраструктурасын төзүгә бәйсез объектларны төзү, аларны үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү буенча башка барлык очраклардагы кебек үк, эшләр тәмамланганнан соң файдаланылган җирләр рекультивацияләнергә тиеш (РФ УК 21 ст. 6 өлеше).

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару өчен, файдалы казылма ятмаларын әзерләү өчен дәүләт мөлкәтендә яисә муниципаль мөлкәттә торучы урман кишәрлекләре арендага тапшырыла, әлеге РФ Урман кодексының 43 ст. 2, 3 өлешләрендә каралган очраклардан тыш.

Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының әлеге РФ Урман кодексының 81-84 статьялары нигезендә билгеләнгән вәкаләтләренә туры китереп бирелгән рөхсәтләре нигезендә урман фонды җирләрендә урман кишәрлеген бирмичә генә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкарырга рөхсәт ителә, әгәр мондый эшләрне башкару урман утыртмаларын кисүгә, капиталь төзелеш объектларын төзүгә китереп чыгармаса (РФ УК 43 ст. 3 өл.).

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе кырык тугыз елга кадәрле срокка төзелә һәм РФ Урман кодексының 43 ст. 2 өлешендә каралган гариза килгән көннән башлап утыз көннән артмаган срокта аукцион уздыруны таләп итми. Дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы, үзләренең Урман кодексының 81-84 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә, килгән гаризаны карыйлар һәм урман кишәрлегенең яңа аренда шартнамәсен төзүдән баш тарту өчен нигезләр булуын яки булмавын тикшерәләр һәм аталган карау һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча урман кишәрлегенең арендаторы булып торучы гражданин яки юридик зат белән мондый урман кишәрлегенең яңа аренда шартнамәсен сатулар уздырмыйча төзү турында карар яки, РФ Урман кодексының 43 ст. 2 өлешендә каралган шартларның берсе генә булса да үтәлмәгәндә, мондый шартнамәне төзүдән баш тарту турында карар кабул итәләр. Мондый шартнамәне төзүдән баш тарту турында карарда тиешле карар кабул итүнең барлык нигезләре булырга тиеш (РФ Урман кодексының 72 ст. 3 өлеше һәм 74 ст. 3 өлеше).

Урман кишәрлекләренең күрсәтелгән аренда чоры җир асты байлыклары турындагы законнарның таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

«Җир асты байлыклары турында» 1992 ел, 21 февраль, № 2395-1 РФ законының 10 статьясында җир асты кишәрлекләре файдалануга билгеле бер вакытка бирелә дип билгеләнә:

2395-1 номерлы РФ законының 10 статьясында җир асты кишәрлекләре файдалануга билгеле бер вакытка бирелә дип билгеләнә:

геологик өйрәнү өчен – 5 елга кадәр вакытка;

файдалы казылмалар табу өчен – файдалы казылма ятмаларын эшләүне җир асты байлыкларыннан нәтиҗәле файдалануны һәм саклауны тәэмин итә торган техник-икътисадый нигезләмәдән чыгып исәпләнә торган файдалы казылма ятмаларын эшкәртү чорына;

җир асты суларын табу өчен – 25 елга кадәр вакытка;

җир асты кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктатканда тапшырылган җир асты кишәрлекләреннән кыска вакытлы

файдалану хокукы нигезендә файдалы казылмалар табу өчен – бер елга кадәр вакытка;

әлеге Законның 2.3 статьясының беренче өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән һәм әлеге Законның 10.1 статьясының 6 пунктындагы сигезенче абзацы нигезендә бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләрендә гомумтаралган файдалы казылмаларны разведкалау һәм табу, – гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, үзгәртеп кору, аларны капиталь ремонтлау һәм карап тоту буенча тиешле эшләрне башкару срогына.

Җир асты байлыклары кишәрлекләре җир астында файдалы казылмаларны табуга бәйле булмаган корылмаларны төзү һәм эксплуатацияләү өчен, калдыклар күмүгә бәйле җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү, нефть һәм газ саклау урыннарын төзү һәм эксплуатацияләү, тау токымнары пластларында иярчен суларны һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучылар тарафыннан углеводород чималын разведкалаганда һәм тапканда эш һәм технологик ихтыяҗлар өчен файдаланылган суларны урнаштыру өчен, шулай ук махсус саклана торган геологик объектларны урнаштыру һәм башка максатлар өчен срогы чикләнмичә тапшырылырга мөмкин.

Файдалы казылма ятмаларын эзләү һәм бәяләү яки эшләп чыгару эшләрен төгәлләү яисә ликвидацияләүгә бәйле чараларны башкару зарурлыгы булган очракта, җир асты байлыкларынннан файдаланучы тарафыннан лицензия шартларын бозу очраклары булмау шарты белән, шушы җир асты байлыкларыннан файдаланучының инициативасы белән җир асты байлыкларыннан файдалану чорлары озынайтыла.

Продукция бүлеге турында килешү шартларында җир асты байлыкларыннан файдалану срогын озайту тәртибе күрсәтелгән килешүдә билгеләнә.

Җир асты байлыкларыннан файдалану сроклары әлеге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне дәүләт теркәвенә алган вакыттан башлап исәпләнә.

РФ УК 20 ст. 2 өлеше нигезендә урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләп чыгару өчен файдаланганда алынган үзагачка Россия Федерациясенең милекчелек хокукы билгеләнә.

Җир асты байлыкларыннан файданучылар агач әзерләүне гамәлгә ашыруны күздә тоткан очракларда, алар аны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 23 июлендәге № 604 карарында каралган тәртиптә рәсмиләштерергә тиеш. Моның өчен урман кишәрлеге бер үк вакытта төрле максатларда файдалану өчен тапшырылырга мөмкин.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләү өчен урманнардан файдалану тәртибе Россия Федерациясе Урман хуҗалыгы министрлыгының 2010 ел, 27 декабрь, № 515 боерыгы белән расланган.

Бу норматив-хокукый актта урман кишәрлеген бирмичә генә эшләр алып баруга рөхсәт бирү процедурасы билгеләнгән.

Урман фонды җирләрендә урман кишәрлеге тапшырылмыйча җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару өчен җир асты байлыкларыннан файдаланучы (алга таба – Мөрәҗәгать итүче) Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хакимияте органнарына яки җирле үзидарә органнарына язмача гариза тапшыра, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:

а) Гариза бирүче турында мәгълүматлар:

- тулысынча һәм кыскартылган аталышы һәм оешу-хокукый рәвеше, урнашкан җире һәм почта адресы, банк реквизитлары – юридик зат өчен;

- фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны буенча адресы, шәхесен таныклаучы документ белешмәләре, – шәхси эшкуар булып торучы граждан өчен;

2) планлаштырылган эшләрне башкару өчен кирәкле урман фонды җирләренең урнашкан урыны һәм мәйданы, урманнардан файдалану нигезләмәсе һәм җир асты байлыкларын геологик өйрәнү эшләрен башкару вакыты.

Гаризага Мөрәҗәгать итүче исеменнән эш йөртүче затның вәкаләтләрен таныклаучы документ теркәлә (зарурлык булганда).

Дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек юлы белән түбәндәге документларны ала:

1) юридик затка карата Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

2) физик затка карата Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

3) салым органында исәпкә куелу турында белешмәләр;

4) җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең яисә дәүләт ихтыяҗлары өчен җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкаруга дәүләт контракты булуы турында белешмәләр.

Гариза 30 көн эчендә карала һәм аталган эшләрне башкаруга рөхсәт бирү турында карар кабул ителә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү, файдалы казылма ятмаларын эшкәртү өчен эшләр башкару максатларында җир асты байлыкларыннан файдалану Россия Федерациясе субъектының Урман планы һәм урманчылыкның (урман паркының) урман хуҗалыгы регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару һәм файдалы казылма ятмаларын эшләү өчен урманнардан файдалану тәртибендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкаруга, файдалы казылма ятмаларын эшләүгә бәйле объектларны урнаштыру максатларында, барыннан да элек, урмансыз җирләрнең, ә урман кишәрлегендә андый җирләр булмаганда – агачлар киселгән, үрентеләре торгызылмаган, янгын булган җирләрнең, бушлыкларның, ачык урыннарның, шулай ук түбән тулылыктагы

һәм әллә ни кыйммәтле булмаган урман утыртмалары үсә торган мәйданнарның файдаланылуы күздә тотыла. Аталган максатлар өчен башка төрле урман кишәрлекләреннән файдалану җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкаруга, файдалы казылма ятмаларын эшләүгә бәйле объектларны урнаштыруның башка вариантлары мөмкин булмаган очракта гына рөхсәт ителә.

Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкаруга, файдалы казылма ятмаларын эшләүгә бәйле объектларны урнаштыру биләнүче һәм янәшә торучы территорияләрдә эрозия процессларының үсешенә юл куймаска тиеш.

РФ Урман кодексының 21 ст. 1 өл. 1-4 п.п. каралган максатларда (шул исәптән авария-коткару эшләрен уздыру максатларында), шул исәптән гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыруга билгеләнгән саклык зоналарында һәм санитар-яклау зоналарында, агачларны, куакларны, лианаларны сайланма һәм тоташ кисүләр рөхсәт ителә.

Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, файдалы казылма ятмаларын эшләү максатларында файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

бульдозер ярдәмендә агачлар аудару һәм урман кишәрлекләрен агач үсемлекләреннән чистарту, чик буе полосаларын һәм урман авызларын агач калдыклары белән чүпләү, урман авызындагы агач кәүсәләрен һәм скелет тамырларын зарарлау, җәйге чорда яңа киселгән үзагачларны махсус чараларсыз гына урманда саклау;

урман утыртмаларын суга батыру һәм озак итеп су бастыру;

тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларына, үсемлекләр капламына һәм туфракка зыян салу;

урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач, көнкүреш һәм бүтән калдыклар, чүпләр белән чүпләү;

тапшырылган урман кишәрлеге мәйданын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;

транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның бирелгән урман кишәрлегеннән читтәге юллардан гайре ирекле маршрутлар буенча узуы.

Урман-парк зоналарында файдалы казылма ятмаларын эшләү тыела.

Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, файдалы казылма ятмаларын эшләү максатларында файдаланучы затлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

файдаланыла торган урманнарны һәм аның янәшәсендәге урман кырыйларын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, сәнәгать, агач кисүдән калган, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, чүп-чарлардан даими рәвештә чистартып торуны;

житештерү эшчәнлеге барышында җимерелгән юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, күперләрне, башка гидротехника

корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын, аншлагларны, урманнар территориясен төзеклəндерү элементларын торгызуны;

Россия Федерациясе законнарына ярашлы рəвештə урман инфраструктурасы булдыруга бəйле булмаган, җир асты байлыкларын геологик өйрəнү, файдалы казылма ятмаларын эшлəп чыгаруга бəйле объектларны тиешле эшлəрне үтəү чорлары тəмамлану белəн консервациялəүне яисə юк итүне һəм күрсəтелгəн объектларны төзү, үзгəртеп кору һəм (яки) эксплуатациялəү өчен файдаланылган җирлəрне рекультивациялəүне;

аталган затлар гаебе белəн барлыкка килгəн һəлакəт очракларын һəм урман янгыннарын юкка чыгару, шулай ук башка шундый хəллəрне бетерү буенча кирəкле чаралар күрелүне;

сейсмик разведка эшлəрен планлаштыру һəм үткəрү, шулай ук хəрəкəт составын һəм йөклəрне яңа урынга күчерү максатларында квартал ызаннары, урман юллары билəгəн һəм урман утыртмалары белəн капланмаган башка җирлəрдəн максималь рəвештə файдалануны.

## 2.13. Урманнардан сусаклагычлар һəм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һəм махсуслаштырылган портлар төзү һəм эксплуатациялəү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һəм чорлары

Сусаклагычлар һəм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга портлары, причаллар төзү һəм аларны эксплуатациялəү өчен урманнардан файдалану РФ Урман кодексының 44 ст. нигезендə гамəлгə ашырыла.

Сусаклагычларны, башка төрле ясалма су объектларын, шулай ук гидротехника корылмаларын, диңгез портларын, диңгез терминалларын, елга портларын, причаллар төзү һəм аларны эксплуатациялəү өчен урманнардан файдалану су законнары нигезендə гамəлгə ашырыла.

РФ Су кодексының 1 статьясы су объекты дип табигый яисə ясалма сулыкны, су агып төшү урынын яисə суларның даими яисə вакытлыча җыелып торучы су режимының характерлы рəвешлəренə һəм сыйфатларына ия булган бөтəн су объектын аңларга киңəш итə.

Ясалма су объектларының төрлəре: сусаклагычлар, буалар һəм каналлар.

Урман хуҗалыгында сусаклагычлар һəм буалар асылда кече һəм уртача зурлыктагы елгаларда, шулай ук инешлəрдə аларның урманүткəрү сəлəтен көчəйтү, урман əзерлəүне һəм җитештерүнең бөтəн төрен су белəн тəэмин итү өчен корыла һəм файдаланыла.

Урман хуҗалыгында каналлар нигездə корыту, сугару, су бастыру һ.б. максатларында булдырыла һəм эксплуатациялəнə. Аерым очракларда сал агызу каналлары ясалырга һəм эксплуатациялəнергə мөмкин.

Шул ук максатларда гидротехника корылмалары булдырыла һəм эксплуатациялəнə, аларга «Гидротехника корылмаларының куркынычсызлыгы

турында» 1997 ел, 21 июль, № 117-ФЗ федераль законның 3 ст. нигезендә түбәндәгеләр керә:

плотиналар, гидроэлектростанция биналары, суташлагыч, суҗибәргеч һәм сучыгаргыч корылмалар, тунельләр, каналлар, насос станцияләре, суда йөзүче шлюзлар, судно күтәрткечләр;

сусаклагычларның ярларын, елга ярларын һәм үзән төбен су басудан һәм җимерелүдән саклау өчен билгеләнгән корылмалар; сәнәгый һәм авыл хуҗалыгы оешмаларының сыек калдыкларын саклагычларны чикләп торучы корылмалар (дамбалар).

каналларда су ашалудан саклау җайланмалары;

су ресурсларыннан файдалану һәм суларның һәм сыек калдыкларның тискәре йогынтысын бетерү өчен билгеләнгән башка төрле корылмалар, биналар, җайланмалар һәм объектлар, «Су белән тәэмин итү һәм су агызу турында» 2011 ел, 7 декабрь, № 416-ФЗ федераль законда каралган кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системасы объектларыннан тыш.

Сусаклагычлар, башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары, диңгез портлары, диңгез терминаллары, елга портлары, причаллар төзү һәм аларны эксплуатацияләү өчен урманнардан файдалану

РФ УК 21 ст. нигезендә гамәлгә ашырыла. Файдалануның әлеге төре урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектларны төзүгә, үзгәртеп коруга һәм эксплуатацияләүгә бәйле.

Урманнардан күрсәтелгән максатларда файдаланганда агачларны, куакларны, лианаларны кисү рөхсәт ителә, шул исәптән гражданнарның иминлеген тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыру өчен билгеләнгән саклык һәм санитар-яклау зоналарында (РФ УК 21 ст. 5 өл.).

РФ УК 21 ст. 4 өлеше нигезендә гидротехника корылмалары су законнарына туры китереп консервацияләнергә яисә ликвидацияләнергә тиеш.

Су объектын файдалануга тапшыру турындагы карарны әзерләү һәм кабул итү кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 ел, 30 декабрь, № 844 карары белән расланган.

Дәүләти һәм муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлекләре сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү өчен даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга, арендага яисә түләүсез сроклы файдалануга тапшырылырга мөмкин.

РФ УК 72 статьясының 3 өлеше һәм 74 статьясының 3 өлеше нигезендә күрсәтелгән урман кишәрлекләре атап үтелгән максатларда дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары карарлары нигезендә, аукционнар уздырмыйча гына, бер елдан алып кырык тугыз елга кадәрге чорга арендага тапшырыла. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган гариза килгән көннән соң утыз көннән артып китмәгән чорда дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә

органы үзләренең РФ УК 81-84 ст. билгеләнгән вәкаләтләре чигендә килгән гаризаны карыйлар һәм урман кишәрлегенең яңа аренда шартнамәсен төзүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерәләр һәм күрсәтелгән карау һәм тикшерү нәтиҗәсендә урман кишәрлегенең арендаторы булып торучы гражданин яисә юридик зат белән мондый урман кишәрлегенең яңа аренда шартнамәсен сатулар уздырмыйча төзү турында яисә РФ УК 74 ст. 2 өлешендә каралган шартларның берсе генә булса да үтәлмәгәндә мондый шартнамәне төзүдән баш тарту турында карар кабул итәләр. Мондый шартнамәне төзүдән баш тарту турында карарда тиешле карар кабул итүнең барлык нигезләре булырга тиеш.

Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнардан шушы рәвешле файдаланганда алынган үзагачка карата милекчелек хокукы Россия Федерациясенеке була (РФ УК 20 ст. 2 өлеше).

## 2.14. Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен файдалану РФ Урман кодексының 45 ст. нигезендә регламентлана.

РФ Урман кодексының 9 статьсы нигезендә урманнардан даими (вакытын чикләмичә) файдалану хокукы, чит урман кишәрлекләреннән чикләнгән рәвештә файдалану хокукы (сервитут), урман кишәрлекләрен арендага алу хокукы, шулай ук урманнардан түләүсез файдалану хокукы гражданлык законнарында, концессия килешүләре турында Россия Федерациясе законнарында, дәүләти-хосусый партнерлык, муниципаль-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе законнарында һәм җир законнарында, «Дәүләт мөлкәтендә яки муниципаль мөлкәттә торучы һәм Россия Федерациясе субъектларының Ерак көнчыгыш федераль округы составына керүче территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» федераль законда каралган нигезләрдә һәм тәртиптә барлыкка килә һәм туктатыла, әгәр әлеге Кодекста башкача каралмаган булса.

Урманнардан электртапшыру, элемтә линияләре, юллар, торбаүткәргечләр һәм линияле башка объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен файдалану Россия Рослесхозның 2011 ел, 10 июнь, № 223 боерыгы белән расланган Кагыйдәләр белән раслана.

Линияле объектлар төзү максатларында, барыннан да элек, урмансыз җирләр, ә урман кишәрлегендә андый җирләр булмаганда – кисүләрдән соң торгызылмаган кишәрлекләр, янгыннан калган җирләр, бушлыклар, ачык

урыннар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман утыртмалары үсә торган җирләр файдаланыла.

Линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү биләнгән һәм янәшә торучы территориядә эрозия процессларын арттырмаска тиеш.

Автомобиль юллары һәм тимер юллар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда җир өсте һәм туфрак эче агынтысын боза торган, юллар буендагы урман кишәрлекләрен су бастыра яки сазландыра торган очраклар булмаска тиеш.

Линияле объектлардан файдалану максатларында (шул исәптән авария-коткару эшләрен уздыру максатларында) шул исәптән гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү һәм тиешле объектларны эксплуатацияләү өчен кирәкле шартлар тудыруга билгеләнгән саклык зоналарында һәм санитар-яклау зоналарында, агачларны, куакларны, лианаларны сайланма һәм тоташ кисүләр рөхсәт ителә.

Урманнардан линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү максатларында файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә һәм тиешле саклык зонасында урман утыртмаларына, үсемлекләр капламына һәм туфракка зыян салу;

тапшырылган урман кишәрлеген читтә янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;

тапшырылган урман кишәрлеге мәйданын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;

транспорт чараларының һәм бүтән механизмнарның бирелгән урман кишәрлегеннән читтә һәм тиешле саклык зонасындагы юллардан гайре иректе, билгеләнмәгән маршрут буенча узуы

Линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү максатларында урманнардан файдаланучы затлар түбәндәгеләрне тәэмин итә:

тапшырылган урман кишәрлеген, аның янәшәсендәге урман аланнарын, ясалма һәм табигый су агып чыгу урыннарын төзелеш, урман кисү, көнкүреш һәм бүтән калдыклардан, агулы матдәләрдән даими рәвештә чистартып тора;

эшчәнлек барышында җимерелгән юлларны, киптерү канауларын, дренаж системаларын, шлюзларны, күперләрне, башка гидротехника корылмаларын, квартал баганаларын, квартал юлларын торгыза;

аталган затлар гаебе белән барлыкка килгән һәлакәт очракларын һәм урман янгыннарын юкка чыгара, шулай ук башка шундый хәлләрне бетерү буенча кирәкле чаралар күрә;

Линияле объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен урманнардан файдаланганда җимерелгән яисә пычранган җирләр Россия Федерациясе законнары таләпләренә ярашлы рәвештә рекультивацияләнергә тиеш.

Линияле объектларның саклык зоналарында барча киңлеге буйлап эрозия арту куркынычы барлыкка килгәндә туфрак катламы бозылган урыннарда үлән чәчү һәм (яки) куаклыклар утырту юлы белән җирләргә рекультивация уздырылырга тиеш.

Уртак файдаланудагы автомобиль юлларын һәм тимер юлларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнарның (шушы юллар буйларындагы яклаучы полосалар) хокукый режимы РФ УК 102 ст. белән регламентланган.

Урман фонды җирләрендә һәм энергетика җирләренә кертелмәгән башка категория урманнары үсә торган җирләрдә электртапшыру линияләре төзү өчен кирәкле урман фонды җир кишәрлегенең (җир кишәрлегенең бер өлешенең) зурлыгы Электр челтәрләренә хезмәт күрсәтүче һава электртапшыру линияләре һәм элемтә линияләре баганалары урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең зурлыкларын билгеләү кагыйдәләренең (РФ Хөкүмәтенең 2003 ел, 11 август, №486 карары белән расланган) 6 пункты нигезендә исәпләп чыгарыла.

Җир кишәрлегенең, шул исәптән көчәнеше 10 кВ артмаган һавадан электртапшыру линияләре баганалары (электр челтәренә хезмәт күрсәтүче элемтә линияләре баганалары) урнаштыру өчен җир кишәрлегенең җир өслегендә багананың аркылы кисеменә тигез булган контур мәйданы буларак минималь зурлыгы билгеләнде.

Көчәнеше 10 кВ артмаган һавадан электртапшыру линиясе баганасын урнаштыру өчен урман кишәрлегенең минималь зурлыгы түбәндәгечә билгеләнә:

җир өслегендә багана проекциясе контурыннан 1 м торган контур мәйданы (тарттырып торучы җайланмалардагы баганалар өчен – тарттыргычларны да кертеп), – авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре белән чиктәш булган, ригельләрен урнаштыру тирәнлеге 0,8 м артмаган баганалар урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләреннән кала, барлык категориядәге җирләрнең җир кишәрлекләре белән чиктәш торучы җир кишәрлекләре өчен;

җир өслегендә багана проекциясе контурыннан 1,5 м торган контур мәйданы (тарттырып торучы җайланмалардагы баганалар өчен – тарттыргычларны да кертеп), – авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир кишәрлекләре белән чиктәш торучы, ригельләрен урнаштыру тирәнлеге 0,8 м артмаган баганаларны урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре өчен.

330 кВ һәм аннан югарырак көчәнешле, конструкциясендә җиргә беркетелеп куела торган таягы (тарттырып торучы җайланмасы) кулланыла торган һавадан электртапшыру линияләре баганасын урнаштыру өчен аерып алынган җир кишәрлекләренең минималь зурлыкларын барлык категориядәге җирләрнең җир кишәрлекләре белән чиктәш торучы җир кишәрлекләре өчен (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) җир өслеге дәрәҗәсендә һәм таяныч җайланмасының (тарттырып торучы җайланмасының) тышкы контурларыннан – 1 м һәм авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җир

кишәрлекләре белән чиктәш торучы җир кишәрлекләре өчен 1,5 м торучы контурлар мәйданы буларак билгеләргә рөхсәт ителә.

Һавадан электртапшыру линиясе баганаларын (электр челтәрләренә хезмәт күрсәтүче элемтә линияләре баганаларын) урнаштыру өчен җир кишәрлекләренең билгеле бер зурлыклары баганаларны җиргә беркетү зарурлыгыннан, баганаларның зурлыкларыннан һәм типларыннан, грунтларның терәк була алу сәләтеннән һәм тотрыклылыгын һәм иминлекле эксплуатацияләнүен тәэмин итү максатында багана мәйданчыгын инженерия ягыннан төзекләндерү зарурлыгыннан чыгып билгеләнә.

Энергетика объектлары оешмалары эшчәнлеген тәэмин итү (РФ Җир кодексының 89 ст.) максатларында һәм электр хуҗалыгы объектларының һәм электр энергетикасының электр энергетикасы турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бүтән объектларының куркынычсыз һәм аварияләрсез функцияләвен, ышанычлы эксплуатацияләнүен тәэмин итү өчен, әлеге урман кишәрлекләре составына кергән җирләрнең категориясенә бәйсез рәвештә, җир кишәрлекләреннән файдалануда махсус шартлары булган саклык зоналары билгеләнә.

Мондый саклык зоналарын билгеләү һәм тиешле җир кишәрлекләреннән файдалану тәртибе РФ Хөкүмәтенең «Электр челтәрләре хуҗалыгы объектларының саклык зоналарын һәм мондый зоналарның чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануда махсус шартлар билгеләү тәртибе турында» 2009 ел, 24 февраль, № 160 карары белән билгеләнә (алга таба – Җир кишәрлекләренең саклык зоналарын һәм алардан файдалануңа махсус шартлар билгеләү кагыйдәләре). Электр энергетикасы объектларының саклык зоналары чикләрендә җир кишәрлекләреннән файдалану буенча махсус шартларны үтәүгә күзәтчелек федераль дәүләт энергетика күзәтчелеге буенча функцияләр йөкләнгән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Саклык зоналарында электртапшыру линияләрен һәм электр хуҗалыгының башка объектларын эксплуатацияләүдә куркынычсыз шартлар тәэмин итү һәм аларга зыян салыну мөмкинлеген юкка чыгару максатларында территорияләрдән файдалануда махсус шартлар билгеләнә.

Саклык зоналары челтәр оешмалары хисабыннан кисәтү тамгалы урнаштыру юлы белән маркаланырга тиеш, әлеге тамгаларда саклык зонасының зурлыгы, тиешле челтәр оешмасы турында мәгълүматлар, шулай ук Җир кишәрлекләренең саклык зоналарын һәм алардан файдалануда махсус шартлар билгеләү кагыйдәләрендә билгеләнгән чикләмәләрне үтәү зарурлыгы күрсәтелә.

Саклык зоналары чикләрендә челтәр оешмалары белән килештерү турында язмача рөхсәттән башка юридик һәм физик затларга түбәндәгеләр тыела:

биналар һәм корылмалар төзү, капиталь ремонтлау, үзгәртеп кору яки сүтү;

тау, шартлату, мелиоратив эшләр, шул исәптән җирләрне вакытлыча су бастыруга бәйле эшләр;

агачлар һәм куаклыклар утырту һәм кисү;

төпне тирәнәйтә, туфрак сосу һәм төяү-бушату эшләре, балык, судагы башка хайваннарны һәм үсемлекләрне су төбеннән тоту кораллары белән табу, сугару урыннары ясау, боз вату һәм әзерләү (электр тапшыру буенча су астындагы кабель линияләренең саклык зоналарында);

йөк белән яки йөктән башка вертикаль буенча иң биек ноктасыннан сулыклар аша электртапшыруның һава линияләре үтә торган урынның иң түбән ноктасына кадәр озынлыгы, шул исәптән ташу вакытында суның максималь күтәрелү дәрәҗәсен исәпкә алып, минималь дәрәҗәдә мөмкин булган озынлыктан азрак тәшкил иткән судноларның үтүе;

йөк белән бергә яки йөктән башка юл өслегеннән исәпләгәндә 4,5 метрдан биегрәк озынлыкта булган машиналарның һәм механизмнарның үтүе (электртапшыруның һава линияләрен саклау зоналарында);

0,3 метрадан тирәнрәк урында җир эшләре (сөрелә торган җирләрдә 0,45 метрдан тирәнрәк булган урыннарда), шулай ук грунт планлаштыру (электртапшыру буенча җир астындагы кабель линияләренең саклык зоналарында);

су агынтысының биеклеге 3 метрдан артып киткән очракта авыл хуҗалыгы культураларына су сибү (электртапшыру буенча һава линияләренең саклык зоналарында);

биеклеге 4 метрдан артып китә орган авыл хуҗалыгы машиналарыннан һәм җайланмаларыннан файдаланып, кырда авыл хуҗалыгы эшләрен башкару (электртапшыру буенча һава линияләренең саклык зоналарында) яки кырда җир сөрүгә бәйле авыл хуҗалыгы эшләрен башкару (электртапшыруның кабель линияләрен саклау зоналарында).

Челтәр оешмалары һәм бүтән затлар саклык зоналарында челтәр оешмасы белән килештерү турында язмача карар алмыйча эшләр башкарылу фактларын ачыклаган очракта, аталган затлар федераль дәүләт энергетика күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына мондый фактларның булуы турында гариза җибәрә, шулай ук Россия Федерациясе законнары нигезендә судка һәм (яки) тиешле хокук бозулар турында эшләрне карау өчен вәкаләтле булган башкарма хакимият органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Гамәлләр башкаруны килештерү турында язмача рөхсәт алу өчен мәнфәгатьле затлар язмача гариза белән электр хуҗалыгының тиешле объектларын эксплуатацияләү өчен җаваплы булган челтәр оешмасына (аның филиалына, вәкиллегенә яисә структур бүлекчәсенә) кирәкле эшләрне гамәлгә ашыра башлар алдыннан 15 эш көненнән соңга калмыйча мөрәҗәгать итә.

Челтәр оешмасы гариза килгән датадан соң 2 көн эчендә аны карый һәм тиешле эшләрне гамәлгә ашыруны килештерү (килештерүдән баш тарту) турында карар кабул итә.

Эшләрне гамәлгә ашыруны килештерү (килештерүдән баш тарту) турында язмача карар мөрәҗәгать итүчегә тапшырыла яки почта аша кулга тапшыру турында белдереп җибәрелә. Мөрәҗәгать итүчегә шулай ук челтәр оешмасы тарафыннан кабул ителгән карар турында факсимиль яки электрон элемтә чараларыннан файдаланып та хәбәр ителә, әгәр шушы рәвешле хәбәр итү зарурлыгы гаризада күрсәтелгән булса.

Әгәр тиешле эшләрне гамәлгә ашыру норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозса һәм тиешле электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары эшенә хилафлык китерергә мөмкин булса, эшләрне килештерүдән баш тарту рөхсәт ителә. Баш тарту нигезле булырга һәм мөрәҗәгать итүченең тиешле эшләрне башкаруы (тиешле гамәлләрне гамәлгә ашыруы) нәтиҗәсендә бозылачак норматив хокукый актларның нигезләмәләренә сылтамаларны үз эченә алырга тиеш.

Саклык зоналарында эшләрне гамәлгә ашыруны килештерү турында карар алган затлар аларны электр челтәрләре хуҗалыгы объектларын саклауны тәэмин итә торган шартларны үтәп гамәлгә ашырырга тиеш.

Саклык зоналарында шартлату эшләрен башкаруны килештерү турында язмача карар бу эшләрне башкаручы затлар билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән, шартлату эшләрен башкарганда норматив хокукый актларда билгеләнгән куркынычсызлык кагыйдәләрендә каралган техник документацияне (проектларны, паспортларны һ.б.) тапшырган очракта гына бирелә.

Биналар һәм корылмалар төзүне, капиталь ремонтлауны һәм үзгәртеп коруны килештерү турында язмача карар алынган очракта, күрсәтелгән гариза белән бер үк вакытта челтәр оешмасына тиешле объектларга карата эшләнгән проект документациясе дә җибәрелә. Шәһәр төзү эшчәнлеге турында законнар нигезендә мондый документацияне эшләү зарури булмаган очракта, мондый гариза белән бер үк вакытта төзергә планлаштырылган объект параметрлары (үзгәртеп корганда аның параметрларын үзгәртү) турында, шулай ук төзү, үзгәртеп кору һәм ремонтлау буенча эшләрнең сроклары һәм күләмнәре турында белешмәләр дә тапшырыла. Биналар һәм корыламалар төзүне, үзгәртеп коруны һәм ремонтлауны гамәлгә ашыруда мәнфәгатьле затлардан бүтән документларны һәм белешмәләрне таләп итү рөхсәт ителми.

Челтәр оешмаларының саклык зоналарында эшләрне гамәлгә ашыруны килештерү турында язмача карар бирүдән баш тартуына карата судка шикаять белдерелергә мөмкин.

Көчәнеше 1000 вольтка кадәрге электр челтәрләре хуҗалыгы объектлары өчен билгеләнгән саклык зоналарында, әлеге Кагыйдәләрнең 10 пунктында каралган эшләрдән тыш, челтәр оешмасы белән килештерү турында язмача карардан башка тыела:

а) балалар өчен һәм спорт мәйданчыклары, стадионнар, базарлар, сәүдә нокталары, кыр станнары, терлек өчен җәйләүләр, гаражлар һәм барча төр машиналар һәм механизмнар өчен тукталышлар, бакча һәм дача җир

кишәрлекләре, яшелчәчелек, бакчачылык һәм дача коммерциясез оешмалары, торак, шул исәптән индивидуаль, төзелеше объектлары урнаштыру (электр тапшыру буенча һава линияләренең саклык зоналарында);

б) теләсә нинди, шул исәптән ягулык-майлау материалларын туплау яки урнаштыру;

в) суднолар, баржалар һәм йөзә торган краннар өчен причаллар урнаштыру, суднолардан якорьлар ташлау һәм аларның бирелгән якорьлар, чылбырлар, лотлар, сөйрәткеләр һәм трал белән узуын гамәлгә ашыру (электр тапшыру буенча су асты кабель линияләре урнашкан саклык зоналарында).

Федераль дәүләт энергетика күзәтчелеген гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы саклык зоналарында әлеге Кагыйдәләрнең 8 һәм 9 пунктларында тыелган эшләрнең гамәлгә ашырылу фактларын яисә челтәр оешмасы белән килештерү турында язмача карар алмыйча әлеге Кагыйдәләрнең 10 һәм 11 пунктлары күздә тотыкан эшләрнең башкарылу фактларын ачыклаган очракта, күрсәтелгән органдагы вәкаләтле вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә тиешле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзи.

Саклык зоналарында электр хуҗалыгы объектларының иминлекле эшләвен бозарга мөмкин булган, шул исәптән аларның җимерелүенә яисә юкка чыгуына китереп чыгарырга һәм (яки) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә һәм физик яки юридик затларның мөлкәтенә зыян китерергә мөмкин булган, шулай ук экологиягә зыян салырга һәм янгыннар китереп чыгарырга мөмкин булган теләсә нинди эшләрне башкару тыела, шул исәптән:

а) электр тапшыру буенча һава линияләре үткәргечләренә һәм баганаларына предметлар атарга, шулай ук электр тапшыру буенча һава линияләре баганалары буйлап үрмәләп менәргә;

б) электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына үтү һәм килү буенча норматив-техник документлардагы таләпләргә туры китереп төзелгән урыннар чикләрендә теләсә нинди объектларны һәм предметларны (материалларны) урнаштырырга, шулай ук электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына үтеп керүгә комачауларга мөмкин булган теләсә нинди эшләрне, моны эшләү өчен кирәкле үтеп керү яисә килү мөмкинлекләрен булдырмыйча, уздырырга һәм корылмаларны торгызырга;

в) бүленеш корылмалары һәм подстанцияләренең әйләндереп алынган территорияләре чикләрендә һәм биналарында булырга, бүленеш корылмаларының һәм подстанцияләренең ишекләрен һәм люкларын ачарга, электр челтәрләрен яңача тоташтыруны һәм тоташтыруны башкарырга (әлеге таләп билгеләнгән тәртиптә рөхсәт ителгән эшләрне башкаручы хезмәткәрләргә кагылмый), кертү һәм бүлү җайланмаларының, подстанцияләрнең, электр тапшыру буенча һава линияләренең саклык зоналары чикләрендә, шулай ук электр тапшыру буенча кабель линияләренең саклык зоналарында учак ягарга;

г) чүплекләр урнаштырырга;

д) суга торган механизмнар белән эшләр башкарырга, 5 тоннадан авырлыклы әйберләр ташларга, зәһәр һәм тутык матдәләрен һәм ягулык-майлау материалларын ташлау һәм бушату рөхсәт ителми (электр тапшыру буенча җир асты кабель линияләренең саклык зоналарында).

Көчәнеше 1000 вольттан артык булган электр челтәрләрехуҗалыгы объектлары өчен билгеләнгән саклык зоналарында, әлеге Кагыйдәләрнең 8 пунктында каралган эшләрдән тыш, тыела:

а) теләсә нинди, шул исәптән ягулык-майлау материалларын туплау яки урнаштыру;

б) балалар өчен һәм спорт мәйданчыклары, стадионнар, базарлар, сәүдә нокталары, кыр станнары, терлек өчен җәйләүләр, гаражлар һәм машиналарның һәм механизмнарның барлык төрләре өчен тукталышлар ясау, билгеләнгән тәртиптә рөхсәт ителгән эшләрне башкармаучы кешеләрне күпләп туплый торган теләсә нинди чараларны уздыру (электр тапшыру буенча һава линияләренең саклык зоналарында);

в) теләсә нинди очкыч аппаратлардан файдалану (очыртып җибәрү), шул исәптән һава елланнарын, очкыч аппаратларның спорт модельләрен (электр тапшыру буенча һава линияләренең саклык зоналарында);

г) суднолардан якорьлар ташлау һәм аларның бирелгән якорьлар, чылбырлар, лотлар, сөйрәткеләр һәм трал белән узуын гамәлгә ашыру (электр тапшыру буенча су асты кабель линияләре урнашкан саклык зоналарында);

д) краннарының уклары күтәртелгән килеш судноларның һәм башка механизмнарның узып китүен гамәлгә ашыру (электр тапшыру буенча һава линияләренең саклык зоналарында).

Техник хезмәт күрсәтү буенча план (регламент) эшләре
электр челтәрләре хуҗалыгы объектларына карата җир кишәрлекләре милекчеләренә (җирдән файдаланучыларга, җир хуҗаларына, арендага алучыларга) алдан хәбәр итеп гамәлгә ашырыла.

Хәбәрләмә язмача рәвештә почта аша кулга тапшыру турында белдерү белән җибәрелә. Хәбәрләмәне җибәрү билгеләнгән тәртиптә язмача корреспонденцияне җибәрү буенча билгеле бер контроль чорларны исәпкә алып, тиешле эшләрне башлап җибәрү датасына кадәр 7 эш көненнән соңга калмыйча алынуын тәэмин итәрлек чорда гамәлгә ашырыла, аварияләрне туктату яисә ликвидацияләү буенча эшләр искәрмәле очраклар булып тора. Хәбәрләмдә эшләрнең озынлыгы, шулай ук эчтәлеге күрсәтелә.

Электр хуҗалыгы объектларының аварияләрсез функцияләнүен һәм эксплуатацияләнүен тәэмин итү өчен саклык зоналарында челтәр оешмалары яисә челтәр оешмалары белән тиешле шартнамәләр нигезендә гамәл кылучы оешмалар тарафыннан түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) күрсәтелгән зоналар урман биләмәләрендә һәм яшел утыртмаларда урнашкан очракта һавадан электртапшыру линияләре буйлап һәм подстанцияләрнең һәм бүлү җайланмалары периметры буйлап урман ызаннары салына һәм карап тотыла;

б) агачлар һәм куаклыклар ябалдашларына кадәр рөхсәт ителгән минималь аралык чикләрендә киселә һәм игәүләнә, шулай ук аву куркынычы янаган агачлар кисеп атыла.

Урман ызаннарын карап тотканда челтәр оешмалары түбәндәгеләрне тәэмин итәргә бурычлы:

а) урман ызаннарын урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре таләпләре нигезендә янгыннан ышанычлы торышта карап тотарга;

б) урман ызаннары киңлеген, агачларны (куакларны) кисеп ату яисә ябалдашларын кискәләү юлы һәм башка төрле ысуллар белән, электр хуҗалыгы объектларын төзү проектларында һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган таләпләрдә каралган зурлыкларда карап тотарга;

в) урман ызаннарында үсүче, биеклеге 4 метрдан артып китүче агачларны (урман утыртмаларын) кисәргә яисә ябалдашларын кискәләргә.

Кагыйдәләрнең 21 һәм 23 пунктларында каралган очракларда агачларны (куакларны һәм башка төрле утыртмаларны) кисү эше зарурлык очрагына карап, урман кишәрлекләрен алдан бирмичә генә гамәлгә ашырыла. Челтәр оешмалары яисә челтәр оешмалары белән тиешле шартнамәләр нигезендә эшләүче оешмалар вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары РФ УК 49 статьясы нигезендә урманнардан файдалану турында хисаплар тапшыра.

Урман фонды җирләрендә саклчык зоналары электртапшыру буенча һава линияләре буйлап җир кишәрлеге өслегенең һәм һава киңлегенең (электртапшыру буенча һава линияләре баганаларының биеклегенә туры килгән биеклектә) вертикаль параллель яссылыклар белән чикләнгән, электртапшыру линиясенең һәр ягында кырый үткәргечләрдән түбәндәгечә ераклыкларда үзләренең читкә тайпылмаган торышында торучы бер өлеше рәвешендә билгеләнә:

| Көчәнешнең проектта каралган номинал классы, кВ | Ераклыгы, м |
|---|---|
| 1 кадәр | 2 (биналарның стеналары, конструкцияләр һ.б. буйлап үзтотышлы яки изоляцияләнгән үткәргечле линияләр өчен саклык зонасы мондый линияләрдән норматив хокукый актларда билгеләнгән минималь мөмкин аралык белән билгеләнә) |
| 1-20 | 10 (5 – торак пунктлары чикләрендә урнаштырылган үзтотышлы яки изоляцияләнгән үткәргечле линияләр өчен) |
| 35 | 15 |
| 110 | 20 |
| 150, 220 | 25 |
| 300, 500, +/- 400 | 30 |
| 750, +/- 750 | 40 |
| 1150 | 55 |

Элемтә, радио элемтәсе, телевидение, информатика белән тәэмин итү максатларында (космик элемтәдән тыш) тиешле инфраструктура объектлары урнаштыру өчен җир кишәрлекләре бирелә, түбәндәгеләрне дә кертеп:

1) балансында радиорелейлы, һава, кабельле элемтә линияләре һәм тиешле читләштерү полосалары булган эксплуатацион элемтә предприятиеләре;

2) кабельле, радиорелейлы һәм һавадагы элемтә линияләре һәм кабельле һәм һава элемтә трассаларындагы радиофикация линияләре һәм элемтә линияләренең радиофикациясе һәм тиешле саклык зоналары;

3) җир астындагы кабельле һәм һава элемтә һәм радиофикация линияләре һәм элемтә линияләренең тиешле саклык зоналары;

4) элемтәнең кабель линияләрендә хезмәт күрсәтелми торган җир өсте һәм җир асты көчәйткеч пунктлары һәм тиешле саклык зоналары;

5) спутник элемтәсенең җир өсте корылмалары һәм инфраструктурасы.

«Элемтә турында» 2003 ел, 7 июль, №126-ФЗ федераль законда элемтә линияләре тапшыру линияләре, элемтәнең физик чылбырлары һәм линияле-кабельле корылмалары буларак билгели, элемтә челтәрләренең һәм элемтә корылмаларының саклык зоналарын билгели.

Җирләрдән элемтә максатларында файдалануга кагылышлы мәсьәләләр РФ Хөкүмәтенең 1995 ел, 9 июнь, № 578 карары белән расланган Россия Федерациясе элемтә линияләрен һәм корылмаларын саклау кагыйдәләрендә билгеләнгән.

Кабельле һәм һава элемтә линияләре трассаларында һәм радиофикация линияләрендә махсус файдаланулы саклык зоналары билгеләнә:

урмансыз урыннарда торак пунктларыннан читтә урнашкан элемтәнең җир астындагы кабель һәм һава линияләре һәм радиофикация линияләре өчен, – әлеге линияләр буйлап урнашкан җир кишәрлекләре рәвешендә, алар элемтәнең җир астындагы кабеле трассасыннан яки элемтәнең иң кырый һава үткәргечләреннән һәм радиофикация линияләреннән һәр яклап кимендә 2 метрда торучы параллель турылар буларак билгеләнә;

элемтәнең диңгездәге кабель линияләре һәм суднолар йөри торган һәм сал агыза торган елгалар, күлләр, сусаклагычлар һәм каналлар (арыклар) аша узганда элемтә кабельләре өчен, – су өслегеннән су төбенә кадәр бөтен тирәнлеге буенча су тирәлеген тәшкил итүче кишәрлек рәвешендә, ул диңгездәге кабель трассасыннан һәр ягыннан 0,25 диңгез миленә тигез булган ераклыкта яки елгалар, күлләр, сусаклагычлар һәм каналлар (арыклар) кичүендә һәр ягыннан 100 метрга тигез булган ераклыкта торучы параллель өслекләр буларак билгеләнә;

җир өслегендә һәм җир астында элемтәнең кабель линияләрендә хезмәт күрсәтелми торган ток көчәйткеч һәм регенерация пунктларында, – җир кишәрлекләре рәвешендә, алар көчәйткеч һәм регенерация пунктлары урнашкан үзәктән яки алар тирәли вал салыну чикләреннән кимендә 3 метр

ераклыкта һәм җиргә беркетү контурларыннан кимендә 2 метр ераклыкта торучы йомык линияләр белән билгеләнә.

Кабель һәм һава элемтә линияләре трассаларында урман биләмәләрендә һәм урман утыртмаларында түбәндәгечә урман ызаннары ясалырга тиеш:

агачларның биеклеге 4 метрдан кимрәк булганда – һава элемтә линияләренең һәм радиофикация линияләренең кырый үткәргечләре арасында кимендә плюс 4 м киңлегендә (кырый үткәргечләрдән агач ботакларына кадәр һәрьяклап 2шәр метр);

утыртмалар биеклеге 4 метрдан биегрәк булганда – һава элемтә линияләренең һәм радиофикация линияләренең кырый үткәргечләре арасында кимендә плюс 6 м киңлегендә (кырый үткәргечләрдән агач ботакларына кадәр һәрьяклап 3әр метр);

элемтә кабеле трассасы буйлап – кимендә 6 метр киңлектә (элемтә кабеленнән һәрьяклап 3әр метр);

элемтә линияләренең һәм корылмаларының, радиофикация линияләренең һәм корылмаларының саклык зоналарындагы барлык эшләр эшләрне башкару һәм кабул итү кагыйдәләре буенча гамәлгә норматив документларны үтәп башкарыла.

Элемтә линияләре трассалары даими рәвештә куаклыклардан һәм агачлардан чистартылырга, янгынга каршы куркынычсыз торышта тотылырга, ызаннарның билгеләнгән киңлеге үзгәртелмичә тотылырга тиеш. Элемтә линияләре үткәргечләренә һәм элемтә линияләре баганаларына куркыныч тудыра торган агачлар билгеләнгән тәртиптә агач кисү билетларын (ордерларын) рәсмиләштереп, кисеп атылырга тиеш.

Урман биләмәләре һәм урман утыртмалары буенча уза торган кабель һәм һава элемтә линияләре ёщм радиофикация элемтәсе өчен ызаннар шушы элемтә линияләре белән эш итүче предприятиеләрнең көче белән янгын куркынычы күзлегеннән караганда иминлекле торышта тотылырга тиеш.

Әгәр гамәлдәге кабельле һәм һава элемтә линияләре трассалары тыюлыклар, беренче төркем урманнары һәм махсус саклanучы башка территорияләр буйлап узса, махсус саклanучы кишәрлекләрнең (сирәк һәм югала баручы хайван төрләрен ашату урыннары, кыйммәтле балык токымнарының уылдык чәчү урыннары һ. б.) вазыйфаи әһәмиятен киметү күренеше булмаганда гына урман ызаннары ясау рөхсәт ителә.

Паркларда, бакчаларда, тыюлыкларда, шәһәрләр һәм торак пунктлар тирәсендәге яшел зоналарда, кыйммәтле урман биләмәләрендә, кыряклагыч урман утыртмаларында, автомобиль юллары һәм тимер юллар буендагы яклаучы урман полосаларында, елгалар һәм каналлар буендагы, күлләр һәм башка сулыклар тирәсендәге тыюлыклы урман полосаларында ызаннар ясау утыртмаларның торышына мөмкин кадәр аз зыян китереп һәм аларның яклау үзенчәлекләре югалмаслык итеп башкарылырга тиеш. Ызаннарда куаклыклар һәм яшь агачлар киселмәскә (кабельле элемтә линияләренең ызаннары гайре),

йомшак туфракларда, текә урыннарда (15 градустан югары) һәм сулар белән юыла торган урыннарда түмәрләр казып алынмаска тиеш.

Элемтә линияләре һәм радиофикация элемтәләре белән эш итүче предприятиеләргә саклык зоналарында түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

үз хисабыннан юллар, килә торган юллар, күперләр һәм элемтә линияләренә һәм радиофикация линияләренә эксплуатацияле хезмәт күрсүтү өчен кирәкле башка корылмаларны җир милекчеләре (җир хуҗалары, җирдән файдаланучылар, арендаторлар) белән килештерелгән шартларда төзү, соңгылары әлеге предприятиеләргә элемтә корылмаларына эксплуатацияле хезмәт күрсәтү өчен шартлар тудырудан баш тартырга хокуклы түгел;

элемтә линияләрен һәм радиофикация линияләрен ремонтлау өчен, алга таба күмеп, чокырлар, траншеялар һәм нигез чокырлары казу;

урман биләмәләре аша уза торган элемтә линияләрендә һәм радиофикация линияләрендә аварияләр булганда, алга таба билгеләнгән тәртиптә агач кисү билетларын (ордерларын) биреп һәм әлеге линия трассаларына янәшә урнашкан җирләрдә алга таба кисү калдыкларын чистарту шарты белән аерым агачларны кисеп ату.

РФ Җир кодексының 90 ст. 6 өлешенә ярашлы рәвештә, трубаүткәргеч оешмаларының эшчәнлеген һәм әлеге өлкә объектларының эксплуатацияләнүен тәэмин итү максатларында, түбәндәгеләр өчен җир кишәрлекләре бирелергә мөмкин:

1) нефтьүткәргечләр, газүткәргечләр, башка төрле трубаүткәргеч системасындагы җир өсте объектларын урнаштыру;

2) трубаүткәргеч транспортның җир өсте һәм җир асты биналарын, корылмаларын, җайланмаларын һәм башка төрле объектларын эксплуатацияләү, карап тоту, төзү, үзгәртеп кору, ремонтлау өчен кирәкле җир өсте объектларын урнаштыру.

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 ел, 31 март, № 69-ФЗ федераль законның 28 ст. нигезендә урманнардагы газ белән тәэмин итү системасы объектлары (аларга газүткәргечләр дә керә) белән эш итүче оешмаларның бурычларына түбәндәгеләр керә:

газ белән тәэмин итү системасының саклык зоналарын янгын куркынычы янамаган торышта карап тоту;

газ белән тәэмин итү системасының саклык зоналарында һәм мондый зоналардан читтә Россия Федерациясе урман законнарында билгеләнгән тәртиптә планлаштырылган эшләрне башкару, агачларны (куакларны) кисү.

РФ Хөкүмәтенең 2000 ел, 20 ноябрь, № 878 карары белән расланган Газ бүлү челтәрләрен саклау кагыйдәләрендә саклык зоналары – файдалануда махсус шартлары булган, газүткәргеч трассалары буйлап һәм газ бүлү челтәренең башка объектлары тирәли билгеләнә торган, аның нормаль шартларда эксплуатацияләнүен һәм аңа зыян салыну мөмкинлеген юкка чыгара торган территорияләр карала.

Саклык зоналары урманнар буйлап уза торган поселокара газүткәргеч трассалары буйларында, – газүткәргечнең һәр ягыннан 3әр м, 6 м киңлегендәге ызаннар рәвешендә билгеләнә.

Газүткәргечләрнең җир өслегендәге өлешләре өчен агачлар белән газүткәргеч арасы газүткәргечне эксплуатацияләү вакытында агач биеклегеннән ким булмаска тиеш.

Газ бүлү челтәрләренең саклык зоналары урманнар буенча һәм агач-куак үсә торган урыннардан узганда газ бүлү челтәрләренең эксплуатация оешмалары үз хисабына:

газ бүлү челтәрләренең саклык зоналарын (ызаннарны) янгыннан имин торышта карап тотарга;

ызаннарның чикләре буйлап кимендә 1,4 м киңлегендәге минераллаштырылган полосалар ясарга;

һәр 5-7 км саен янгынга каршы техника узып йөрерлек юллар ясарга тиеш.

Мондый саклык зоналарында һәм алардан читтә эшләр башкару Россия Федерациясе урман законнары белән билгеләнгән тәртиптә башкарылырга тиеш.

Авария очракларында эксплуатацияләү оешмасына, соңыннан акт рәсмиләштерү шарты белән, техника һәм материаллар китертү өчен иң кыска маршрут буенча газ бүлү челтәрләренә килергә рөхсәт ителә.

Аталган эшләрне урманнар һәм агач-куак үсемлекләре аша уза торган газүткәргечләрдә уздырганда, соңыннан бер айлык срокта урман кисү билетларын рәсмиләштереп һәм киселгән урыннарны кисек агач калдыкларыннан чистартып, агачларны кисү рөхсәт ителә.

Урман фонды җирләрендә газ бүлү челтәрләренә ремонт ясау, аларга хезмәт күрсәтү яисә аварияләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшләрен башкарганнан соң эксплуатацияләү оешмасы бу җирләрне башлангыч хәленә кайтарырга (рекультивацияләргә) һәм аларны акт буенча милекчесенә, хуҗасына, җир кишәрлегеннән файдаланучыга яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән затка тапшырырга тиеш.

Газ белән тәэмин итү системасы объектында авария, һәлакәт барлыкка килгән очракта мондый системаның милекчесе яки аның тарафыннан вәкаләт бирелгән оешма кирәкле көчләрне һәм чараларны авария, һәлакәт урынына каршылыксыз китерү хокукына ия һәм территориясе буйлап кирәкле көчләрне һәм чараларны китерү гамәлгә ашырылган җир кишәрлеге милекчесенә китерелгән барлык зыянны тулы күләмендә капларга тиеш.

Газ белән тәэмин итү системасы объектларына тоташып торучы җир кишәрлекләрендә мондый объектларны куркынычсыз эксплуатацияләү максатларында газүткәргечләрнең саклык зоналары билгеләнә. Аталган җир кишәрлекләренең хуҗалары аларны хуҗалык өчен файдаланганда, газ белән тәэмин итү системасының милекче булган оешма яки аның тарафтан вәкаләт бирелгән оешма белән килештермичә, газ белән тәэмин итү системасы

объектларына кадәр билгеләнгән минималь аралыклар чигендә нинди дә булса биналар, төзелмәләр, корылмалар төзи алмыйлар; мондый хуҗалар белән тәэмин итү системасының милекче булган оешмага яки аның тарафтан вәкаләт бирелгән оешмага газ белән тәэмин итү системасы объектына хезмәт күрсәтү һәм аны төзәтү, анда барлыкка килгән аварияләрне, һәлакәтләрнең нәтиҗәләрен бетерү эшен башкаруда каршылык тудырырга хокуклы түгел.

## 2.15. Урманнардан агач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын яклаучы урманнарда һәм урманнарның махсус яклanучы кишәрлекләрендә урнаштыру рөхсәт ителми.

Агач материалы һәм бүтән урман ресурслары эшкәртү өчен урман кишәрлекләреннән файдалану РФ Урман кодексының 46 ст. белән регламентлана, Татарстан Республикасының урман планы һәм урманчылыкның урман регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнардан агач материалын һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдаланучы затларның хокуклары:

РФ УК 13 ст. 1 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы (урман юллары, урман саклыкханәләре һәм башкасы) булдыру;

РФ УК 14 ст. 1 өлеше нигезендә агач эшкәртү инфраструктурасы (әзерләнгән агач материалын эшкәртү объектлары, биоэнергетика объектлары һәм башкасы) булдыру;

урман фонды җирләрендә РФ УК 21 ст. 1 өлеше нигезендә урман инфраструктурасы булдыруга бәйле булмаган объектларны төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү;

Россия Федерациясе Урман кодексында каралган бүтән хокукларны гамәлгә ашыру.

Урманнардан агач материалын һәм башка урман ресурсларын эшкәртү өчен файдаланучы затларның бурычлары:

урман кишәрлегенең аренда шартнамәсе яки Россия Федерациясе Урман кодексының 46 статьясы нигезендә урман кишәрлеген даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшыру турында карар шартларын үтәү;

Россия Федерациясе Урман кодексының 88 статьясының 1 өлеше нигезендә урманнарны үзләштерү проектын төзү;

урманнардан урманнарны үзләштерү проекты нигезендә файдалану;

Россия Федерациясе Урман кодексының 50.1 статьясында каралганча, агач материалын исәпкә алуны гамәлгә ашыру;

урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрендә, урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләрендә, урманнарны тәрбияләү кагыйдәләрендә билгеләнгән таләпләрне үтәү;

Россия Федерациясе Урман кодексының 26 статьясының 2 өлеше нигезендә ел саен урман декларациясен тапшыру;

Россия Федерациясе Урман кодексының 49 статьясының 1 өлеше нигезендә урманнардан файдалану турында хисап тапшыру;

Россия Федерациясе Урман кодексының 60 статьясының 1 өлеше нигезендә урманнарны саклау һәм яклау турында хисап тапшыру;

Россия Федерациясе Урман кодексының 91 статьясының 4 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Урман кодексының 91 статьясының 2 өлешендә каралган документлаштырылган мәгълүматларны дәүләт урман реестрына тапшыру;

Россия Федерациясе Урман кодексында каралган бүтән бурычларны үтәү

Урман эшкәртү инфраструктурасы объектларын урнаштыру максатларында, барыннан да элек, урмансыз җирләр, ә урман кишәрлегендә андый җирләр булмаганда – кисүләрдән соң торгызылмаган кишәрлекләр, янгыннан калган җирләр, бушлыклар, ачык урыннар, шулай ук тулылыгы һәм кыйммәте түбән булган урман утыртмалары үсә торган җирләр файдаланыла.

Бүтән урман кишәрлекләреннән күрсәтелгән максатларда файдалану күрсәтелгән объектларны урнаштыруның башка вариантлары булмаганда рөхсәт ителә.

Агач материалы һәм бүтән урман ресурслары эшкәртү өчен урманнардан файдалану кагыйдәләре РФ Табигать министрлыгының «Урманнардан агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2014 ел, 01 декабрь, № 528 боерыгында билгеләнә.

## 2.16. Урманнардан дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалану нормативлары, параметрлары һәм чорлары

Урманнар дини оешмалар тарафыннан РФ УК 47 ст. һәм «Вөҗдан иреге һәм дини берләшмәләр турында» 1997 ел, 26 сентябрь, № 125-ФЗ федераль закон нигезендә дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдаланылырга мөмкин.

Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә дини һәм хәйриячелек билгеләнешендәге биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне торгызу рөхсәт ителә (РФ Урман кодексының 47 ст. 2 өлеше).

Дәүләти яки муниципаль мөлкәттә булган урман кишәрлекләре дини оешмаларга дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен түләүсез нигездә файдалануга тапшырыла.

Урман ресурсларын әзерләү һәм җыю, авыл хуҗалыгын алып бару һәм башка төрле шундый эшчәнлек дини оешмалар тарафыннан аларга тапшырылган урман кишәрлекләрендә РФ Урман кодексының 32, 34, 34,38 ст. нигезендә гамәлгә ашырылырга мөмкин.

Урманнардан шушы рәвешле файдалану урман кишәрлекләрен тапшырып, әмма урман ресурсларын алмыйча гамәлгә ашырыла.

Урманнардан дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдаланучы субъектлар дип һәм, әлбәттә инде, тиешле урман кишәрлекләренә карата милекчелек хокуклары субъектлары дип дини оешмалар дип игълан ителә.

«Намус иреге турында һәм дини берләшмәләр турында» 1997 ел, 26 сентябрь, № 125-ФЗ федераль законның 8 статьясы нигезендә Россия Федерациясе гражданнарының, Россия Федерациясе территориясендә даими рәвештә һәм законлы нигезләрдә яшәүче бүтән затларның бергәләп гыйбадәт кылу һәм динне тарату максатларында төзелгән һәм законда билгеләнгән тәртиптә юридик затлар буларак теркәлгән ирекле берләшмәсе дини оешма дип танылa.

Юридик зат статусына ия булмаган дини берләшмәләргә, шулай ук дини төркемнәргә һәм аларда катнашучыларга дини максатларда урманнарны файдалану өчен тапшыру каралмаган. «Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 ел, 08 август № 129-ФЗ федераль закон нигезендә дини оешмалар дәүләт теркәвенә алынырга тиеш (намус иреге һәм дин тоту иреге турындагы законнарда билгеләнгән дини оешмаларны дәүләт теркәвенә алу тәртибен исәпкә алып).

РФ Урман кодексының 47 статьясының 3 өлешенә ярашлы рәвештә, дәүләти яисә муниципаль мөлкәттәге урман кишәрлекләре дини оешмаларга дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен түләүсез нигездә файдалануга тапшырыла.

РФ Урман кодексының 25 ст. билгеләнгән эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен урман кишәрлекләре арендага, даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга тапшырылган затлар эшчәнлекне Дәүләт экспертизасы нәтиҗәләре буенча уңай бәяләмә алган урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашыра.

## 2.17. Урманнарны саклауга, яклауга һәм торгызуга карата таләпләр

### 2.17.1. Урманнарда янгын куркынычсызлыгы чараларына, урманнарны радиоактив матдәләр белән пычранудан һәм тискәре башка йогынтыдан саклауга карата таләпләр

Урманнарны янгынга каршы кору, шул исәптән янгынга каршы билгеләнгән юлларны төзү, үзгәртеп кору һәм карап тоту, урман ызаннары салу, янгынга каршы чокырлар казу түбәндәгечә башкарыла:

туфрак тыгызлыгы 1дән алып 5 Ки/км$^2$ һәм 5тән башлап 15 Ки/км$^2$ тәшкил иткән цезий-137 белән пычранган зоналарда һәм 0,15тән башлап 1 Ки/км$^2$ кадәр һәм 1дән башлап 3 Ки/км$^2$ тәшкил иткән стронций-90 белән пычранган барлык урман үсә торган зоналарда һәм урманлы районнарда – туфрагы, агачлары һәм урманның башка компонентлары радиоактив пычрануга бәйле рәвештә билгеле бер төзәтмәләр һәм чикләмәләр белән;

Россия Федерациясенең Европа өлешендәге ылыслы-киң яфраклы урманнарның урманлы районында туфрагы тыгызлыгы 15тән 40 Ки/км$^2$ башлап 40 Ки/км$^2$ артык тәшкил иткән цезий-137 белән пычранган зоналарда һәм 3 Ки/км$^2$ югары тәшкил иткән стронций-90 белән пычранган Көньяк-Урал урман районында – махсус эшләнгән проектлар буенча җирле үзидарә органнары рөхсәте нигезендә, санитар-эпидемиология күзәтчелегенең территориаль үзәкләре һәм әйләнә-тирә мохитне саклау органнары киңәшләрен исәпкә алып.

Уртак файдаланудагы, урман кишәрлекләре һәм киптерелгән торфлыклар аша уза торган магистраль юллар буенда тәмәке тартуны һәм ачык ут куллануны тыя торган аншлаглар һәм тамгалар урнаштырыла. Алар буйлап киңлеге кимендә 3 метрлы минераллаштырылган полосалар ясала. Авыл хуҗалыгы биләмәләре булган урман биләмәләре чикләре буйлап та, шулай ук һәлак булган урман кишәрлекләре тирәли дә шундый ук полосалар салына. Алар тузан барлыкка килүне булдырмас өчен туфрак артык дымланган чорларда булдырыла һәм яңартылып тора.

Урманнарны янгыннардан саклау РФ Урман кодексының 51, 53 статьялары, «Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 ел, 21 декабрь, № 69-ФЗ федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 ел, 30 июнь, № 417 карары белән расланган Россия Федерациясе урманнарында янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре (алга таба – Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре урманнарны саклаганда, яклаганда һәм яңадан үстергәндә, урманнарда бүтән эшчәнлекне гамәлгә ашырганда, шулай ук гражданнар урманнарда булганда урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итүгә карата бердәм таләпләр урнаштыра һәм дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, шулай ук юридик затлар һәм гражданнар өчен үтәү өчен мәҗбүри булып тора.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре һәр урман районы өчен Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгы тарафыннан билгеләнә.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

а) урманнарны янгынга каршы төзекләндерү, шул исәптән янгынга каршы билгеләнештәге юлларны, урманнарны саклау һәм яклау буенча авиация эшләрен үткәрү максатларында самолетларга, вертолетларга утыру мәйданчыкларын төзү, үзгәртеп кору һәм карап тоту, ызаннар, янгынга каршы аралыклар ясау;

б) урманнарда янгыннарны кисәтү һәм сүндерү системаларын, чараларын булдыру, шушы системаларны һәм чараларны карап тоту, шулай ук янгын чыгу куркынычы югары булган чорда ягулык-майлау материаллары запасларын формалаштыру;

в) урманнарда янгын чыгу куркынычын һәм урман янгыннарын мониторинглау;

г) урман янгыннарын сүндерү планнарын эшләү;

д) урманнардагы янгыннарны сүндерү;

е) урманнарда янгын куркынычсызлыгы буенча бүтән чаралар.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгының санап үтелгән чаралары дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан, аларның вәкаләтләре чикләрендә, РФ Урман кодексының 81-84 статьялары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарда янгын куркынычсызлыгы буенча гомуми таләпләр.

Кар катламы эреп беткән көннән башлап көзге тотрыклы яңгырлы һава торышы урнашканчыга кадәрге яисә кар капласы барлыкка килгәнчегә кадәрге чорда урманнарда түбәндәгеләр тыела:

а) ылыслы яшь урманнарда, янгын булып узган, зыян салынган урын кишәрлекләрендә, торфлыкларда, агачлар киселгән (диләнкеләрдә), агач кисү калдыкларыннан һәм әзерләнгән агачтан чистартылмаган урыннарда, үләне корыган урыннарда, шулай ук агачларның ябалдашлары астында учак ягу. Киңлеге кимендә 0,5 метрлы минераллаштырылган полоса (ягъни туфракның минерал өлешенә кадәп чистартылган) белән әйләндереп алынган бүтән урыннарда учаклар ягу рөхсәт ителә. Киселүдән калган агач калдыкларын яндырып бетергәннән соң яисә учактан башка максатта файдалангач, учак урыны әйбәтләп туфрак белән күмелергә яисә пыску күренеше тулысынча юкка чыкканчыга кадәр су сибелергә тиеш;

б) янып торган шырпы, тәмәке төпчекләре һәм тәмәке төрепкәсеннән көл, пыяла (пыяла шешәләр, банкалар һәм башкалар) ташлау;

в) ау вакытында ягулык яисә пыскып торучы материаллардан тыккычлар куллану;

г) бензин, керосин яисә башка ягулык матдәләре сеңгән материалларны (кәгазь, тукыма, пәҗи, мамык һәм башкалар) шуның өчен махсус каралмаган урыннарда калдыру;

д) двигатель эшләп торганда эчке янулы двигательләр бакларына ягулык салу, туклану системасы төзек булмаган двигательле машиналардан файдалану, шулай ук ягулык салына торган машиналар янәшәсендә тәмәке тарту яисә ачык уттан файдалану.

е) торфлыкларда ачык ялкын белән эшләр башкару.

Кар катламы эреп беткән көннән башлап тотрыклы көзге яңгырлар чоры яки кар катламы барлыкка килгәнчегә кадәрге чорда урманга янәшә торучы территорияләргә ия булган, алардан файдаланучы һәм (яки) алар белән эш итүче дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, учреждениеләр, оешмалар, оешу-хокук формасына һәм мөлкәт формасына бәйсез рәвештә бүтән юридик затлар, крестьян (фермер) хуҗалыклары, иҗтимагый берләшмәләр, шәхси эшкуарлар, вазыйфаи затлар, Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар урманнан кимендә 10 метр киңлектәге полосада аның коры үлән үсемлекләреннән, камыл калдыкларыннан, ауган агачлардан, кисенте калдыкларыннан, чүп-чардан һәм

янучан башка материаллардан чистартылуын тәэмин итә яисә кимендә 0,5 метр киңлегендәге янгынга каршы минераллаштырылган полоса белән яки янгынга каршы башка төрле киртә белән урманны аерып ала.

Урманнарны көнкүреш, төзелеш һәм бүтән төрле калдыклар белән чүпләү тыела.

Торак пункттан чыгарылган чүпне яндыру урман янәшәсендә бары тик махсус билгеләнгән урыннарда гына түбәндәге шартлар булганда рөхсәт ителә:

а) чүп яндыру урыннары (чокырлар яисә мәйданчыклар) түбәндәгечә ераклыкта урнашырга тиеш, кимендә:

1) ылыслы урманнан яисә аерым үсеп утыручы ылыслы агачлардан һәм яшь агачлардан 100 метр;

2) яфраклы урманнан яисә аерым үсеп утыручы яфраклы агачлардан һәм яшь агачлардан 50 метр;

б) чүп яндыру урыны тирәсендәге территория (чокырлар яисә мәйданчыклар) 25-30 метр радиуста корыган агачлардан, ауган агачлардан, кисек калдыкларыннан, башка ягулык материалларыннан чистартылган һәм һәрберсенең киңлеге кимендә 1,4 метр булган ике катлы минераллаштырылган полосалар белән, ә коры туфраклардагы ылыслы урман янәшәсендә һәрберсенең киңлеге кимендә 2,6 метр, аралары 5 метр булган ике катлы минераллаштырылган полосалар белән әйләндереп алынган булырга тиеш.

Урманнарда янгын чыгу куркынычы чорында чүп яндыру бары тик һава торышына карап һәм җаваплы затлар контролендә генә рөхсәт ителә.

Урманнарга, яклаучы һәм урман утыртмаларына турыдан-туры тоташа торган һәм кимендә 0,5 метр киңлегендәге янгынга каршы минераллаштырылган полоса белән аерып алынмаган җир кишәрлекләрендә туз, урман түшәмәсе, коры үлән һәм башка янучан урман материалларын яндыру тыела.

Урманчылыкта янгын куркынычсызлыгын күзәтүне һәм тикшереп торуны оештыру буенча чаралар исемлеге

| № | Чара төре | Уздыру чоры |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Янгын куркынычы чорына әзерләнү буенча урманнан файдаланучыларны, аларның янгынга каршы җайланмалар, инвентарь белән тәэмин ителешен тикшереп тору. | 10 апрельгә кадәр |
| 2 | Диләнкеләрнең, юл яны полосаларының, электртапшыру линияләренең агач кисү калдыкларыннан һәм ауган агачлардан, урманчылыкның барча территориясендә әзерләнгән агачлардан чистартылуын тәэмин итү | янгын куркынычы янаган сезон башланганчы |
| 3 | Гамәлдәге янгынга каршы чокырларны тиешле торышка китерү, чүп-чардан һәм корыган үсемлекләрдән чистарту, янгынга каршы билгеләнгән юлларны ремонтлау һәм төзү. | Апрель-сентябрь |

| № | Чара төре | Уздыру чоры |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 4 | Янгын сакчылары көче белән җир өсте маршрутлары һәм патрульлек итү тәртибе билгеләү, аларны транспорт, янгын сүндерү һәм элемтә чаралары белән тәэмин итү. | Янгын куркынычы янаган чорда |
| 5 | Торак пунктларында ирекле янгын дружиналары оештыру, дружина әгъзаларын янгын сүндерүнең гади ысулларына өйрәтү. | Янгын куркынычы янаган сезон алдыннан |
| 6 | Урман фондына илтүче юлларда динамиклар белән җиһазланган автомобильләр ярдәмендә гражданнарга урманда янгын куркынычсызлыгы буенча чараларны үтәү турында мөрәҗәгать тапшыруны оештыру, бәйрәм һәм ял көннәрендә кизү торулар оештыру. | Янгын куркынычы чыгу югары торган чорларда |
| 7 | Автомобиль транспортына урман фондына керүне чикли торган юл билгеләре урнаштыру. | Янгын куркынычы чыгу югары торган чорларда |
| 8 | Урманнарда янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре үтәлүен тикшереп торуны көчәйтү | Янгын куркынычы янаган чорда |
| 9 | Урманнарны янгыннардан саклау һәм урманга карата сакчыл караш буенча пропагандалауны көчәйтү. | Апрель-сентябрь |
| 10 | Ылыслы урман диварларыннан 100 метрдан кимрәк аралыкта һәм яфраклы утыртмалар диварыннан 50 метрдан кимрәк аралыкта печән, салам өюне тыю. | Янгын куркынычы янаган чорда |
| 11 | Урман кварталларын авыл хуҗалыгы формированиеләренә беркетү (кушымта) | май |
| 12 | Барлыкка килгән урман янгыны турында хәбәр итүне оештыру | Янгын куркынычы янаган чорда |
| 13 | Җирдән һәм һавадан урманнарны патрульләүне оештыру | Янгын куркынычы янаган чорда |

Урманчылык мәйданы янгын чыгу куркынычы классларына бүленеше 14.2 таблицада китерелде.

14.2 таблица

Урман фонды җирләре мәйданының табигый янгын куркынычы класслары буенча бүленеше

| Кишәрлек урманчылыгының атылышы | Янгын чыгу куркынычы классы | | | | | Җәм-гысе | Уртача классы, |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | I | II | III | IV | V | | |
| 1 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. Зәй-Каратай | 545.3 | 32.3 | 3035.8 | 5205.8 | 82.8 | 8902 | 3,5 |
| 2. Лениногорск | 912.1 | 82.5 | 5248.8 | 6276 | 405.6 | 12925 | 3,4 |
| 3. Түбән Чыршылы | 169.8 | - | 2186.4 | 9166.7 | 65.1 | 11588 | 3,8 |
| 4. Иске Куак | 500.8 | 63.6 | 3226.9 | 5200.9 | 113.8 | 9106 | 3,5 |
| 5. Шөгер | 567.5 | 5.5 | 4003.6 | 5627.6 | 111.8 | 10316 | 3,5 |
| Урманчылык буенча | 2695.5 | 183.9 | 17701.5 | 31477 | 779.1 | 52837 | 3,5 |

| | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| барлыгы | | | | | | | |
| % | 5,1 | 0,3 | 33,5 | 59,6 | 1,5 | 100,0 | |

Урманнарда янгыннар килеп чыгуга бәйле куркыныч дәрәҗәсе «Урманнарның табигый янгын чыгу куркынычы классификациясен һәм, һава шартларына карап, урманнарда янгын чыгу куркынычы классификациясен раслау турында» 2011 ел, 05 июль, № 287 Рослесхоз боерыгына нигезләнеп бәяләнде.

Шкала, токым составы үзенчәлекләрен, туфрак дымлылыгын, урман утыртмаларының яшен һәм торышын исәпкә алып, туфраклы-типологик принцип буенча төзелде.

14.2.1 таблица.

Урманнарның табигый янгын куркынычы классификациясе

| Урманнарның табигый янгын куркынычы классы | Ут элү объекты (кисүләрдән соң урманнарның, урман утыртмаларының һәм урмансыз киңлекләрнең характерлы типлары) | Мөмкин булган янгын төрләре, аларны барлыкка китерергә һәм җәелдерергә мөмкин булган чор шартлары һәм озынлыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| I (бик югары табигый янгын куркынычы) | Ылыслы яшь агачлар. Тоташ кисү урыннары: мүкле, арчанлы, кылганлы һәм коры урыннар буенча кисүләр (бигрәк тә чүпләнгән).<br>Мүкле һәм арчанлы наратлыклар.<br>Зәгыйфьләнгән, корып баручы һәм бик зарарланган агачлыклар (корыган агачлар, агачларын җил-буран аударган, кисеп бетерелмәгән урыннар), аерым агачларны калдырып, тоташ кисү урыннары, югары һәм бик югары интенсивлыктагы сайлап алып кисү урыннары, янгын булып, чүпләнгән урыннар. | Янгын чыгу куркынычы югары торган чор дәвамында – аскы өлештә, агачлар үсә торган урыннарда – өске өлештә янгыннар булырга мөмкин. Кылганлы һәм үләнле бүтән коры урыннарда агач киселгән җирләрдә бигрәк тә язын, ә кайбер районнарда көзен янгын чыгу куркынычы аеруча зур була. |
| II (табигый янгын куркынычы – югары) | Нарат җиләкле, нарат шытымнары яисә уртача куелыктагы артыш куаклыклары булган наратлыкларда.<br>Кедрлы-җиргә җәелеп үсә торган куаклы яфраклы агачлар. | Янгын куркынычы югары булган чор дәвамында аскы өлештә; өске өлештә – янгыннар максимумнары чорында (янгын чыгу саны яисә янгын элеп алган мәйдан әлеге район өчен күпьеллык күрсәткечләрдән артып китә торган чор дәвамында). |
| III (табигый янгын куркынычы – уртача) | Ачы җиләкле наратлыклар һәм кара җиләклекләр, нарат җиләкле яфраклылар, барлык типтагы кедрлыклар, сфагналы, нарат җиләкле чыршылыклар һәм ачы җиләклекләр. | Аскы һәм өске янгыннар җәйге максимум чорында булырга мөмкин, ә кедрлыкларда, моннан тыш, язгы һәм бигрәк тә көзге максимумнарда. |
| IV (табигый | Тубылгылы һәм озын мүкле тоташ кисү | Янгын чыгу (беренче чиратта |

| Урманнарның табигый янгын куркынычы классы | Ут элү объекты (кисүләрдән соң урманнарның, урман утыртмаларының һәм урмансыз киңлекләрнең характерлы типлары) | Мөмкин булган янгын төрләре, аларны барлыкка китерергә һәм җәелдерергә мөмкин булган чор шартлары һәм озынлыгы |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| янгын куркынычы – аз дәрәҗәле) | урыннары (аеруча чүпле). Үләнле тип урманнары шартларында наратлыклар, карагачлыклар һәм яфраклы агач токымнары урманнары. Катлаулы нарат һәм чыршы урманнары, юкәле, чикләвекле, имәнле, чыршылы урманнар – кара җиләклекләр, сфагналы һәм озын мүкле нарат урманнары, елга буйларында үсә торган һәм сфагналы кедр урманнары, каен-мүк җиләге урманнары, кымызлыклы, кара җиләкле һәм сфагналы урманнар, усаклы-кымызлыклы һәм кара җиләкле, куе урманнар. | аскы) күренешләре үләнле тип урманнарында, тубылгылы һәм озын мүкле кисү урыннарында язгы һәм көзге максимумнар чорында; башка тип урманнарында һәм озын мүкле кисүләрдә җәйге максимум чорында күзәтелергә мөмкин. |
| V (табигый янгын куркынычы юк) | Озын мүкле чыршы, каен һәм усак урманнары, сфагнумлы һәм елга буйларында үсә торган чыршы урманнары. Төрле типтагы зиреклекләр. | Янгын бары тик аеруча начар шартларда (дәвамлы корылык) гына чыгарга мөмкин. |

Искәрмәләр: Янгын чыгу куркынычы түбәндәге урманнар өчен бер класска югарырак билгеләнә:

төзелеше яисә бүтән үзенчәлекләре аскы янгын кинәт кенә өске янгынга күчү мөмкинлеге булган ылыслы урман үсентеләре өчен (ылыслы агачларның биек куе шытымнары булган токымнары, агачларның һәм куакларның ябалдашлары вертикаль рәвештә ябылган урман үсентеләре, шактый гына чүпләнү һ.б.);

табигый янгын чыгару куркынычы югары булган урман утыртмалары әйләндереп алган коры урыннарда зур булмаган урман кишәрлекләре өчен;

гомуми файдаланудагы автомобиль юллары һәм тимер юллар янәшәсендәге урман кишәрлекләре өчен.

Куе шытымнары булган яисә ябалдашлары вертикаль рәвештә ябылган кедрлыклар II класслы янгын куркынычына кертелә.

## Урманнарда һава торышына карап янгын куркынычы классификациясе

1. Һава торышына карап, урманнарда янгын чыгу куркынычын классификацияләү урманнарда янгын чыгу куркынычына йогынты ясый торган метеорологик шартларга карап, тиешле территориядә урман янгыннары чыгу (мөмкинлеге) дәрәҗәсен билгели.

2. Классификацияләү (бәяләү) максатлары өчен метеорология (һава торышы) шартларын характерлый торган комплекслы күрсәткеч кулланыла.

3. Комплекслы күрсәткеч зурлыгына карап, урманнарда һава торышына бәйле рәвештә янгын чыгу куркынычы классы билгеләнә.

Комплекслы күрсәткеч һәр көн саен 12-14 сәгатьләрдә билгеләнә.

4. Россия Федерациясе субъектларында һава торышына карап, урманнарда янгын чыгу куркынычының иөбәк класслары (алага таба – төбәк класслары) гамәлдә, алар түбәндәгеләрне билгели:

комплекслы күрсәткечне исәпләп чыгару методикасын;

янгын чыгу куркынычы классы чикләрен;

явым-төшемнәрне исәпләп чыгару методикасын.

Төбәк классларын куллану турындагы карар Федераль урман хуҗалыгы агентлыгы боерыгы нигезендә рәсмиләштерелә һәм төрле вакыт чорлары өчен аерым билгеләнергә мөмкин.

5. Төбәк класслары билгеләнмәгән төбәкләр өчен, һава торышына карап, урманнарда янгын чыгу куркынычының таблицада күрсәтелгән федераль класслары билгеләнә.

6. Һава торышына карап, урманнарда табигый янгын чыгу куркынычы классын исәпләп чыгару формуласы һава температурасын (t°) һава температураларының һәм яңгырсыз n көн эчендә чык ноктасының (ул) аермасына тапкырчыгышы суммасы рәвешендә билгеләнә (яңгырсыз чорда 3 мм артыграк явым-төшем төшкән көн беренче көн дип санап):

1

$$КП = SUM\,[t^\circ (t^\circ - ул)]$$

N

14.2.2 таблица.

Урманнарда һава торышына карап, янгын чыгу куркынычының федераль класслары

| Урманнардагы янгын чыгу куркынычы классы | Комплекслы күрсәткеч зурлыгы | Янгын чыгуга бәйле куркыныч дәрәҗәсе |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| I | 0 ... 300 | Юк |
| II | 301 ... 1000 | Аз |
| III | 1001 ... 4000 | Уртача |
| IV | 4001 ... 10000 | Югары |
| V | 10 000 артык | Гадәттән тыш |

РФ Хөкүмәтенең «Урманнарны янгынга каршы кору чаралары турында» 2011 ел, 16 апрель, № 281 карарына, «Урманнарны янгынга каршы кору нормативлары раслау турында» 2012 ел, 27 апрель, № 174 боерыгына таянып, регламентта табигый һәм икътисадый шартларны, урманнарның пирологик сыйфатламаларын, янгынның потенциаль чыганакларын исәпкә алып, янгынга каршы чаралар комплексы билгеләнде.

Урманнарны янгынга каршы кору чараларына түбәндәгеләр кертелә:

урман юлларын чистарту, аларның янгынга каршы минераллаштырылган полосаларын яңарту;

янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү;

урманнарда гражданнар ял итә торган зоналарны төзекләндерү;

янгынга каршы киртәләр кору һәм карап тоту, яфраклы урман кырыйларын кору;

урманнарда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында мәгълүматы булган стендлар һәм башка тамгалар урнаштыру.

шлагбаумнар кую һәм эксплуатацияләү, янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү максатларында, урманнарда гражданнарның булуын чикләүне тәэмин итәрлек киртәләр кору.

Янгынга каршы кору чараларының ел саен башкарыла торган күләме 14.2.3 таблицада күрсәтелде.

14.2.3 таблица.

Янгынга каршы кору буенча ел саен башкарыла торган чаралар күләме

| № п/п | Чараларның аталышы | Үлч.бер эм. | Таләп ителә торган күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Кисәтү чаралары | | |
| 1.1 | Даими күргәзмәләр һәм витриналар | данә | 1 |
| 1.2 | Даими стендлар | данә | 3 |
| 1.3 | Кисәтүче аншлаглар | данә | 6 |
| 1.4 | Авыл хуҗалыгы формированиеләре вәкилләре белән киңәшмәләр | данә | Зарурлыкка карап даими |
| 1.5 | Шлагбаумнар урнаштыру | данә | 3 |
| 1.6 | Ял итү һәм тәмәке тарту урыннарын оештыру | данә | 75 |
| 1.7 | Ирекле янгын сүндерүче дружиналар оештыру | данә | 5 (ел саен) |
| 2. | Янгыннар таралуны чикләү чаралары | | |
| 2.1 | Янгынга каршы киртәләр, чокырлар ясау | км | планлаштырылмый |
| 2.2 | Янгынга каршы минераллаштырылган полосалар урнаштыру (ел саен) | км | 125 |
| 2.3 | Янгынга каршы минераллаштырылган полосаларны чистарту һәм яңарту (ел саен) | км | 518 |
| 2.4 | Ызаннарны чистарту | км | 23 (ел саен) |
| 3. | Юллар төзелеше | | |
| 3.1 | Урман юллары төзү урманнарны янгыннардан саклау өчен | км | 14 |
| 3.2 | Урман юллары төзү, урманнарны янгыннардан саклау өчен | км | 44 |
| 3.3 | Урманнарны янгыннардан саклау өчен билгеләнгән урман юлларын эксплуатацияләү | | 306 |
| 4. | Дозор-сак хезмәте | | |
| 4.1 | Вакытлы янгын сакчыларын яллау | кеше | 4 |

| №<br>п/п | Чараларның аталышы | Үлч.бер<br>әм. | Таләп ителә торган<br>күләме |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 5. | Янгыннарга каршы көрәш чаралары | | |
| 5.1 | Я/к су белән тәэмин итү чыганакларына килү юллары ясау | данә | 5 |
| 5.2 | Янгынга каршы инвентарь туплау пунктлары оештыру | данә | 5 |
| 5.3 | Янгын сүндерү сулыклары ясау | данә | 5 |
| 5.4 | Янгынга каршы сулыкларны һәм су белән тәэмин итү чыганакларына килү юлларын эксплуатацияләү | данә | булганнары санына карап |
| 6. | Янгынга каршы җайланмалар сатып алу | | |
| 6.1 | Урман-янгын сүндерү автомашиналары | данә | 1 |
| 6.2 | Янгын мотопомпалары | данә | 2 |
| 6.3 | Басымлы янгын җиңсәләре | пог. м | 1000 |
| 6.4 | Уткабызгыч аппаратлар | данә | 10 |
| 6.5 | Бензопычкылар | данә | 10 |
| 6.6 | Ранецлы урман янгын сүндергечләре | данә | 30 |
| 6.7 | Кул кораллары: | | |
| | Көрәкләр | данә | 30 |
| | Балталар | данә | 20 |
| | тәкмәннәр | данә | 20 |
| | тырмалар | данә | 20 |
| | аркылы пычкылар | данә | 10 |
| 7. | Янгын чыгу куркынычын мониторинглау: | мең га | 52837 (ел саен) |
| | Ел саен урманнарны янгыннардан саклау буенча планлаштырылган чараларга чыгымнар күләме – барлыгы | мең сум | Республика буенча тулаем каралган |
| | шул исәптән: | | |
| | – Урман янгыннарын сүндерү буенча системалар һәм чаралар булдыру (ПНВ, радио-телефон элемтәсен, моторлы транспортны карап тоту, янгын сакчылары яллау) | мең сум | -//- |
| | – Урман янгыннарын сүндерү | мең сум | -//- |
| | – Авиапатруль | мең сум | -//- |
| | – Башка төрле чаралар (ш.и. янгынга каршы пропаганда) | мең сум | -//- |

Урманнарны янгыннардан саклаганда эш урыннары урнаштыру һәм планлаштыру нормативлары 14.2.4 таблицада китерелде

14.2.4 таблица.

## Урманнарны янгыннардан саклаганда эш урыннарын урнаштыру һәм планлаштыру нормативлары

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Гомуми нормативлар: | |
| 1.1 | Шәһәр урманнарын урман-янгын районнарына бүлү: | |
| | җир өстендә саклау районнары | янгыннарны ачыклау һәм сүндерү җир өсте чаралары белән гамәлгә ашырыла |
| 1.2 | Янгын куркынычы дәрәҗәсе буенча кишәрлекләрне бәяләү: | |
| | югары<br>уртача<br>түбән | үсеш алу урыны шартларына карап –<br>1-2 класслар, һава шартларына карап –<br>4-5 класслар, 3 класс |
| 1.3 | Урманнарның фактта яну чоры (янгын куркынычы тудыручы һава торышы чоры) | Һава шартлары буенча янгын куркынычының 2-5 классы көннәре |
| 1.4 | Урманчылык буенча янгын куркынычының фактик озынлыгын билгеләү | Кар катламы кузгалу һәм барлыкка килү. 10 һәм аннан күбрәк ел дәвамында урманнарның фактик януының максималь һәм уртача озынлыгы. Җирле шкалалар буенча һава торышының янгын чыгу куркынычы дәрәҗәсе – һава торышының 2 класслы янгын куркынычы башлану һәм бетүнең иң соңгы һәм уртача даталары |
| 1.5 | Урманнарда чагыштырмача янучанлык | Янгыннарның уртача еллык мәйданын урманнар мәйданына бүлүдән килеп чыккан зурлык |
| 1.6 | Урман янгыннарының зурлыклары:<br>зур<br>исәпкә алырлык | <br>мәйданы 25 га артык<br><br>теләсә нинди мәйданда шәһәр урманнары территориясендә янып китү |
| 1.7 | Янгын куәте<br>түбән<br>уртача<br>югары | <br>ялкын биеклеге 0,5 м һәм аннан түбәнрәк<br>ялкын биеклеге 0,6-1,0 метр<br>1,0 метрдан биек |
| 2 | Җир өстендәге сак районнарында урманнарны янгынга каршы планлаштыру нормативлары: | |
| 2.1 | ылыслы токымнарда эре янгын куркынычын планлаштыру | Өске һәм түбәнге янгыннарга таралуга каршы киртә, шулай ук барлыкка килгән янгыннарны локальләштергәндә терәк линияләре буларак хезмәт итүче янгынга каршы табигый яки ясалма киртәләр һәм аралыклар белән 2-12 мең гектаргача мәйданлы зур йомык блокларга бүлү (аларның янгын чыгу куркынычы дәрәҗәсенә һәм урман хуҗалыгы интенсивлыгына карап). Аларда уртак юл челтәрләренә керү урыны булган юллар салалар |
| 2.2 | Урман биләмәләре территориясендә | Су баса торган киң тугайлары булган зур күлләр һәм елгалар, яфраклы токымнар өстенлек иткән урман кишәрлекләре |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | янгынга каршы табигый киртәләр сайлау | (составы буенча кимендә 7 берәмлек), урманнар һәм янучан материаллар капламаган кишәрлекләр |
| 2.3 | Янгынга каршы ясалма киртәләр һәм аралыклар сайлап алу | Тимер юл трассалары һәм автомобиль юллары, электр тапшыру линияләре һәм торбаүткәргечләр һ.б. һәр ягы буйлап мөмкин булган саен 50-60 метр киңлектәге яфраклы агачлык полосасын утырталар. Киртәнең гомуми киңлеге – 120-150 метр. Яфраклы полосаларның урманга карап торган тышкы ягы буенча 1,4 м киңлектәге минполосалар булдырыла, ә әгәр дә яфраклы полосалар янгын куркынычы буенча 1 һәм 2 классына караучы кишәрлекләргә якын урнашса – бер-берсеннән 5-10 м ераклыктагы ике минполоса булдырыла. Яфраклы полосаларны утырту мөмкин булмаган ылыслы урман утыртмалары территориясе (урман бүлемтеге сәбәпле) чокырның һәр ягыннан киңлеге 120-150 м булган полосаларда янучан материаллардан (агач материалы чүбеннән, ылыслы шытымнардан, янгын куркынычы булган урманчыклардан, ылыслыларның 1,5-2,0 м кадәрле аскы ботакларыннан һ.б.) даими рәвештә чистартып торыла. Ылыслы урманның мондый полосаларын янәшә урнашкан урманнан чиклиләр һәм буйлы юнәлештә һәр 20-30 м саен 1,4 м киңлектәге минполосалар белән аералар. Мондый төп каршылыкларның гомуми киңлеге (чокыр яки юлларның киңлеге белән берлектә) – 260-320 метр. |
| 2.4 | Янгынга каршы өстәмә киртәләр һәм аралыклар ясау | 2.2 һәм 2.3 пунктларда күрсәтелгән киртәләр тиешле күләмдә булмаган очракта, блок буйлатып йомык боҗра булдыру өчен аларда юллар һәм һәр як буйлап яфраклы полосалар булдырып, чокырлар казыйлар |
| 2.5 | Уртача интенсивтагы урман хуҗалыгы алып барыла торган зоналарда урнашкан, янып киту дәрәҗәсе югары булган аеручы кыйммәтле ылыслы токым биләмәләрен планлаштыру | 2-12 мең га (2.1 пунктны кара) кадәр мәйданлы эре блокларны һәм биләмәләрне, үз чиратында, уртасыннан, зурлыгы буенча, мәйданы 400-1600 гектарлы йомык блокларны киртәләр (чокырлар, ялкынга каршы саклагычлар) ярдәмендә 2.2-2.4 пунктларда бәян ителгән тәртиптә аералар. Шул ук вакытта киң кулланылыштагы (тимер юл, шоссе) юлларның һәр ягы буенча яфраклы полосаларны (хуҗалары көче белән) 30-50 м киңлектә, ә башка чокырлар, шул исәптән кварталлардагы урман юллары буйлап һәр ягыннан 10-15 метр киңлектә булдыралар. Ылыслы агачлыкларның чокырга янәшә торучы аеручa кыйммәтле биләмәләрендә (яфраклы полосалар ясау мөмкинлеге булмаганда) киңлеге 100 метрлы полосаларны һәр яклап янучан материаллардан чистарталар һәм, әлеге таблицаның 2.3 п. күрсәтелгәнчә, һәр 20-30 метр саен буйдан-буйга минполосалар ясыйлар. Яфраклы токымнардан мондый эчке (өстәмә) ышыкларның киңлеге 60-100 метр булырга тиеш, ылыслы токымнардан – 200 метр, урман ызаннары буйлап – 20-30 метр (чокырларның һәм урман ызаннары киңлеген исәпкә алмыйча) |
| 2.6 | Яшел зона | Аларны янгынга каршы билгеләнештәге минполосалар яисә |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) | |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | |
| | урманнарында һәм 1 төркемдәге башка урманнарда ылыслы культураларның һәм яшь урманнарның эре кишәрлекләрен планлаштыру | юллар ярдәмендә 25 гектарлы блокларга бүләләр, һәр ягында яфраклы яшь агачлардан һәм куаклыклардан 10 м киңлегендәге полосалар ясала. Үзәге буйлап гади юл белән берлектә каплавычның гомуми киңлеге – 30 метр. Әгәр яфраклы полосалар утырту мөмкинлеге булмаса, ул чакта аралыкка янәшә торучы ылыслы агачларда һәр ягыннан 100 м киңлегендәге полосаларда янучан материалны алып ташларга, шулай ук һәр 20-30 м саен (әлеге табл. 2.3 пунктын кара) буйлы минполосалар салырга кирәк. | |
| 2.7 | Поселоклар янәшәсендә ылыслы урманнар планлаштыру | Урман биләмәсе тирәли янгынга чыдам, киңлеге кимендә 150 метрлы яфраклы урман кашаклары булдырыла. Мондый урман кашакларының ике чиге буйлап кимендә 2,5 метрлы минполосалар ясала. Әгәр яфраклы урман кашакларын булдыру мөмкин булмаса, ул вакытта поселокка якын урнашкан ылыслы урман полосаларында 250-300 метрлы киңлектә янучан материалларны тулысынча алып бетерәләр һәм алар буйлап һәр 50 метр саен буйлы минполосалар салалар (әлеге таблицаның 2.3 п. кара). | |
| 2.8 | Яклаучы миниполосаларны бульдозерлар, тракторлар, туфрак эшкәртүче һәм башка төр кораллар ярдәмендә туфрак өстендәге каплам төренә һәм куәтенә бәйле рәвештә салганда: | | |
| | лишайниклардан һәм яшел мүкләрдән җиләклекләрдән һәм арчаннан<br>куәтле үлән катламы булган урыннарда һәм чүпләнгән кишәрлекләрдә | 1,0 м башлап 1,5 м кадәр<br><br>1,5 м башлап 2,5 м кадәр<br>2,5 м башлап 4,0 м кадәр<br>1,4 м (бер мәртәбә ПКЛ-70 сукасы белән узганда ясала) | Бары тик полоса киңлеге түбәнге янгынның мөмкин булган биеклегеннән ике мәртәбә артык булу шарты белән генә тотрыклылык сыйфатында хезмәт итә алалар |
| | блоклар һәм ылыслы биләмәләр арасындагы минималь киңлек (әлеге таблицаның 2.1, 2.5-2.7 пунктлары) | корылмалар, урман культуралары, табигый шытып чыккан, кыйммәтле яшь ылыслы агач агачлар, ылыслы урман үсентеләрендә уза торган агач ташу юллары буйларында, минераллаштырылган полосаларның дәвамы буларак ылыслы урманнарда ясалган янгынга каршы барьерларда, шулай ук бу эш таләп ителгән башка урыннарда | |
| | янгын куркынычы янаган чорга калдырылган урман продуктлары һәм кисенте калдыклары булган коры туфраклардагы тигезлекле ылыслы урманнарның диләнкеләрендә | агач әзерләүчеләрнең көче белән диләнкеләр минераллаштырылган полосалар белән әйләндереп алына. Мәйданы 25 гектардан зуррак булган диләнкеләрне аркылы минполосалар белән 25 гектардан артмаган кишәрлекләргә аералар. Аларга агач өеп кую урыннары шулай ук аерым йомык минераллаштырылган полосалар белән, ә ылыслы кисенте урыннарында бер-берсеннән 5-10 м ара белән шундый ике полоса белән әйләндереп алына | |
| | тимер юллар, шосселар һәм агач ташу юллары | алар буйларындагы полосаларны (агач ташу өчен – һәр ягыннан 10 метр) янгын сезоны эчендә ауган агачлардан, агач | |

<table>
<tr><th>№ п/п</th><th>Күрсәткечләр</th><th colspan="2">Нормативлар (оптималь күрсәткечләр)</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td colspan="2">3</td></tr>
<tr><td></td><td>буйларында (алар карый торган оешмалар ярдәмендә)</td><td colspan="2">чүпләреннән һәм башка тиз кабынып китүчән материаллардан чистартып торыла. Минераллаштырылган полосаларны чигерелгән полосаларның тышкы ягы буйлап салалар, коры туфраклы ылыслы урманнарда – бер-берсеннән 5 метр ераклыкта ике минераллаштырылган полоса салына.<br>Шушындый ук шартларда минераллаштырылган полосалар белән юл буйларында яткан шпал өемнәрен һәм кар саклау щитларын, агач күперләрне, стационар платформаларны, торак йортларны һәм юлларны карап йөрүчеләр будкаларын әйләндереп алалар, учак ягу рөхсәт ителгән урыннар, урманда ял итү һәм тәмәке тарту урыннары, урманнарда эшләр башкарганда ЯММ саклау урыннары тирәли, янгын куркынычы урман промыселлары мәйданчыклары тирәли (күмер ягу, сагыз, дегет эшкәртү һәм башкалар), арадаш һәм төп чәер складлары тирәли, авыл хуҗалыгы җирләре чикләре буйлап әйләндереп алалар.</td></tr>
<tr><td rowspan="2">2.9</td><td colspan="3">Янгын куркынычы сезонында янгынга каршы аермалар кору:</td></tr>
<tr><td>урманда агач саклыханәләре тирәли</td><td colspan="2">саклыкханәләрне ачык урыннарда түбәндәге аралыкта урнаштыралар: яфраклы урман диварларыннан склад урыннары мәйданы 8 га – 20 метрга кадәр, 8 га һәм аннан да күбрәк – 30 метр, ылыслы һәм катнаш урман диварларыннан складлаштыру урыннары мәйданы 8 га – 40 метр, 8 га аннан да күбрәк – 60 метр.<br>саклыкка кую урыннары һәм күрсәтелгән янгынга каршы аермалар янучан материаллардан чистартыла</td></tr>
<tr><td>2.10</td><td colspan="3">Янгын сүндерү сулыклары ясау: урман янгыннары килеп чыгу мөмкинлеге булган урыннан ерак урнашкан су чыганаклары ясау:</td></tr>
<tr><td rowspan="7"></td><td>утыртмаларның янгын куркынычы классы</td><td>ераклыгы, чм</td><td>бер сулыктан су белән тәэмин ителә торган агачлар мәйданы, га</td></tr>
<tr><td>1</td><td>2–4</td><td>500</td></tr>
<tr><td>2</td><td>2–8</td><td>2000–5000</td></tr>
<tr><td>3–5</td><td>8–12</td><td>5000–10000</td></tr>
<tr><td>янгын сүндерү өчен табигый су чыганакларын әзерләү</td><td colspan="2">аларга килү юлларын төзекләндерү, янгын автоцистерналары һәм мотопомпалар белән су алу өчен махсус мәйданчыкларны җиһазландыру, зарурлык очракларында сулыкларны тирәнәйтү яки буалар ясау</td></tr>
<tr><td>янгын сүндерү буенча ясалма сулыклар төзү</td><td colspan="2">югары янгын куркынычы булган урман биләмәләрендә, аларда табигый су чыганаклары булмаса, яхшыртылган автомобиль юлларына янәшә сулыкларга килә торган юллар салына</td></tr>
<tr><td>янгынга каршы сулыкта нәтиҗәле су запасы</td><td colspan="2">җәйнең иң эссе чорында кимендә 100 куб метр</td></tr>
</table>

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 2.11 | Урман юллары ясау: | |
| | юл челтәрләренең гомуми калынлыгы (куелыгы) | 1000 га гомуми мәйданга кимендә 6 км, шул исәптән янгын куркынычы түбән булган һәм янгын тиз таралмый торган урман үсентеләре өстенлек иткән кварталларда юллар челтәре куелыгы 6 км/мең гектар рөхсәт ителә, янгын куркынычы югары булган урман үсентеләре өстенлек иткән кварталларда ул бу күрсәткечтән артык булырга тиеш |
| | урман хуҗалыгы юллары | урман янгыннары белән көрәш өчен түгел, урман хуҗалыгы ихтыяҗлары өчен кирәкле юллары булган кишәрлекләрдә урман хуҗалыгы интенсив алып барыла торган үзләштерелгән урманнарда корыла. 5 категория гомуми файдаланудагы юлларга тиңләштерелә һәм 3 типка бүленә.<br>1 типлы урман хуҗалыгы юллары:<br>бер полосалы, полосаларның гомуми киңлеге – 8 метр, юл кырыйларының киңлеге – 1,75 метр.<br>Исәпләп чыгарылган хәрәкәт тизлеге – 60 км/сәг, сикәлтәле урыннарда 40 км/сәг кадәр киметеп |
| | янгынга каршы билгеләнеш юллары | урман хуҗалыгы буенча 3 типлы билгеләнеш юлларына карыйлар, җир капламының киңлеге – 4,5 метр, юл кырыйлары киңлеге – 0,5 шәр метр. Аларны гамәлдәге урман юллары челтәрләренә өстәмә коралар, автотранспорт янгын буенча куркыныч саналган урыннарга һәм сулыкларга үтеп керә алсын өчен. Аларга шулай ук табигый грунт юллары, квартал урман юллары һәм төрле трассалар кертелә |
| 2.12 | Көчләрне һәм чараларны янгын сүндерү урынына илтеп җиткерү вакыты | Янгын беленгәннән соң 3 сәгатьтән дә артмаска тиеш. Ә янгын куркынычы югары булган кишәрлекләр өчен – 0,5-1,0 сәг артмаска тиеш |
| 2.13 | Янгын урынына бару юлына китә торган вакытны исәпләп чыгарганда юлларның, сукмакларның яисә җәяүлеләр узып йөрерлек урыннарның сикәлтәлеген һәм җир өсте рельефын исәпкә алу өчен аларны озынайту коэффициентлары: | |
| | 1 типлы урман хуҗалыгы юллары өчен<br>3 типлы урман хуҗалыгы (янгынга каршы) юллары өчен | тигез җирлектә – 1,1;<br>калкулыклы – 1,25<br>тигез җирлектә – 1,15;<br>калкулыклы – 1,65 |
| 2.14 | Янгын сүндерүче хезмәткәрнең хәрәкәт тизлеге | Гадәттә 1-3 км/сәг тәшкил итә (автоюлдан корал белән янгын урынына килгәндә) |
| 2.15 | Җир өсте патруль маршрутларын планлаштыру нормативлары: | |
| 2.15.1 | Урнаштыру урыннары | Агач-куаклар аз булган урыннарда (15% һәм аннан да түбән) һәм территория буйлап вак урман кишәрлекләре урнашканда. Кыр саклаучы урман утыртмаларын, чокырларда һәм балкаларда үсә торган агачларны, яшел зона, урман паркы урманнарында үсә торган утыртмаларны саклаганда. |

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | Стационар һәм авиапатруль күзәтү пунктларыннан өстәмә күзәтү өчен – агач әзерләү, төрле объектларны һәм трассаларны төзү урыннарында, ял зоналарында, елгаларның һәм күлләрнең ярлары буйлап, янгын куркынычы югары булган агачлар арасында |
| 2.15.2 | Патруль маршрутының озынлыгы | Транспорт төренә, юллар торышына һәм саклана торган кишәрлекне карап чыгу санына бәйле |
| 2.15.3 | Янгын куркынычы булган кишәрлекләрдә урман-янгын патруленең хәрәкәт тизлеге | |
| | мотоцикллар, машиналар һәм башка транспорт чаралары | Гомуми файдаланудагы шоссе юллары буйлап – 30 км/сәг артык, урман юллары буйлап – 15-20 км/сәг. Урмансыз киңлекләрдә юл хәрәкәте иминлеге кагыйдәләре нигезендә арттырылырга да мөмкин |
| 2.16 | Җирлектә урман янгыннары чыгуга күзәтчелек пунктларын урнаштыру нормативлары: | |
| 2.16.1 | Манараларның әйләнә-тирәлектән биеклегенә бәйле рәвештә максималь күзәтү радиусы (бик яхшы күренүчәнлек шартларында):<br>манаралар биеклеге, м<br>күзәтү радиусы, чм | 10 15 20 25 30 35 40<br>12 15 17 19 21 23 24 |
| 2.16.2 | Манараларны оптималь урнаштыру | Калку җирләрдә – бер-берсеннән 10-12 км. ерак түгел, ә тигез җирдә – 5-7 км. Янгын чыгу ихтималы мөмкин булган районда аның урынын 2-3 пункттан почмак үлчәү инструменты (буссоль һ.б.ш.) һәм бинокль ярдәмендә төгәл ачыклау исәбеннән. ПТУ-59 телевидение корылмасының күзәтү радиусы 8 чм кадәр (күзәтче югары күтәрелмичә дә). Видеоконтроль җайланмасын һәм идарә пультын мачтадан 1 чм кадәр ераклыктагы теләсә нинди ябык бинага урнаштыралар, ә кабельнең озынлыгы 1 чм алып 3 чм кадәр булганда линия көчәйткече тоташтырырга кирәк. |
| 2.16.3 | Манараларны (чаралар җитешмәгәндә) рөхсәт ителгәнчә урнаштыру | 35 м биеклеге типлаштырылган металл вышка начар һава шартларында 10-12 чм, ә яхшы шартларда 20 чм кадәр араны күрергә мөмкинлек бирә. Шуңа күрә аларны минималь күренүчәнлектән икеләтә күбрәк ераклыкта (20-24 чм) урнаштыралар. ПТУ-59 телевидение корылмасының күзәтү радиусы - 10-15 чм кадәр. |
| 2.16.4 | Күзәтү манараларының хезмәт итү вакыты:<br>агач – 10 ел<br>металл – 30 ел | Манараларның хакы бертигез диярлек |
| 2.17 | Янгын-химия станцияләрен (алга таба – ЯХС) планлаштыру һәм урнаштыру нормативлары: | |
| 2.17.1 | ЯХС оештыруның максатка ярашлылык | Беренче чиратта, беренче өч класслы янгын куркынычына караган кыйммәтле урманнары, һәр 1000 га урман фондына |

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | күрсәткечләре (урманнарны янгыннан саклауны оештыру планнарына ярашлы рәвештә) | гомуми озынлыгы 6 чм ким булмаган транспорт юллары һәм су юллары булган урман хуҗалыкларында |
| 2.17.2 | Һәр ЯХС тирәсендә беркетелә торган урманнар территориясе радиусы:<br>юл челтәрләре яхшы торышта булган очракта<br>канәгатьләндерерлек булганда<br>сыйфатлы булмаганда | Иң күбе 40 чм<br>Иң күбе 30 чм<br>Иң күбе 20 чм |
| 2.17.3 | ЯХС бинасын урнаштыру өчен урын сайлау | Урманның янгын куркыныч белән янаган һәм янучан кишәрлекләренә мөмкин кадәр якында, беркетелгән территория үзәгендә, урман хуҗалыгы (урманчылык) конторасына, цехларга, түбәнге агач саклыкханәләренә, күп кешеләр эшли торган бүтән хуҗалыкларга, төп транспорт юлларына, сулыкларга якын җирдә. Берничә варианттан бу шартлардагы иң мөһим таләпләрнең күпчелегенә туры килә торганын сайлыйлар. Техника һәм урман янгыны бригадалары гадәттә бер пунктта туплана, ләкин кирәк булганда ЯХС тармаклары ике я күбрәк пунктта да урнашырга мөмкин (зур булмаган ерак, янгын куркынычлы урманчылыкларда яисә аерым ЯХС оештыру максатка ярашсыз булган аймакларда). |
| **3.** | **Урманнарны янгыннардан авиация патруле белән саклау эшләрен планлаштыру нормативлары** | |
| 3.1 | Төбәктә маршрут линияләрен урнаштыру: авиапатрульлек иткәндә | Бер-берсенә һәм күзәтелә торган кишәрлекнең озын ягына параллель итеп<br>Бер-берсеннән иң күбе 60 чм, ә маршруттан күзәтү кишәрлеге чигеннән – иң күбе 30 чм |
| 3.2 | Очыш биеклеге:<br>урманнарны янгыннардан авиация ярдәмендә саклаганда | Оптималь биеклек – 600 м. Һәр аерым очракта куелган бурычның үзенчәлекләре, җирле очыш шартлары, аппаратның техник характеристикасы, аның герметик кабинасы булу-булмау белән билгеләнә (АН-24 самолетыныкы – 7000 м кадәр). |
| | авиация белән патрульлек итүне урманнарның санитар торышына гомуми күзәтчелек белән бергә алып барганда | Урманның аерым кишәрлекләрен җентекләп күзәтү өчен самолетта очыш 200 м кадәр, вертолетта очыш 100 м кадәр түбәнәя (урындагы рельефны һәм анда биек элементлар булуны исәпкә алып). |
| 3.3 | Авиация белән партульләгәндә янгын урынын билгеләү төгәллеген бәяләү: | |

| №<br>п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | бик яхшы<br>яхшы<br>канәгатьләндерерлек<br>канәгатьләндерерлек түгел | Хатасыз<br>0.5 чм кадәр хилафлык белән<br>0,5 чм башлап 1.0 чм кадәр хилафлык белән<br>1 чм артык хилафлык белән |
| 3.4 | Биек урыннан янгын мәйданын билгеләү төгәллеге | Иң күбе 30% дәрәҗәсендә хилафлык җибәрү рөхсәт ителә |
| 3.5 | Парашютчы-янгын сүндерүчеләрне төшерү урыннарына һәм андагы шартларга таләпләр: | |
| | очыш биеклеге<br><br>җирдән җил тизлеге<br>җиргә утыру өчен ачык мәйданнарның зурлыгы<br><br>сикерүне тыю | Кимендә 800 м (парашют тибына карап)<br>Иң күбе 8 м/с<br>Кимендә 75x75 (урман яланнары, кипкән сазлыклар, басулар һ.б., ә алар булмаганда – биеклеге 20 м кадәр булган куаклар һәм агачлар)<br>Кисентеләргә, урман янган җирләргә, җил еккан агачлыкларга, шулай ук югары вольтлы линияләр тирәсенә |
| 3.6 | Авиация белән сакламалы урманнар территориясендә урман хуҗалыклары башкара торган эш урыннары һәм кишәрлекләр планлаштыру нормативлары: | |
| 3.6.1 | Авиация хәбәрләрен кабул итү пунктлары оештыру:<br>урнаштыру урыны<br><br><br><br>аларны патруль самолетлары (вертолетлары) өчен тану билгеләре белән җиһазлау | Урманчылык, ЯХС кишәрлек урманчылыклары, авыл хакимиятләре, колхоз, совхоз конторлары янында, телефоны һәм радиоэлемтәсе булган торак пунктларда.<br><br>Кизү тору оештырылган өй түбәләренең ике кыегында да ак майлы буяу яисә бур белән, гарәп цифрлары белән пунктның номеры языла. Цифрларны яңа ышкылган тактадан да ясарга мөмкин.<br>Саннарның зурлыгы: биеклеге буенча – 2.5-3.0 м, киңлеге буенча – 0.75 м |
| 3.6.2 | Патруль самолетларына һәм вертолетларына яхшы ориентлашу шартлары булдыру максатыннан өстәмә-ясалма ориентирлар кору: | |
| | ориентирларның типлары һәм урыннары<br><br><br><br><br><br>аларны танып алу тамгасы белән җиһазлау | Урман территориясендә булган корылмалар (кордоннар, аучы өйләре, бараклар һ.б.ш.). Алар булмаса, ачык урыннарда (кимендә 100x100 м) җирдә каезланган киртәләрдән (каезланмаган каен киртәләрдән) куышлар, ике кыеклы түбәләр корыла яисә 7 м кадәр биеклектәге нык утыртылган колгаларга ак флаглар эленә.<br>Корылма яисә куыш түбәсенең ике яки кыегына да, бөтен озынлыгына, квартал (аймак) номеры яки патруль картасының шартлы шакмагы төшерелә. Билгенең биеклеге – кимендә 3 м, иңе – кимендә 0.75 м. |
| 3.6.3. | Вертолетлар эшли торган төбәкләрдә төшеп утыру мәйданчыклары сайлау һәм җиһазлау: | |

| № п/п | Күрсәткечләр | Нормативлар (оптималь күрсәткечләр) | |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | |
| | Билгеләнеше<br><br>урнаштыру урыны | Ягулык салу, янгын сүндерү көчләрен һәм чараларын алу һәм төшерү, хәбәрләр кабул итү пунктлары һ.б.<br>Янгыннар еш кабына торган яисә янгын куркынычы югары булган урман масивларында | |
| | минималь зурлыклар вертолетларны утырту һәм һавага күтәртү мәйданнарының минималь зурлыклары (килүләрне исәпкә алуның эш мәйданы) | Вертолет типлары | Тигезлекле җирлек, м |
| | | МИ - 6<br>МИ - 8<br>МИ - 4<br>МИ - 2<br>МИ - 1А | 50 х 50<br>30 х 30<br>30 х 30<br>16 х 16<br>16 х 16 |
| | күтәрелү һәм төшү (һавадан килү) юнәлешендәге киртәләр биеклеге 0,5 м югары (МИ-2, МИ-1А, Ка-26 өчен) һәм 1 м югары киртәләр урнаштыру (МИ-6, МИ - 8, МҺӘМ - 4 өчен) | Барлык комачаулар мәйданчык чигеннән үз биеклегеннән икеләтә ераграк торырга тиеш<br><br>Мәйданчык чигеннән кимендә 10 м ераклыкта | |

Урманнардан файдаланганда барлыкка килгән очракта урман янгыннарын кисәтү һәм аларны тиз арада локальләштерү максатында урманнардан файдалану урыннарында янгын сүндерү буенча кирәкле күләмдә чараларның булуы күздә тотыла.

РФ ТРЭМның «Урманда янгыннарны кисәтү һәм сүндерү чаралары төрләрен, әлеге чаралар белән урманнардан файдаланучы затларның тәэмин ителү нормативларын, урманнардан файдаланганда урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чаралары булу нормаларын раслау турында» 2014 ел, 28 март, № 161 боерыгы нигезендә агач материалы әзерләүне гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затларның янгын сүндерү чаралары тупланган пунктларда тиешле янгын техникасы, кирәк-яраклар һәм инвентарь булырга тиеш.

ЯХС-3 булганда урманчылык территориясендә янгын техникасына, җайланмасына, кирәк-яракларга һәм инвентарьларга ихтыяҗ булуы турында белешмәләр 14.2.5 таблицада күрсәтелде

14.2.5 таблица.

Урман хуҗалыгын алып баручы урман фондын биләүчеләрне урман янгыннарын сүндерү җайланмалары һәм чаралары белән тәэмин итү нормалары

| Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларының аталышы | Үлч. бер. | ЯХС-3 булган очракта чаралар күләме | Искәрмә |
|---|---|---|---|

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| Төп җиһазланыш: | | | |
| 1. Төп урман-янгын агрегат вариантлары:<br><br>а) урман янгын автоцистернасы, урман-патруль автомобиле, «Которна» тибындагы урман-янгын модуле<br>яки<br>б) урман-янгын тракторы, 30 кН классына караган урман-янгын агрегаты<br>яки<br>в) 6 т кадәр йөк күтәрә торган урман-янгын техникасы<br>яки<br>г) 7,5 т кадәр су сыйдыра торган янгынга каршы җайланмасы булган урман-янгын катеры | данә | 4<br><br>2<br><br>2<br><br>2 | Юл челтәрләре үсеш алган районнарда янгын чыккан урынны янгын сүндерү чаралары һәм хезмәткәрләр белән тәэмин итү<br><br>Юл челтәрләре аз үсеш алган районнарда кебек үк<br><br>Сазлыклар яки марь мәйданнары күп булган районнардагы кебек үк<br><br>Су юллары үсеш алган районнарда урман-янгын агрегаты урынына |
| 2. 6 тоннага кадәр йөк күтәрә торган, авыр урыннардан үтү мөмкинлеге зур булган бортлы автомобиль | данә | 3 | Юл челтәрләре үсеш алган районнарда хезмәткәрләр һәм янгын сүндерү чаралары белән тәэмин итү |
| 3. 1 тоннага кадәр йөк күтәрә торган, авыр урыннардан үтү мөмкинлеге зур булган бортлы автомобиль | данә | 1 | Янгыннар сүндергәндә патрульлек итү һәм хезмәтләр күрсәтү |
| 4. 22-32 ат көче булган, коляскалы авыр мотоцикл | данә | 2 | Шул ук |
| 5. 400-500 кг йөк күтәрә торган элмә моторлы, 4-5 кешелек моторлы көймә | данә | 1 | Шулай ук. Су юллары булганда бортлы автомобиль урынына |
| 6. 800-1600 л/мин җитештерелешле насос станциясе. | данә | 1 | торфлы туфраклар булганда торф янгыннарын сүндерү өчен |
| 7. Авторемонт остаханәсе | данә | 1 | |
| 8. Күчмә мотопомпа яки минутына 600-800 л җитештерелешле элеп куела торган тешле тәгәрмәчле насос | данә | 3-5 | Янгыннарны сыекчалар белән сүндерү өчен |
| 9. 60-120 л/мин җитештерелешле аз габаритлы күчмә мотопомпа | данә | 4-5 | Шул ук |
| 10. Су өчен 100-1500 литрлы алынмалы-куелмалы цистерна яки резин савыт (резервуар) | данә | 3-5 | Суны янгыннарга китерү өчен |
| 11. 90-175 а.к. бульдозер | данә | 2 | Минполосалар ясау һәм янгыннарны локальләштерү өчен |
| 12. 1.5-6 т тарту көче булган | да | 2-3 | Туфрак эшкәртә торган кораллар |

| Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларының аталышы | Үлч. бер. | ЯХС-3 булган очракта чаралар күләме | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| тәгәрмәчле яки чылбырлы трактор (9-30 кН) | нә | | белән эшләү өчен, торфланган туфракларда саз модификацияле трактор кулланыла |
| 13. Урман өчен трактор сабаны яки полосасалгыч, грунтомет, бульдозер күгәне һәм транспорт чаралары белән башка төрле янгын сүндерү кораллары | да нә | 3-5 | Туфрак шартларына карап, минполосалар һәм чокырлар салу өчен |
| 14. Тарттыргычы булган трейлер, 10-30 т авырлыктагы техниканы транспортлау агрегаты | да нә | 1 | Каты түшәмәле юллар булганда |
| 15. Радиостанция (урман хуҗалыгы, урманчылык радио челтәрендә кулланыла торган ешлык диапазонына карап), данә:<br>а) стационар (ЯХС бинасында яки урман хуҗалыгы, урманчылык конторасында)<br>б) йөртелә торган (барлык урман-янгын һәм патруль күчерү чараларында)<br>в) күтәреп йөртә торган | да нә | 1<br><br>10<br><br>16 | Урман хуҗалыгы, урманчылык, бригадалар, күчмә объектлар белән элемтәгә керү өчен<br><br>Күчмә техникалар белән үзара, урман хуҗалыгы, урманчылык конторасы, күзәтчелек пунктлары, вышкалар белән элемтәгә керү өчен<br><br>Бригадирга эшчеләр, машина йөртүчеләр белән һәм үзара аралашу өчен |
| 16. Хәрәкәт итә яки күчереп йөртелә торган тавыш-хәбәр җайланмасы | да нә | 3 | Урман-янгын бригадасын тәэмин итү, янгыннарны сүндергәндә команда бирү өчен |
| 17. Ут кабыза торган аппарат | да нә | 6-12 | Кисенте калдыкларын яндыру өчен |
| 18. 1,8-3,0 л/мин җитештерелешле, ранецлы урман янгынын сүндергеч, | да нә | 30-60 | Янгыннар сүндерү һәм яндырганда терәк полосалар ясау өчен |
| 19. 40-100 см диаметрындагы агачларны аудару өчен бензин-мотор пычкысы | да нә | 4-7 | Полосалар һәм чокырлар трассаларында агачларны аудару һәм эшкәртү өчен |
| Технологик җиһазланыш: | | | |
| 1. Этемле янгын җиңсәләре, м: | да | 10000 | Янгыннарга су бирү өчен һәм |

| Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларының аталышы | Үлч. бер. | ЯХС-3 булган очракта чаралар күләме | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| – 26 һәм 51 диаметрлы яки<br>– җиңеләйтелгән (этеме 0,5 мПа кадәр),<br>– нормаль (этеме 1,2 мПа кадәр),<br>– көчәйтелгән (этеме 1,5 мПа кадәр) | нә | | яраксызланган җиңсәләрне алмаштыру өчен резерв |
| 2. Янгын көпшәсе, данә. | дана | 10 | Күчереп йөртелә торган янгын мотопомпалары комплекты |
| 3. Торфлы көпшә, данә. | дана | 4 | Торф янгыннарын сүндерү өчен |
| 4. Ялгый торган этемле башчык (җиңсәнеке); күчереп йөртелә торган этемле башчык; тармакланган өчйөрешле; тармакланган икейөрешле | дана | 100 | Этемле янгын җиңсәләрен үзара һәм янгын сүндерү җайланмасы белән тоташтыру; төрле диаметрлы җиңсәләрне үзара ялгау; магистраль җиңсәләрдән суны бүлү |
| 5. Ут сүндерә торган сыекчаны саклау өчен савыты булган болгаткыч агрегат | дана | 2 | Измәләр әзерләү өчен |
| 6. Җиңсәләрне бер урыннан икенче урынга күчерү җайланмасы | дана | 4 | |
| 7. Универсаль һәм корсетлы кыскыч | дана | 70 | Җиңсәләрдән су тамган урыннарны бетерү өчен |
| 8. Янгын көрәге | дана | 200 | Ялкынны җир белән күмү |
| 9. «Пуласки» тибындагы янгын сүндерү балта-тәпкесе | дана | 40 | Минполосалар салу, түшәмәне салдыру һ.б. |
| 10. Янгын сүндерү тырмалары (металл) | дана | 40 | Минполосалар салу |
| 11. Янгын сүндерү чиләге (10 литрлы) | дана | 40 | Янгынның калган өлешен сүндереп бетерү |
| 12. Аркылы пычкы | дана | 20 | Трассаларны чистарту |
| 13. 10-20 литрлы канистра | дана | 20-40 | Янгын сүндергеч измәләрне ташу өчен һәм мотопомпаларга ЯММ |
| 14. Балта | дана | 40 | Трассаларны чистарту |
| 15. Һава торышының янгын куркынычын үлчәү өчен җайланма (УСП-1) яки явым-төшемне үлчәгеч, психромер һ.б. | дана | 2 | |
| 16. Алынмалы-куелмалы | Бригадалар | | Янгын сүндерү инвентарын ташу |

| Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларының аталышы | Үлч. бер. | ЯХС-3 булган очракта чаралар күләме | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| контейнер (стандарт түгел) | санына карап | | өчен |
| Оештыру-техник җиһазланыш: | | | |
| 1. «Авиалесохрана» өчен эшләнгән аптечка җыелмасы | дана | 6-10 | Янгында медицина ярдәме күрсәтү |
| 2. Хосусый яра бәйләү пакеты | дана | Команда әгъзалары санына карап | Шул ук |
| 3. 20 л кадәр сыешлы канистра яки бидон | дана | 12 | Эчә торган суга |
| 4. Махсус кием һәм аяк киеме | дана | Команда әгъзалары санына карап | 4-7 п. нигезендә мөлкәт урман составын җәрәхәт алулардан һәм пешүләрдән яклау өчен ТБ таләпләренә туры килергә тиеш |
| 5. Респиратор | дана | Шул ук | |
| 6. Саклагыч күзлекләр | дана | Шул ук | |
| 7. Яклагыч каска | дана | Шул ук | |
| 8. Йоклый торган капчык | дана | Команда әгъзалары санына карап | |
| 9. 8-12 кешелек палаткалар | дана | Шул ук | |
| 10. Кружка | дана | Шул ук | Эчә торган суга |
| 11. Инә | дана | 20 | Җиңсәләрне ремонтлау |
| 12. Химик карандаш яисә фломастер | дана | 20 | Җиңсәләрнең зыян күргән урыннарын тамгалау өчен |
| 13. Чәчле яки капрон щетка | дана | 10 | Җиңсәләрне юдыру өчен |
| 14. Келәй (резин һ.б.) | дана | 10 | Җиңсәләрне ремонтлау өчен |
| 15. Бинокль (кыр) | дана | 5 | Җирлекне карау өчен |
| 16. Андрианов компасы | дана | 8 | Җирлектә юнәлеш алу өчен |
| Ярдәмче материаллар: | | | |

| Урман янгыннарын кисәтү һәм сүндерү чараларының аталышы | Үлч. бер. | ЯХС-3 булган очракта чаралар күләме | Искәрмә |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. Янгын сүндерү составы | т | 2,5 | Суның янгын сүндерү үзлекләрен көчәйтү өчен |
| 2. Җебеткеч, кг (ДБ, сульфанол, НП-1 һәм башка юа торган чаралар) | да нә | 200 | Шул ук |
| 3. Ягулык-майлау материалы (бензин, дизель ягулыгы, майлар) | Сарыфларга, техника санына, янгыннар күләменә һәм аларны сүндерү вакытына карап ясалган исәпләмә | | |

Һәр транспорт чарасына өстәмә күздә тотыла:
балта – 1 данә;
гади лом – 1 данә;
чиләк (яисә 10-15 литрлы су савыты) – 1 данә;
янгын сүндергеч – 1 данә.
Эшләнүче һәр диләнкегә, шулай ук өске саклыкханә өчен өстәмә күздә тотыла:
штыклы көрәк – 3 данә;
чиләк (яисә 10-15 литрлы су савыты) – 2 данә;
ранецлы урманда янгын сүндергеч – 3 данә.

### 2.17.2. Урманнарны яклауга карата таләпләр (санитар-савыктыру чараларының, урманнарны яклау буенча профилактика чараларының, зарарлы организмнарның чыганакларын ликвидацияләү чараларының, шулай ук вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән башка чараларның нормативлары һәм параметрлары)

Гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары керүне чикләгәндә, шулай ук урманнарда санитар куркынычсызлык тәэмин итү максатларында билгеле бер эшчәнлек төрләрен уздырганда түбәндәге чаралар гамәлгә ашырыла:

эшләр уздырылган районда урманнардан файдаланучы затларга чаралар уздыруга бәйле рәвештә урманнарда булуны вакытлыча тыю турында әлеге эшләр башланырга 10 көн калгач кулга тапшыру турында белдереп хәбәр ителә;

массакүләм мәгълүмат чаралары аша (газеталар, радио, телевидение, листовкалар) урманнарда булуны вакытлыча чикләү турында җирле халыкка җиткерелә, чараларны уздыру максатлары, урман корткычларыннан якланырга тиешле урман кишәрлекләрен препаратлар белән эшкәртү (алга таба – эшкәртү) чорлары, җәмәгатьчелек иминлеге буенча чаралар һәм җирле халык, төрле предприятиеләр һәм оешмалар, үзләренең милекчелек формаларына бәйсез рәвештә, үтәргә тиешле зарури карантин кагыйдәләре турында мәгълүмат җиткерелә;

чаралар уздырылган вакыт өчен дәүләт хакимияте органнарында, җирле үзидарә органнарында җәмәгатьчелек белән элемтәгә керү һәм гражданнарның сорауларына җавап бирү өчен «кайнар линия» телефоны оештырыла;

эшкәртелә торган кишәрлек чикләреннән (җир өсте эшкәртелгәндә) 300 метр ераклыкта һәм (авиация ярдәмендә эшкәрткәндә) 500 метр ераклыкта эшләр уздыру урыннарында бердәй кисәтү аншлаглары урнаштырыла. 1х1,5м зурлыгындагы аншлагларга кисәтүле язулар теркәлә: «Сак булыгыз! Пестицидлар кулланылды. (Дата) башлап (дата) кадәр кешеләрнең йөрүе, гөмбә җыю, терлек көтү, җимешләр, җиләкләр, дару үләннәре җыю тыела»;

эшкәртелергә тиешле урман кишәрлекләре уза торган, аркылы узу һәм узып китү, шулай ук терлек куу өчен юллар ябыла;

эчә торган су чыганакларын препаратлар эләгүдән саклау чаралары күрелә;

эшкәртелергә тиешле урман кишәрлекләрендә урманнардан файдалануның барлык төрләре туктатыла.

Урманнарны зарарлы организмнардан яклау РФ Урман кодексының 60.1-60.10 статьялары һәм «Үсемлекләр карантины турында» 2014 ел, 21 июль, № 206-ФЗ федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 ел, 20 май, № 607 карары белән расланган Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре (алга таба – Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарны яклау зарарлы организмнарны (үсемлекләрне, хайваннарны, билгеле бер шартларда урманнарга һәм урман ресурсларына зарар китерерлек авыру кузгатучы организмнарны) ачыклауга һәм алар таралуны булдырмауга, карантин объектларга кертелгән зарарлы организмнар чыганаклары барлыкка килгән очракта, аларны локальләштерүгә һәм бетерүгә юнәлдерелә.

Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре урманнарны зарарлы организмнардан, шулай ук зарарлы йогынтыдан яклауның бердәм тәртибен һәм шартларын, шулай ук урманнарда санитар иминлек тәэмин итүгә юнәлдерелгән урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләрен билгели.

Урманнарда санитар иминлекне тәэмин итү максатларында түбәндәгеләр гамәлгә ашырыла:

1) урман-яклау районнарына бүленеш;
2) дәүләт урман-патологик мониторинг;
3) урман патологиясенә тикшеренүләр уздыру;
4) зарарлы организмнар таралуны кисәтү;
5) урманнарда янгын куркынычсызлыгы буенча бүтән чаралар.

Урманнарда 3-5 пунктларда күрсәтелгән санитар куркынычсызлык чаралары Татарстан Республикасы урман планы, урманчылыкның урман хуҗалыгы регламенты һәм урманнарны үзләштерү проекты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләрен Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели.

Урман патологиясе буенча тикшеренүләр урманнарда дәүләт урман-патологик мониторинг белешмәләрен, шулай ук урманнарның санитар һәм урман-патологик торышы турында башка мәгълүматларны исәпкә алып уздырыла.

Урман патологиясе буенча тикшеренүләр җир өсте һәм (яисә) дистанцион методларны кулланып, – урманнарның санитар һәм урман-патологик торышына зарури төгәл бәяне тәэмин итүче визуаль һәм кораллы ысуллар белән уздырыла.

Урман патологиясе буенча тикшеренүләрне уздыру тәртибе, урман патологиясе буенча тикшеренү актының формасы вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнә.

Зарарлы организмнар таралуны кисәтү түбәндәгеләрнең уздырылуын үз эченә ала:

1) урманнарны яклау буенча профилактика чаралары;

2) санитар-савыктыру чаралары, шул исәптән һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү;

3) вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән башка чаралар.

Даими (вакыты чикләнмичә) файдалануга, арендага тапшырылган урман кишәрлекләрендә зарарлы организмнар таралуны кисәтү буенча күрсәтелгән чаралар урманнарны үзләштерү проекты нигезендә урманнардан файдаланучы затлар тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Санитар-савыктыру чараларын гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы урман планына, урманчылыкның урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертелә.

60.7 статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру рөхсәт ителми:

1) әгәр мондый чаралар урман патологиясе буенча тикшерүнең тиешле актында каралмаган булса;

2) вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы урман патологиясе буенча тикшерүнең тиешле актын гамәлдән чыгару турында яки аңа үзгәрешләр кертү турында күрсәтмә җибәрсә;

3) әлеге Кодексның 60.6 статьясының 3 өлеше нигезендә урман патологиясе буенча тикшерү акты дәүләт хакимияте органының яки җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылганнан соң егерме көн эчендә.

Урманнарда зарарлы организмнарның чыганакларын юк итү түбәндәге чараларны үз эченә ала:

1) зарарлы организмнарның чыганакларын тикшерү;

2) зарарлы орзанизмнарны юкка чыгару яисә күләмен киметү, шул исәптән химия препаратлары белән;

3) зарарлы организмнар белән зарарланган урман утыртмаларының токым һәм яшь составларын җайга салу максатларында урман утыртмаларын кисү.

РФ УК 60.8 статьясының 3 өл. буенча зарарлы организмнарның чыганакларын бетергәндә чаралар уздыру барышында әзерләнгән агач материалы күләме файдалану өчен билгеләнгән диләнке күләменә кертелми.

Зарарлы организмнарның чыганакларын юкка чыгару буенча чараларны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча ТР урман планына, урманчылыкның, урман паркының урман хуҗалыгы регламентына үзгәрешләр кертелә.

Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары үзләренең РФ Урман кодексының 81-84 статьяларында билгеләнгән вәкаләтләре чигендә гражданнарның урманнарда булуын һәм аларга транспорт чаралары белән үтеп керүне, урманнарда билгеле бер эш төрләрен уздыруны чиклиләр.

РФ Урман кодексының 60.6 ст. 4 өлешенә, РФ ТРЭМның «Урман патологиясе буенча тикшеренүләр уздыру тәртибен һәм урман патологиясе буенча тикшеренү акты формасын раслау турында» 2016 ел, 16 сентябрь, № 480 боерыгына ярашлы рәвештә урман патологиясе буенча тикшеренү (алга таба – УПТ) урманнарда дәүләт урман-патологик мониторинг белешмәләрен, шулай ук урманнарның санитар һәм урман-патологик торышы турында башка мәгълүматларны исәпкә алып уздырыла.

УПТ уздыру дәүләт хакимияте органнары яисә җирле үзидарә органнары тарафыннан РФ Урман кодексының 81-84 статьяларында билгеләнгән үзләренең вәкаләтләре чикләрендә яисә гражданнар, шул исәптән урманнардан файдаланучы шәхси эшкуарлар һәм юридик затлар тарафыннан тәэмин ителә.

Урманнарда санитар куркынычсызлык кагыйдәләре нигезендә урманнардан файдалануны, урманнарны саклауны, яклауны һәм яңадан җитештерүне гамәлгә ашыручы гражданнар һәм юридик затлар корткычлар, авырулар, тискәре торыш, байтак дәрәҗәдә яисә массакүләм зарарлану яисә зыян күрү билгеләрен ачыклаган очракта мондый хәл ачыкланган датадан соң бишкөнлек чорда бу хакта вәкаләтле органнарга хәбәр итәргә бурычлы.

Мәгълүмат язмача яисә электрон рәвештә, ачыкланган зарарлану урынын (зыян күрү билгеләрен тасвирлап), зарар салыну сәбәбен, агачларның зарарланган токымын, зарарланган урынның якынча мәйданын һәм гариза бирүченең элемтә белешмәләрен: фамилиясен, исемен, ата исемен (булган очракта) һәм телефонын күрсәтеп җибәрелә.

Мәгълүмат вәкаләтле органнар тарафыннан аны алган вакыттан 30 көнлек чорда тикшерелә.

Урман патологиясе буенча тикшеренүләр җир өсте һәм (яисә) дистанцион, урманнарның санитар һәм урман-патологик торышына зарури төгәл бәяне тәэмин итүче визуаль һәм коралды ысуллар белән уздырыла.

УПТ урман кишәрлекләренең хәзерге санитар (төрле торыштагы категория агачларының санына карап билгеләнә торган сыйфатлама) һәм урман-патологик торышы (зарарлы организмнарның санына һәм алар агачларга салган зыян дәрәҗәсенә карап билгеләнә торган сыйфатлама) турында мәгълүмат алу, шулай ук зарарлы организмнар таралуын кисәтү буенча чараларны нигезләү һәм билгеләү максатларында уздырыла.

УПТ урман утыртмаларында вегетация чорында яфрак (ылыс) чыккан вакыттан алып сезонлы дехромация (начар табигый һәм антопоген факторлар йогынтысы нәтиҗәсендә ылысларның яисә яфракларның төсе үзгәрә башлау) башланган вакытка кадәр уздырыла.

Составы буенча мәңге яшел чиста урман утыртмаларында, шулай ук җилдән зыян күргән (җил аударган, давыл еккан) һәм өске ягыннардан зарарланган урман утыртмаларында УПТ ел дәвамында уздырыла.

Татарстан Республикасы урман планында һәм урман хуҗалыгы регламентында УПТ күләмнәре күрсәтелми һәм ел саен билгеләнә, шул исәптән дәүләт урман-патологиясе мониторингы белешмәләрен һәм урманнарның санитар һәм урман-патологик торышы турындагы башка мәгълүматларны исәпкә алып.

Визуаль ысул белән УПТ урманнарның санитар һәм урман-патологик торышы турында дәүләт урман-патологик мониторинг, урманнарны яңадан җитештерүгә дәүләти мониторинг, урманнарда янгын куркынычы һәм урман янгыннары буенча мониторинг нәтиҗәсендә алынган мәгълүматлар, шулай ук вәкаләтле органнардан, гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан һәм юридик затлардан алынган мәгълүматлар нигезендә планлаштырыла.

Кораллы ысул белән УПТ визуаль ысул белән яисә башка чыганаклардан алынган мәгълүматлар буенча УПТ нәтиҗәсендә санитар-савыктыру чаралары (алга таба – ССЧ) уздыру таләп ителгән урман кишәрлекләрендә планлаштырыла.

Визуаль ысул белән УПТ җир өсте һәм (яисә) дистанцион методларны кулланып гамәлгә ашырыла.

Кораллы ысул белән УПТ бары тик җир өсте методыннан файдаланып кына уздырыла.

УПТ барышында түбәндәгеләр башкарыла:

урман утыртмаларына зыян салыну (яисә аларның һәлак булу) сәбәпләре билгеләнә, шулай ук аварияле агачлар ачыклана;

зарарланган урман кишәрлекләренең урнашкан урыны һәм чикләре билгеләнә;

урман кишәрлекләренең агымдагы санитар һәм урман-патологик торышы билгеләнә;

зарарлы организмнар таралуын кисәтү буенча чаралар, шул исәптән урманнарны яклау буенча профилактика чаралары, шулай ук иң беренче чиратта рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә, кыйммәтле урманнарда агитация чаралары (алга таба – чаралар) билгеләү.

Торышы буенча бердәй булган бүлемтекләрнең мәйданнары таксация тасвирламасында күрсәтелгән тиешле бүлемтекләрнең мәйданнарын кушу юлы белән билгеләнә, ә таксация тасвирламалары булмаган очракта, сурәтләнә торган урман кишәрлекләренең чик координаталарына нигезләнеп исәпләп чыгарыла.

Бүлемтекнең санитар һәм урман-патологик торышы бертөрле булмаганда, билгеләнгән чаралар өчен бертөрле сыйфатламаларга ия булган өлеше (урман-патологик бүлемтеге) тасвирлана. Урман-патологик бүлемтекнең көчле урман-патология куркынычы булган зонадагы минималь мәйданы – 0,1 гектар; уртача урман-патология куркынычы булган зонада – 0,5 гектар; өлешчә урман-патология куркынычы булган зонада – 1 гектар.

УПТ гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча РФ ТРЭМның «Урман патологиясе буенча тикшерүләр уздыру тәртибен һәм урман патологиясе буенча тикшерү актының формасын раслау турында» 2016 ел, 16 сентябрь, № 480 боерыгына 2 нче кушымтада китерелгән формада урман патологиясе буенча тикшерү акты төзелә.

Урман патологиясе тикшерү уздырылганда тикшерелә торган урман-патологик бүлемтек буенча, зарурлык булганда урман-патологик бүлемтеге буенча таксация сыйфатламасы билгеләнә, агачларның зәгыйфьләнү һәм һәлак булу сәбәпләре, кору холкына, торыш категорияләренә яки ашалу дәрәҗәсенә карап агачларның утыртмалар запасындагы % бүленеше (зарарланган урман кишәрлегендә зарарлану билгеләре күренеп торган агачларның процентларда чагылдырылган өлеше яки агачларның аерым өлешләренә зыян салыну дәрәҗәсе), шулай ук агачларның зарарлану билгеләре һәм әлеге билгеләр күзәтелгән зыян салынган агачларның өлеше билгеләнә.

Урман кишәрлекләренең Урман патологиясе буенча тикшерүләр уздыру тәртибенең 7 пунктында күрсәтелгән, урман кишәрлекләренең санитар һәм (яки) урман-патологик торышы начарлануга китергән санитар һәм урман-патологик торышы сыйфатламалары үзгәргәндә, УПТ яңадан уздырыла.

Кораллы ысул белән УПТ урман кишәрлекләренең зыян салынган чикләрен, һәлак булган яисә зыян салынган урман утыртмаларының мәйданнарын төгәл билгеләү һәм чаралар уздыру өчен кирәкле документация әзерләү максатында уздырыла.

Кораллы ысул белән УПТ барышында җир өсте методын кулланып түбәндәгеләр башкарыла:

зарарланган һәм (яисә) һәлак булган урман утыртмалары булган урман кишәрлекләре ачыклана һәм аларның чикләре билгеләнә;

зыян салынган һәм һәлак булган урман кишәрлекләренең (агачларның) мәйданын һәм пространстволы урнашуын ачыклау;

агачлар санала;

урман утыртмаларына зыян салыну яки аларның һәлак булу сәбәпләрен, авария хәлендәге агачларның (агачның тоташ яисә бер өлеше авуга китерергә мөмкин булган һәм халыкка яисә дәүләт мөлкәтенә һәм гражданнарның һәм юридик затларның мөлкәтенә зыян салырга мөмкин булган (структур җитешсезлекләре булган (тишек-тошыклар, черегән урыннар, тамыры өзелгән урыннар, куркыныч рәвештә сыгылган) агачларны) структур җитешсезлекләрен ачыклау;

чаралар билгеләнә.

Урман утыртмалары арасында аварияле агачлар булганда, физик затларга, физик затларның һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләт милкенә зыян салыну яки линияле һәм башка төрле объектларның куркынычсыз эксплуатацияләнүенә куркыныч булу шартында урман патологиясе буенча тикшерү уздырыла. Аварияле агач келәймә белән тамгалана яки башкача маркалана.

Геодезик кораллар ярдәмендә зыян күргән һәм һәлак булган урман кишәрлекләре чикләрен билгеләр алдыннан рекогносцировка ысулы белән (урман кишәрлегенең кирәкле параметрларын беренчел бәяләү) чикләр билгеләнә.

Зарарланган һәм (яисә) һәлак булган урман утыртмалары булган урман кишәрлекләренең чикләрен билгеләү урман кварталы чикләрендә башкарыла, бу вакытта урман кишәрлеге чикләренә таксация сыйфатламалары, санитар һәм урман-патологик торышы буенча охшаш булган берничә урман-таксация бүлемтеге кертелергә мөмкин.

Зарарланган һәм һәлак булган урман кишәрлекләренең чикләре чатларын теркәү өчен үсүче агачлар файдаланырга мөмкин, аларга тиешле тамагалар ясала (юнып алына, лента асыла, буяла).

Навигация җайланмалары ярдәмендә зарарланган һәм (яисә) һәлак булган урман утыртмалары булган урман кишәрлекләре чикләре буйлап сыйфатлы нокталарның географик координаталары билгеләнә.

Агачларны яңадан санап чыгу тоташ (һәр агач буйлап) (булган барлык агачларны санау) санап чыгу методы, тасмалап санау (тар полосаларда (тасмаларда) агачларны тоташ санап чыгу), түгәрәкләп реласкопик мәйданчыклар белән (агачларны реласком ярдәмендә файдаланып карау мәйданында санап чыгу), даими радиуслы түгәрәк мәйданчыклар белән (даими яисә үзгәрүчән радиуслы түгәрәк рәвешендәге файдаланып карау мәйданчыкларында агачларны санау) гамәлгә ашырыла. 3 га кадәрге урман кишәрлекләрендә агачлар тоташ исәпләп чыгу юлы белән санала.

Агачлар санау турында мәгълүмат агачлар сану исемлегенә (урман патологиясе буенча тикшеренү актына 2 нче кушымта) кертелә.

Агачларны санау нәтиҗәләре буенча урман кишәрлегендәге агачның гомуми запасыннан процентларда һәм тулаем алганда урман кишәрлеге өчен торыш категорияләре буенча агач токымнарына бүлү эше башкарыла. Һәр агач категориясе һәм урман кишәрлеге өчен торышы буенча уртача исәпләнгән категориясе билгеләнә.

Җил аударган, давыл еккан, кар сындырган, янгын нәтиҗәсендә ауган агачлары 50% артык булган урман утыртмаларында УПТ визуаль ысул белән уздырыла, ә җитешмәгән мәгълүматлар таксация тасвирламаларыннан күчереп алына.

Кораллы ысул белән УПТ нәтиҗәләре буенча Урман патологиясе буенча тикшеренү актында торыш категорияләре буенча агачларны сайлап алу

проценты, чаралар билгеләү, урман утыртмасына салынган зыян дәрәҗәсе, урман утыртмаларының зарарлану һәм һәлак булу сәбәпләре күрсәтелә.

УПТ нәтиҗәләре буенча урман патологиясе буенча тикшерену акты (алга таба – акт) төзелә.

Актның беренче бите теләсә нинди ысул белән УПТ уздырылганда тутырыла.

УПТ ысулына карап, актның тиешле бүлекләре һәм кушымталары тутырыла.

Актның һәр тутырылган бүлеге һәм кушымтасы УПТ уздыру буенча эшләрне башкаручылар тарафыннан имзалана.

УПТ уздыру өчен билгеләнгән кишәрлекләр реестрына кисүгә билгеләнгән агачларны санау турында актка 2 нче кушымтада күрсәтелгән формада исемлекләре һәм актка 3 нче кушымтада күрсәтелгән формада диләнке абрисы кушып куела.

Имзаланганнан соң 2 эш көне эчендә акт раслау һәм бастырып чыгару өчен вәкаләтле органнарга җибәрелә.

Кушымталары белән бергә акт килгән көннән соң 10 эш көне эчендә вәкаләтле органнарны актны карыйлар һәм кисәтүләр булмаганда аны раслыйлар.

Раслаган көннән соң 3 эш көненнән соңга калмаган чорда, акт кушымталары белән берлектә дәүләт хакимияте органының яисә җирле үзидарә органының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла, федераль законнарда әйләнеше чикләнгән мәгълүматлардан торучы актлардан тыш.

Урман патологиясе буенча тикшерү нәтиҗәләре буенча урман патологиясе буенча тикшерү акты төзелә, ул дәүләт хакимияте органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан аларның әлеге Кодексның 81-84 статьялары нигезендә билгеләнгән вәкаләтләре чикләрендә раслана һәм расланган көненнән соң өч эш көне узганчы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте органының яисә җирле үзидарә органының рәсми сайтында урнаштырыла һәм, ведомствоара электрон хезмәттәшлек буенча бердәм системадан яки уртак файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән, шул исәптән «Интернет» челтәреннән файдаланып, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органына җибәрелә (РФ УК 60.6 ст. 3 өлеше).

Актны кушымталары белән берлектә рәсми сайтта урнаштыру чоры 2 ел тәшкил итә.

РФ УК 60.7 ст., РФ ТРЭМ «Зарарлы организмнар таралуын кисәтү чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында» 2016 ел, 12 сентябрь, № 470 боерыгына ярашлы рәвештә ССЧ урман утыртмаларының санитар торышын яхшырту, зарарлы организмнар таралу куркынычын киметү, урман утыртмалары өчен үзләренең максатчан вазыйфаларын тәэмин итү, шулай ук

тискәре факторларның (зыянлы организмнар, ялкын йогынтысы, һава шартлары, туфрак-климат факторлары һәм башкалар, урманнарның тотрыклылыгына яки максатчан вазыйфасына зыян сала торган биотик һәм абиотик факторлар) йогынтысыннан зыянны киметү максатларында уздырыла.

Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү, леквидлы булмаган агач материалыннан, шулай ук аварияле агачлардан җыештыру ССЧ була.

Аренда шартнамәсе, урман кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмичә) файдалану хокукы нигезендә урманнардан файдаланучы затлар тарафыннан уздырылырга планлаштырылучы ССЧ төрләре һәм күләмнәре турында белешмәләр урман декларациясендә чагылдырыла.

Файдалануга тапшырылмаган урман кишәрлекләрендә ССЧ күләмнәрен планлаштыру урманчылыкның (урман паркының) урман хуҗалыгы регламентында дәүләт урман-патологик мониторинг белешмәләре һәм УПТ мәгълүматлары нигезендә чагылдырыла.

ССЧ күләмнәрен ел кварталлары буенча бүлгәндә урман утыртмаларының зарарлану дәрәҗәсе һәм вакыты, агач токымының, зарарлы бөҗәкләрнең һәм чир барлыкка китерүчеләрнең биологиясе исәпкә алына. Йогышлы чир таралуны булдырмау өчен тоташ һәм сайланма кисүләрне барыннан элек кышкы чорда уздырырга кирәк.

ССЧ 4 һәм 5 бонитетлы урман утыртмаларында планлаштырылмый, әлеге агачлыкларда зарарлы организмнарның чыганаклары барлыкка килгән очраклардан тыш, шулай ук әлеге бонитет агачлары өстенлек иткән урман кишәрлекләрендә дә планлаштырылмый.

ССЧ теләсә нинди максатчан билгеләнештәге урманнарда һәм яклаучы урманнарның барлык категорияләрендә планлаштырыла, тыюлыклы кишәрлекләрдән тыш.

ССЧ өчен урман утыртмаларында (яфраклы һәм карагайлы) (утыртмалар составында 30% һәм аннан күбрәк) диләнкеләрне аерып чыгару вегетация чорында башкарыла (җилдән (җил аударган, давыл еккан – 5 «а», «б» һәм 6 «а», «б» торыш категориясенә караган агачлар) һәм өске янгыннардан зыян күргән урман кишәрлекләреннән тыш).

ССЧ уздыру өчен диләнкеләрнең күләме лимитланмый.

Һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларын кисү тоташ (һәлак булган һәм зарарланган утыртмалар өчен) һәм сайланма (зарарланган утыртмалар өчен) санитар кисүләр формасында уздырыла.

Яшь агачлыкларда эшкә яраклы агач өлгереп җиткәнче, орлыклык агачлар булган очракта, сайланма санитар кисүләр уздырыла һәм (яисә) леквидлы булмаган агач материалы җыеп алына.

Диләнкеләрне санитар тоташ һәм сайланма кисүләр өчен аерып чыгару РФ ТРЭМның 2016 ел, 13 сентябр, № 474 боерыгы белән расланган Агач материалы әзерләү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә короллы ысул белән уздырыла торган УПТ нәтиҗәләре буенча башкарыла.

Тоташ һәм сайланма санитар кисүләргә билгеләгәндә зарури тәртиптә 5-6 нчы категория торышындагы агачлар сайлап алына. Җил аударган, давыл еккан һәм кар сындырган агачлар 5-6 нчы категория торышына кертелә.

Түбәндәге очракларда торыш категорияләрендәге агачларны тоташ һәм сайланма санитар кисүгә билгеләү рөхсәт ителә;

торышы буенча 4 нче категориягә караган ылыслы токым агачлары;

| Ус, Т | | | + | + | | – | – | – | | | – | + | | – | – | – | + | | | | |
| Юкә | | | | | | – | | – | | | | | | – | – | – | + | | | | |
| Кара з. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + | |
| Тал аг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | + |
| 2. Туфракны минераллаштырып, табигый яңаруга булышу | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Н, Ю | – | + | + | – | – | + | + | – | – | | | | | | | | | | | | |
| Ч, П | | | | | | | | | – | + | – | – | + | – | | | | | | | |
| И, Кч, Өр Элмә | | | | | | | | | | | | | | | - | - | | | | | |
| Б | | – | + | – | | + | + | – | – | + | – | – | – | | – | – | | | | | |
| Ус, Т | | | + | – | | + | + | – | – | + | – | – | – | | – | – | | | | | |
| Юкә | | | | | | – | – | – | | | | | | – | – | - | | | | | |
| Кара з. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | – | |
| Тал аг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

| Төп үстен. итү-че токым | Урман типлары төркемнәре | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | С бел. | С бр. | С чер | С пр. | С сф д. | С тр.лп | С к.ч. | С слж. | С т.ос | е бр. | е ч. | е пр. | е сф.д. | Е слж. | е к. | Д слж. | Д пм. | Б ос | Б т.ос. | Ольш | Тал |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 | 21 | 22 |
| 3. Шытым саклау | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Н, Ю | – | + | + | – | – | + | + | – | – | | | | | | | | | | | | |
| Ч, П | | | | | | | | | – | + | – | – | + | – | | | | | | | |
| И, Кч, Өр Элмә | | | | | | | | | | | | | | | - | - | | | | | |
| Б | | – | + | – | | + | + | – | – | + | – | – | – | | – | – | | | | | |
| Ус, Т | | | + | – | | + | + | – | – | + | – | – | – | | – | – | | | | | |
| Юкә | | | | | | – | – | – | | | | | | – | – | - | | | | | |
| Кара з. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | – | |
| Тал аг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| 4. Урман культуралары | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| Н, Ю | + | + | + | – | – | + | + | + | + | | | | | | | | | | | | |
| Ч, П | | | | | | | | | | + | + | – | – | + | + | | | | | | |
| И, Кч, Өр Элмә | | | | | | | | | | | | | | | | + | – | | | | |
| Б | | + | + | – | – | + | + | + | + | + | + | | | + | + | + | | | | | |
| Ус, Т | | | + | – | – | + | + | + | + | + | + | | | + | + | + | | | | | |
| Юкә | | | | | | | | + | | + | | | | | | + | | | | | |
| Кара з. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | – | |
| Тал аг. | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | – |

Искәрмәләр: +- киңәш ителүче чара;
– - киңәш ителми торган чара;
буш графа – әлеге токым бу урман типларының төркемнәренә хас түгел.

## 2.18. Урман үсү зоналары һәм урманлы районнар буенча урманнардан файдалануга карата таләпләрнең үзенчәлекләре

РФ ТРЭМның «Россия Федерациясендә урман үсү зоналары исемлеген һәм Россия Федерациясе Урманлы районнар исемлеген раслау турында» 2014 ел, 18 август, № 367 боерыгы нигезендә Урманчылыкның барча территориясе Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала зонасының урман-дала районында урнашкан.

Бүлектә китерелгән нормативлар Россия Федерациясенең Европа өлешендәге урман-дала зонасының урман-дала районына туры килә.

# 3 БҮЛЕК. УРМАННАРДАН ФАЙДАЛАНУДА ЧИКЛӘМӘЛӘР

## 3.1. Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләмәләр

Урманнарны максатчан билгеләнеш төрләре һәм яклаучы урман категорияләре буенча чикләүләр 18 таблицада китерелде.

18 таблица.

Урманнарның максатчан билгеләнеш төрләре буенча чикләмәләр

| № п/п | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Су саклау зоналарында урнашкан урманнар | Тыела:<br>1) урман утыртмаларын тоташ кисү;<br>2) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратлары куллану;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару, умартачылык һәм печән чабудан гайре;<br>4) урман плантацияләре утырту һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасы ясау;<br>5) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру, линия-ле объектлардан, гидротехника корылмаларыннан һәм углеводородлы чимал ятмаларын геологик өйрәнү һәм эшләү буенча эшләр башкаруга бәйле объектлардан тыш. |
| 2. | Табигый һәм башка төр объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнар | Урман утыртмаларына тоташ кисүләр үткәрү тыела. |
| | Россия Федерациясе субъектлары милкендәге, гомуми файдаланудагы тимер юл, гомуми файдаланудагы федераль автомобиль юллары, гомуми файдаланудагы автомобиль юллары буйларында урнашкан яклаучы урман полосалары | Тыела:<br>1) техник регламентта каралганнан киңрәк итеп линияле корылмалар кисү;<br>2) урман түшәмәсен белән мүк җыю һәм әзерләү. |
| | а) урман-парк зоналары | Тыела:<br>1) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратлары куллану;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;<br>3) авыл-хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылма ятмаларын эшләү;<br>5) капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, |

| № п/п | Урманнарның максатчан билгеләнеше | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан тыш;<br>6) урман плантацияләрен утырту һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасы ясау. |
| | б) яшел зоналар | Тыела:<br>1) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратлары куллану;<br>2) аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру;<br>3) авыл хуҗалыгы алып бару, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында коймалар кую;<br>4) файдалы казылма ятмаларын эшләү;<br>5) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру, гидротехника корылмаларыннан, элемтә линияләреннән, электрүткәргеч линияләрдән, җир асты торбаүткәргечләреннән гайре;<br>6) урман плантацияләрен утырту һәм эксплуатацияләү, урман эшкәртү инфраструктурасы ясау. |
| 3. | Кыйммәтле урманнар | Урман үрентеләрен тоташ кисүләр тыела, сайланма кисүләр үзләренең яклау урманнарының максатчан билгеләнешен саклауны тәэмин итә торган үзлекләрен югалта баручы урман утыртмаларын алмаштыруны тәэмин итмәгән очраклардан тыш.<br>Тыела:<br>1) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру, линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан тыш;<br>2) урман плантацияләре утырту һәм эксплуатациялəү, урман эшкәртү инфраструктурасы ясау. |
| 4. | Эксплуатация урманнары | Урманнардан файдалануның барлык төрләре дә рөхсәт ителә. |

## 3.2. Махсус якланучы урман кишәрлеге төрләре буенча чикләмәләр

Махсус якланучы урман кишәрлекләренең хокукый режимы РФ Урман кодексының 102, 107 ст., Рослесхозның «Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка төрле объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, шулай ук махсус якланучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны файдалану, саклау, яклау, торгызу үзенчәлекләрен раслау турында» 2010 ел, 14 декабрь, № 485 боерыгы (алга таба – Үзенчәлекләр) белән регламентлана.

Махсус яклануты урман кишәрлекләрендә аларның максатчан билгеләнеше белән файдалы үзлекләренә ярашмаган эшчәнлекне гамәлгә ашыру тыела.

Махсус яклануты урман кишәрлекләре төрләре буенча чикләмәләр 19 таблицада күрсәтелде.

19 таблица.

Махсус яклануты урман кишәрлеге төрләре буенча чикләмәләр

<table>
<tr><th>№ п/п</th><th>Махсус яклануты урман кишәрлекләре төрләре</th><th>Урманнардан файдалануда чикләмәләр</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td></tr>
<tr><td>1.</td><td>Су объектлары, чокыр сөзәклекләрендә урнашкан ярсаклагыч, туфраксаклагыч урман кишәрлекләре.<br>Яр буендагы яклагыч полосаларның чикләрендә урнашкан урман кишәрлекләре, аларның киңлекләре:<br>капма-каршы яки нульле авышлыгы булган су яры өчен – 30 м;<br>өч градуска кадәрле авышлыгы булган су объекты яры өчен – 40 м;<br>өч һәм аннан югары градуслы авышлыгы булган су объекты яры өчен – 50 м;<br>су үтә торган сазларның һәм су җыелып тора торган күлләрнең һәм тиешле су агымнары чикләрендә урнашканнар өчен – 50 м;<br>Чокыр сөзәклегендә урнашкан, чокыр кырыена тоташучы урманнар һәм 50 метрга кадәрге киңлектәге урман полосалары.</td><td rowspan="4">Тыела:<br>- тоташ кисүләр уздыру, РФ УК 17 ст. 4 өл., 21 ст. 5.1 өл. каралган очраклардан тыш;<br>– урман эшкәртү инфраструктурасы төзү;<br>– урман плантацияләре ясау;<br>– авыл хуҗалыгы алып бару, умартачылыктан һәм печән чабудан тыш;<br>– капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан тыш;<br>– әлеге урман районында табигый шартларда үсеп китә алмаган агачлар, куаклар, лаианалар, башка урман үсемлекләре төрләренең (токымнарының) интродукциясе.<br>Сайланма кисүләрне бары тик һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларына карата гына башкарырга ярый. Даими урман-орлык кишәрлекләрендә агач токымнарының җимеш бирүен карап тоту тәртибендә сайланма кисүләрне башкару рөхсәт ителә.</td></tr>
<tr><td>2.</td><td>Урмансыз киңлекләр белән чиктәш урман авызлары. Урмансыз җирләрдән 100 м ераклыкта урнашкан, урман кырыеннан кимендә 1,5-2,0 чм ераклыктагы урман авызлары.</td></tr>
<tr><td>3.</td><td>Даими урман-орлык кишәрлекләре. Югары сыйфатлы табигый урманнарның һәм урман культураларының озак вакыт дәвамында кыйммәтле чәчүлек сыйфатына ия булган агач токымнары орлыкларын алу һәм даими әзерләү өчен формалаштырылган югары җитештерүчәнлекле кишәрлекләре.</td></tr>
<tr><td>4.</td><td>Халыкара Кызыл китапка, РФ Кызыл китабына һәм РФ субъектларының Кызыл китапларына кертелгән реликтив һәм эндемик үсемлекләре булган урман</td></tr>
</table>

| № п/п | Махсус яклanучы урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | кишәрлекләре. | |
| 5. | Сирәк һәм югалу куркынычы янаган кыргый җәнлекләрнең яшәү урыннары. Халыкара Кызыл китапка, РФ Кызыл китабына һәм РФ субъектларының Кызыл китапларына кертелгән сирәк һәм югалу куркынычы янаган кыргый җәнлекләрнең яшәү урыннары булган урман кишәрлекләре. | |
| 6. | Тыюлыклы урман кишәрлекләре.<br>Озак вакыт дәвамында табигый юл белән формалашкан, хуҗалык эшчәнлеге һәм рекреацияләү эшчәнлеге нәтиҗәсендә аз җимерелгән, 100-150 гектар мәйданлы, дәүләт табигый тыюлыклары һәм милли паркларның тыюлык зоналары чикләренә керми торган урман кишәрлекләре. | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>1) урман утыртмаларын кисү;<br>2) урманнарны саклау һәм яклау өчен, шул исәптән фәнни максатларда агулы химия препаратлары куллану;<br>3) авыл-хуҗалыгы алып бару;<br>4) файдалы казылма ятмаларын эшләү;<br>5) капиталь төзелеш объектлары урнаштыру.<br>6) урман эшкәртү инфраструктурасы ясау;<br>7) урман плантацияләре ясау. |
| 7. | Бүтән махсус яклanучы урман кишәрлекләре:<br>Тау районнарында урмансыз киңлекләр белән чиктәш җирдә аның өске чиге буйлап 200 м киңлектәге урман киңлекләре.<br>Урмансыз киңлекләрләр арасында урнашкан 100 га кадәрге урман кишәрлекләре.<br>Тау районнарында 100-200 м киңлектәге полосалар, җирле шартларга бәйле рәвештә, 2,5 мең га артык мәйданда су җыю чикләре буенча дулкыннар һәм субүләрләр буенда урнашкан, 20° градустан артык дулкыннар һәм субүләрләр барлыкка китерә торган.<br>Сөзәклек экспозициясенә бәйсез рәвештә 30° текә урыннар авышлыкларындагы урман кишәрлекләре.<br>Дәүләт табигать заказниклары һәм башка махсус саклanучы табигать территорияләре чикләрендәге, мәйданнары аларны барлыкка китергәндә билгеләнә торган урман кишәрлекләре (МСТТ аерым урман кишәрлекләрендә файдалану режимы | Тыела:<br>- тоташ кисүләр уздыру, РФ УК 17 ст. 4 өл., 21 ст. 5.1 өл. каралган очраклардан тыш;<br>– урман эшкәртү инфраструктурасы төзү;<br>– урман плантацияләре ясау;<br>– авыл хуҗалыгы алып бару, умартачылыктан һәм печән чабудан тыш;<br>– капиталь төзелеш объектларын урнаштыру, линияле объектлардан һәм гидротехника корылмаларыннан тыш;<br>– әлеге урман районында табигый шартларда үсеп китә алмаган агачлар, куаклар, лаиаrналар, башка урман үсемлекләре төрләренең (токымнарының) интродукциясе.<br>Сайланма кисүләрне бары тик һәлак булган һәм зарарланган урман утыртмаларына карата гына башкарырга ярый. Даими урман-орлык кишәрлекләрендә агач токымнарының җимеш бирүен карап тоту тәртибендә сайланма кисүләрне башкару рөхсәт ителә. |

| № п/п | Махсус якланучы урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | башка территориягә караганда катгый урнаштырылганда). | |
| | Мәйданнары аларны барлыкка китергәндә билгеләнә торган, әмма федераль әһәмияттәге махсус сакланылучы табигать территорияләре чикләре буйлап кимендә 1000 м киңлектәге полосалы саклау зоналары чикләрендәге урман кишәрлекләре. | |
| | Көртлекләрнең гөлдерәү урыннары тирәли 300 м радиустагы урман кишәрлекләре, 10 мең га урманга 3 тән артык шундый урман кишәрлеге исәбеннән. | |
| | Елганың яисә кондызлар яши торган бүтән су объектының һәр яры буйлап 100 м киңлектәге урман полосалары. | |
| | бал бирә торган кишәрлекләр (өлгереп килүче, өлгергән һәм картайган урман үсентеләре, даими умартачылыклар тирәли 3 чм радиуста юкә һәм ак сәрби өстенлек итә торган урманнар). | |
| | агачларны даими рәвештә җентекләп үлчәү һәм озак чорда агач-куак үсентеләре белән капланган урында урман корылышы яисә урман хуҗалыгы тамгалары белән төзекләндерелгән һәм урман корылышы планшетларына кертелгән үсентеләрне төгәл чагылдыру өчен билгеләнгән даими сынау мәйданнары. | |
| | Шифаханәләр, балалар лагерьлары, ял йортлары, пансионатлар, туристлык базалары һәм башка дәвалау һәм савыктыру учреждениеләре тирәли иң күбе 1 чакрым радиуста (дәвалау-савыктыру урыннарын шифаханә (тау шифаханәсе) саклау округларының беренче, икенче һәм өченче зоналарында яисә урман хуҗалыгын алып баруның һәм урманнардан файдалануның шундый ук режимы булган яклаучы урманнарның бүтән категорияләренә караучы урманнарда урнашмаган булсалар, алар бүленәләр. | |
| | җирле шартларга карап, федераль яисә төбәк туристлык маршрутыннан һәр якка | |

| № п/п | Махсус якланучы урман кишәрлекләре төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | таба 100 метрдан 250 метрга кадәр киңлектәге урман полосалары. | |
| | Авыл торак пунктлары һәм бакчачылык ширкәтләре тирәли 1 км киңлектәге урман кишәрлекләре. | |

Искәрмә. Махсус якланучы урман кишәрлекләре урнашкан җир һәм аларның мәйданы урманнар коруны проектлаганда күрсәтелә.

## 3.3. Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләмәләр

Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләмәләр 19.1 таблицада китерелде.

19.1 таблица.

Урманнардан файдалану төрләре буенча чикләмәләр

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Агач әзерләү | Файдалану өчен исәпкә алынган диләнкене (агач материалы алуның мөмкин булган күләменнән) артып китә торган күләмдә, шулай ук кисентеләрнең яшен бозып, агач материалы әзерләү тыела. (РФ УК 29 ст. 4 өл.) Россия Табигать министрлыгының 2016 ел, 13 сентябрь, № 474 боерыгы белән расланган Агач материалы әзерләү кагыйдәләре нигезендә:<br>а) елга һәм чишмә үзәннәрен сөйрәмә җир трассалары һәм урман юллары сыйфатында куллану рөхсәт ителми;<br>б) диләнкедән читтә урман утыртмаларын, үсемчелек катламын һәм туфракларны зарарлау, урманнарны сәнәгать һәм башка төрле калдыклар белән чүпләү рөхсәт ителми;<br>в) юлларны, күперләрне һәм ызаннарны, шулай ук киптерүче челтәрне, юл, гидромелиоратив һәм башка корылмаларны, су агымнарын, чишмәләрне, елгаларны саклау мөһим;<br>г) аударылыган һәм асылынып төшкән, киселгән агачларны (киселгән һәм диләнкедә калдырылган агачларны исәпкә алып) калдыру, сакланырга тиешле яшь шытымны зарарлау яисә һәлак итү тыела.<br>д) чик, квартал, диләнке баганаларын һәм башкаларын, агачларда һәм түмәрләрдәге тамгаларны, ярлыкларны һәм саннарны бетерү яисә зарарлау тыела;<br>е) кисүгә тиешле булмаган һәм Россия Федерациясенең Агач материалы әзерләү кагыйдәләре һәм урман |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | законнары нигезендә сакланырга тиешле агачларны, шул исәптән орлык бирү чыганакларын һәм плюс агачларын кисү һәм зарарлау тыела;<br>ж) рөхсәт ителгән вакыты (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) тәмамлангач агач әзерләү, шулай ук файдалану хокукы туктатылгач яисә тәмамлангач агач әзерләү рөхсәт ителми;<br>з) билгеләнгән вакытына (рөхсәт ителгән кичектереп торуларны исәпкә алып) алып чыгылмаган агачны диләнкедә калдыру рөхсәт ителми;<br>и) диләнке ясауның технологик картасында каралмаган урыннарга агач чыгару, тарттыру рөхсәт ителми;<br>к) диләнке чистарту эшләрен үтәмәү яисә вакытында үтәмәү рөхсәт ителми;<br>л) сөйрәмә җирләрдән һәм төяү мәйданнарыннан кала, туфракның өске уңдырышлы катламын юк итү рөхсәт ителми;<br>Диләнкеләрдә агач әзерләгәндә яшәргә яраклы, аларның табигый ареалы чикләрендә үсеп китүче (әгәр тиешле агач токымының урманнар составындагы мәйданы өлеше урманчылык мәйданының 1 процентыннан артып китмәсә) кыйммәтле агач токымнарын (имән, бук, корычагач, эрбет, юкә, күг, элмә, кара зирек, чәчә торган каштан) кисү рөхсәт ителми.<br>Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән зат төрләре сакланырга тиешле.<br>Агач әзерләгәндә урман утыртмалары агачлары составында өч һәм аннан да күбрәк берәмлектә эрбет булган, өлгергән, картайган урман утыртмаларын кисү рөхсәт ителми. |
| 2. | Чәер әзерләү | Түбәндәгеләргә кирт салу тыела:<br>а) юкка чыгарганчыга кадәр зарарлы организм чыганакларында урнашкан урман утыртмаларына;<br>б) урман янгыннары, зарарлы организмнар һәм башка тискәре факторлар нәтиҗәсендә зарарланган һәм зәгыйфьләнгән урман утыртмаларына;<br>в) Россия Федерациясе законнары нигезендә агач әзерләү максатында өлгергән һәм картайган урман утыртмаларын тоташ яки сайланма кисүләр рөхсәт ителмәгән урманнардагы урман утыртмаларына;<br>г) даими урман-орлык кишәрлекләрендә, урман-орлык плантацияләрендә, генетика резервацияләрендә урнашкан урман утыртмаларына, шулай ук плюс агачларына, орлыклыкларга, орлык чәчәклекләренә һәм полосаларына (2012 ел, 24 гыйнвар, № 23 Рослесхоз боерыгы белән расланган Чәер әзерләү кагыйдәләренең |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | 7 пункты). |
| 3. | Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу | Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу өчен үсемлекләрнең түбәндәге төрләрен куллану тыела:<br>– Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгәннәрне;<br>– наркотик матдәләр дип танылучыларны;<br>– агачын әзерләү рөхсәт ителми торган агачларның һәм куаклыкларның төрләре (токымнары) исемлегенә кертелгәннәрне.<br>Агач булмаган урман ресурслары әзерләү һәм җыеп алу чикләнергә яки радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә тыелырга мөмкин.<br>2011 ел, 05 декабрь, № 512 Рослесхоз боерыгы белән расланган Агач булмаган урман ресурсларын әзерләү һәм җыеп алу кагыйдәләре нигезендә:<br>– эрозиягә каршы урманнарда; су объектлары, чокыр авышлыклары буйларында урнашкан ярсаклагыч һәм туфраксаклагыч урман кишәрлекләрендә, шулай ук тулылыгы 0,8-1,0гә тигез булган яшь агачларда һәм йомылмаган урман культураларында түмәр сагызын әзерләү рөхсәт ителми (13 пункт);<br>– агачларны туз әзерләү өчен кисү тыела (14 пункт);<br>– урманнарда табигый һәм башка төрле объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урман түшәмәләрен җыярга рөхсәт ителми (20 пункт). |
| 4. | Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыю | Төрләре Кызыл китапка, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән яки наркотик матдәләр булып саналган гөмбәләрне һәм кыргый үсүче үсемлекләрне әзерләү һәм җыеп алу рөхсәт ителми.<br>Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәре җыеп алу радиоактив матдәләр белән пычранган районнарда билгеләнгән тәртиптә чикләнергә мөмкин.<br>2011 ел, 05 декабрь, № 511 Рослесхоз боерыгы белән расланган Азык-төлек урман ресурслары әзерләү һәм дару үләннәрен җыеп алу кагыйдәләре нигезендә:<br>– җимеш бирә торган агачларны кисү һәм җимешләр әзерләү өчен ботакларны кискәләү тыела (14 пункт);<br>– чикләвекләр әзерләгәндә агачларны һәм куакларны кисү, шулай ук агачларга һәм куакларга зыян сала торган ысулларны куллану тыела (15 пункт);<br>– гөмбәләр әзерләү аларның ресурсларын саклауны тәэмин итүче ысуллар белән башкарылырга тиеш (16 пункт);<br>– каен суты әзерләү өлгергән урман кишәрлекләрендә кисәренә кимендә 5 ел калгач рөхсәт ителә (17 пункт);<br>– башка төрле азык-төлек ресурслары әзерләү аларның |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | үрентеләре торышына зыян салмый торган ысуллар белән башкарылырга тиеш; үсемлекләрне тамырлары белән өзеп алырга, яфракларына (ботакларына) һәм тамырларына зыян салырга рөхсәт ителми (18 пункт). |
| 5. | Аучылык хуҗалыгы өлкәсендә эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру | Яшел зоналарда һәм урман-парк зоналарында, шулай ук шәһәр урманнары территорияләрендә аучылык хуҗалыгы өлкәсендәге эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру тыела (РФ УК 105 ст. 3 өл. 2 пункты). |
| 6. | Авыл хуҗалыгы алып бару | Су саклау зоналарында урнашкан урманнарда, печән чабу һәм умартачылыктан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (РФ УК 104 ст. 1 өл. 3 п.).<br>Яклаучы урманнарның яр буе чикләрендәге җирләрне сөрү, авыл хуҗалыгы хайваннарын көтү һәм алар өчен җәйге лагерьлар, ванналар оештыру тыела (РФ Су кодексының 65 ст. 17 өл 1, 3 пунктлары).<br>Урман-парк зоналарында авыл хуҗалыгы алып бару тыела (РФ УК 105 ст. 3 өл. 3 п.).<br>Яшел зоналарда, печән чабу һәм умартачылыктан, шулай ук печән чабу һәм умартачылык максатларында киртәләп алулардан гайре, авыл хуҗалыгы алып бару тыела (РФ УК 105 ст. 5 өл. 2 пункты).<br>Шәһәр урманнарында авыл хуҗалыгы алып бару тыела (РФ УК 105 ст. 5.1 өл.).<br>Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә авыл хуҗалыгы алып бару тыела (РФ УК 107 ст. 2 өл.).<br>Махсус якланучы урман кишәрлекләрендә, тыюлыклы урман кишәрлекләреннән гайре, печән чабу һәм умартачылыктан кала, авыл хуҗалыгын алып бару тыела (РФ УК 107 ст. 2.1 өлеше). |
| 7. | Фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Урманнарны фәнни-тикшеренү һәм мәгариф эшчәнлеге өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм аның чикләрендәге территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату (2011 ел, 23 декабрь, № 548 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан фәнни-тикшеренү эшчәнлеген, мәгариф эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләренең 9 пункты).<br>Агулы химик препаратлар куллану тыела (РФ УК 103 ст. 5 өл, 104 ст. 1 өл., 105 ст. 3 өл. 1 п.). |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 8. | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру | Рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен тапшырылган урман кишәрлекләрендә табигый ландшафтлар, хайваннар дөньясы объектлары, су объектлары сакланырга тиеш (РФ УК 41 ст. 3 өл.).<br>2012 ел, 21 февраль, № 62 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан рекреация эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>– рекреацияләү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен урманнардан файдалану әйләнә-тирә мохиткә һәм кеше сәламәтлегенә зыян китерми торган ысуллар ярдәмендә башкарыла (6 пункт);<br>– вакытлы корылмаларны, физкультура-савыктыру, спорт һәм спорт-техника корылмаларын вакытлыча урнаштыру барыннан элек агачсыз һәм куаксыз урыннарда, ә мондый урыннар булмаганда – артык кыйммәтле булмаган агачлар белән капланган, урманнарны үзләштерү проектында билгеләнгән урыннарда рөхсәт ителә (8 пункт). |
| 9. | Урман плантацияләре утырту һәм аларны эксплуатацияләү | Плантация ясау максатларында түбәндәгеләрне файдалану рөхсәт ителми:<br>а) су саклау зоналарында урнашкан урманнарны;<br>б) табигый һәм башка төрле объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнарны;<br>в) кыйммәтле урманнарны;<br>г) махсус якланучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны (2010 ел, 14 декабрь, № 485 Рослесхоз боерыгы белән расланган Су саклау зоналарында урнашкан урманнарны, табигый һәм башка төрле объектларны яклау вазыйфасын үтәүче урманнарны, кыйммәтле урманнарны, шулай ук махсус якланучы урман кишәрлекләрендә урнашкан урманнарны файдалану, саклау, яклау, торгызу үзенчәлекләренең 30 пункты). |
| 10. | Җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләре, дару үләннәре үстерү | 2011 ел, 05 декабрь, № 510 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>– җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен, беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урмансыз җирләр, шулай ук урманга әверелмәгән диләнкеләр, аланнарны һәм аларга урман культураларын утырткачы урманның табигый торгызылуы мөмкин булмаган башка урман үсемлекләре белән капланмаган җирләр; рекультивацияләнергә тиешле (эшләнелгән торфлыклар һ.б.) (11 пункт) җирләр файдаланыла.<br>– җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | дару үләннәрен –үстерү өчен үзгәртеп коруга билгеләнмәгән, азкыйммәтле утыртма кишәрлекләре файдаланылырга мөмкин (12 пункт);<br>РФ УК 60.15 статьясы нигезендә Россия Федерациясе Кызыл китабына, Татарстан Республикасы Кызыл китабына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләреннән җимешле, җиләкле, декоратив урман үсемлекләрен, дару үләннәрен үстерү өчен файдалану тыела. |
| 11. | Урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү | 2011 ел, 19 июль, № 308 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан урман үсемлекләренең утырту материалын үстерү өчен файдалану кагыйдәләре нигезендә:<br>– урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен, иң беренче чиратта, урман фонды җирләре составындагы урман белән капланмаган җирләрне, шулай ук урмансыз диләнкеләрне, аланнарны һәм башка, урман үсемлекләре белән капланмаган, урман урнашкан бүтән категория җирләре файдаланыла (11 пункт);<br>– урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең яхшыртылган һәм сортлы орлыклары, яки, әгәр андый орлыклар булмаса, урман үсемлекләренең нормаль орлыклары кулланыла (12 пункт);<br>– урман үсемлекләренең утырту материалын (үрентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен урман үсемлекләренең районнарга бүленмәгән орлыкларын, шулай ук сыйфаты тикшерелмәгән урман үсемекләре орлыкларын, чәчүлекләрен һәм башкаларын куллану тыела (13 пункт);<br>– Россия Федерациясе Кызыл китабына, Россия Федерациясе субъектлары кызыл китапларына кертелгән үсемлек төрләре очрый торган урман кишәрлекләрен урман утыртмаларының утырту материалын (үсентеләр, чәчкеннәр) үстерү өчен файдалану Россия Федерациясе Урман кодексының 60.15 статьясы нигезендә тыела. |
| 12. | Җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, файдалы казылма ятмаларын эшләү | Яшел зоналарда һәм урман-парк зоналарында, шулай ук шәһәр урманнары территорияләрендә файдалы казылма ятмаларын эшләү тыела (РФ УК 105 ст. 3 өл. 4 п.).<br>Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, файдалы казылма ятмаларын эшләү максатларында файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) бульдозер ярдәмендә агачлар аудару һәм урман кишәрлекләрен агач үсемлекләреннән чистарту, чик буе |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | полосаларын һәм урман авызларын агач калдыклары белән чүпләү, урман авызындагы агач кәүсәләрен һәм скелет тамырларын зарарлау, җәйге чорда яңа киселгән агачларны махсус чараларсыз гына урманда саклау;<br>б) урман утыртмаларын суга батыру һәм озак итеп су бастыру;<br>в) бирелгән урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфракны зарарлау;<br>г) урманнарны төзелеш, сәнәгать, агач, көнкүреш һәм бүтән калдыклар, чүпләр белән чүпләү;<br>д) бирелгән урман кишәрлеге мәйданын һәм аның чикләрендәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>е) ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап, шул исәптән урман кишәрлегеннән читтә транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (2010 ел, 27 декабрь, № 515 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкару, файдалы казылма ятмаларын эшләү буенча файдалану тәртибенең 18 пункты). |
| 13. | Сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү | Тыюлыклы урман кишәрлекләрендә сусаклагычлар һәм башка төрле ясалма су объектлары, шулай ук гидротехника корылмалары һәм махсуслаштырылган портлар төзү һәм эксплуатацияләү тыела (РФ УК 107 ст. 2 өл. 5 п.). |
| 14. | Линияле объектлар төзү, реконструкцияләү, эксплуатацияләү | Урманнарны линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлеген һәм тапшырылган урман кишәрлегеннән читтәге янәшә урнашкан территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) тапшырылган урман кишәрлеге һәм тиешле сак зоналарыннан читтә ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (2011 ел, 10 июнь, № 223 Рослесхоз боерыгы белән расланган Урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору, эксплуатацияләү өчен файдалану кагыйдәләренең 15 пункты). |

| № п/п | Урманнардан рөхсәтле файдалану төрләре | Урманнардан файдалануда чикләмәләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| | | Урман-парк зоналарында урманнардан линияле объектлар төзү, үзгәртеп кору һәм эксплуатацияләү өчен файдалану тыела (РФ УК 105 ст. 3 өл. 5 п.). |
| 15. | Агач һәм башка урман ресурслары эшкәртү | Яклаучы урманнарда, шулай ук махсус яклanuчы урман кишәрлекләрендә урман эшкәртү инфраструктурасы ясау тыела (РФ УК 14 ст. 2 өл.).<br>Урманнарны агач һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдаланганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) җир өсте һәм туфрак эче су агынтыларын бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>б)  тапшырылган урман кишәрлеген һәм тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә янәшә торучы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеге мәйданнарын һәм аннан читтәге территорияләрне химик һәм радиоактив матдәләр белән пычрату;<br>г) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буйлап транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда йөрү (РФ ТРЭМның 2014 ел, 01 декабрь, № 528 боерыгы белән расланган Урманнардан агач материалы һәм башка урман ресурслары эшкәртү өчен файдалану кагыйдәләренең 6 пункты). |
| 16. | Дини эшчәнлекне гамәлгә ашыру | Дини эшчәнлек башкарганда түбәндәгеләр рөхсәт ителми:<br>а) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә урман утыртмаларын, үсемлекләр капламын һәм туфрак зарарлау;<br>б) тапшырылган урман кишәрлегеннән читтә өске һәм туфрак эче сулары агып төшүне бозарлык, урман кишәрлекләрен су бастырырлык яисә сазландырырлык итеп эшләр башкару һәм корылмалар төзү;<br>в) тапшырылган урман кишәрлеген һәм аның янындагы территорияләрне төзелеш һәм көнкүреш калдыклары, агач калдыклары, бүтән калдыклар белән чүпләү;<br>г) ирекле, билгеләнмәгән маршрутлар буенча транспорт чараларында һәм бүтән механизмнарда үтеп керү. |

20 таблица.

Диләнке эшләрен гамәлгә ашырганда сакланырга тиешле биологик күптөрлелек объектларының һәм буфер зоналарының нормативлары һәм параметрлары

| № п/п | Биологик күптөрлелек объектларының аталышы | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналары зурлыгы (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Даими һәм вакытлы су агымнары | Су агымының аерым ачык күренеп тора торган үзәне. Вакытлы су агымы даими рәвештә су басу эзләре буенча ачыкланырга мөмкин. Коры җәйдә су агымы кибәргә мөмкин. | Әгәр нормативларда башкача билгеләнмәсә, даими су агымнары өчен киңлеге кимендә 50 м, вакытлы су агымнары үзәннәре буйлап кимендә 20 м буфер зоналары билгеләнә. Буфер зонасы инде урман баскан тугайлык булырга тиеш түгел һәм су агымы үзәненнән башлап яисә урмансыз тугайлыктан башлап һәр ягыннан үлчәнә. Искәрмә: буфер зонасына мәҗбүри рәвештә сөзәк таулар һәм тамыр токымнары чыккан урыннар кертелергә тиеш. |
| 2 | Кизләүләр (чишмәләр), грунт сулары чыгу урыннары | Төптә кизләүләр аерылып торырга мөмкин, яисә су таудан агучы чишмә рәвешендә агып чыга.<br>Чишмә карст бүрәнкәсеннән агып чыгарга мөмкин. | Чишмәләр буйлап (алар чыккан урыннар тирәли) киңлеге кимендә 50 м буфер зоналары аерыла.<br>Дәвалану яисә савыктыру максатларында файдаланыла торган, шулай ук зиярәт кылу объекты булып хезмәт итүче (изгеләр чишмәсе) чишмәләр тирәли буфер зонасы киңәйтелергә мөмкин – хосусый тәртиптә билгеләнә. |
| 3 | Сазланган уйсулыклар һәм вакыты-вакыты белән су баса торган урыннар | Кишәрлек артык дымланган: су өслеккә чыккан яисә аяк белән басканда күренә. Объект чикләрендә – артык дымланган урман типларының туфрак катламы. Кырые буйлап, шулай ук объектлар чикләрендә агачлар юк яисә үләне аз булган агачлыклар белән бирелә. | Су баса торган кишәрлек кырые буйлап су өслектә тора яисә басканда чыга. Рельефта түбәнрәк урында, туфрак өсте капламы чигендә, чиге буйлап туфрак өсте катламы һәм агачлыклар сыйфатында. |
| 4 | Күлләрнең, сазларның һәм башка ачык урыннарның ярлары буйлап урман кашаклары, сазлыкларда | Ачык киңлекләрнең (күлләр, сазлар, болыннар) ярларында урман кашакларын аерып чыгару урман корылышы буенча яклаучы полоса билгеләнмәгән очракта башкарыла. | Киңлеге кимендә 50 м урман кашагы күл суыннан алып яисә ачык башка урын киселешеннән башлап үлчәнә. Ләкин, әгәр күлдә утраучык яисә сазланган урын булса, буфер зонасын каты яр кырыеннан яисә сазлык яки |

| № п/п | Биологик күптөрлелек объектларының аталышы | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналары зурлыгы (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | зур булмаган утраулар | | ачык территория кырыеннан башлап үлчиләр. Шулай ук сазлык белән әйләндереп алынган зур булмаган (0.5 га кадәр) утраулар да билгеләнә. Искәрмә: әгәр әлеге күл яисә сазлык хайваннарның сезонлы туплану һәм үрчү урыны, сирәк очраучы һәм нәзберек төрләрнең фактта тереклек итү урыны булып торса, ул очракта буфер зонасы киңәйтелергә тиеш |
| 5 | Чокырлар, су агымнарының тирән үзәнлекләре, башка төрле сөзәклекләр | Су агымнарының тирән кергән үзәнлекләре һәм чокырлар – тауның текәлеге 10° башланып киткәндә. Башка текә таулар (киртләчләр, текә ярлар) – тауның текәлеге кимендә 20° булганда. | Нормативларда башкача билгеләнмәсә, сөзәк тау өсте һәм асты буйлап киңлеге кимендә 15-20 метрлы буфер зоналары билгеләнә. Сөзәк тауның үзе һәм буфер зонасы әһәмиятле объект булып тора. |
| 6 | Төп токымнарның, урман белән капланган калкулыкның шәрә урыннары, известьлы токым, ачык комлы кишәрлекләр, дюналар, таш чәчелгән урыннар | Азкуәтле туфрак үсемлекләре белән капланган, төп токымнар шәрәләнә торган урыннар<br>Таш чәчелгән урыннар – төрле зурлыктагы һәм шомалыктагы ташлар җыелмасы. Тау битләрендә, тау киртләчләрендә, ярларда һәм алар янәшәсендә еш очрый. Ташлы һәм шәрәләнгән урыннар аз куәтле туфрак үсемлекләре белән капланырга мөмкин. Комлы дюналар өлешчә аз куәтле туфрак-үсемлек катламы белән ныгытылырга мөмкин. | Объект кишәрлекнең төп токымнары шәрәләнгән чиге буйлап яисә таш чәчелгән урын чиге буйлап билгеләнә. Таш чәчелгән, төп токымнар шәрәләнгән урын, дюна комплексы кырыеннан киңлеге кимендә 20 метрлы буфер зонасы билгеләнә. |
| 7 | Аерым зур йомры ташлар һәм кантарлар | Лишайниклар һәм үсемлекләр белән капланган аерым зур йомры ташлар (2 $м^3$ башлап) һәм кантарлар. | Аерым зур йомры ташларны мәйданлы объектны билгеләмичә генә билгеләргә була, аларның тупланышы мәйданлы объект буларак билгеләнә |
| 8 | Карст элементлары | Известькатнашмалы токым ятмалары якын уткан урыннарда ярыклар, бүрәнкәләр, юкка чыга торган су агымнары һәм сулыклар, коры үзәнлекле сазлыклар. Известьташның | Объект тирәли уйсулык, куышлык кырыеннан киңлеге кимендә 20 метрлы буфер зонасы билгеләнә. |

| № п/п | Биологик күптөрлелек объектларының аталышы | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналары зурлыгы (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | калын катламының су белән былган куышлыклары. Өслегендә уйсулыклар, җимерек, ярык урыннар күренә. Карст элементлары белән чишмәләр, кизләүле сазлыклар бәйле булырга мөмкин. Өслегендә шәрәләнгән известьташлар күренергә мөмкин. | |
| 9 | Ачык һәм ярымачык урыннар | Урман белән капланмаган урыннар: зур булмаган аланлыклар, сирәклекләр, болынлыклар һ.б. (шул исәптән сазлыкланган). Агачларның тулылыгы 0,4 ким. Запасы 50 $^{м}3$/га ким. | Чиге буйлап агачлар арасында (тулылыгы һәм запасы ким булган кишәрлек) |
| 10 | Таркалу тәрәзәләре чыбык-чабык һәм җил аударган агачлар-туфрак комплекслары белән тупланган. | Төрле токымга караган, төрле таркалу стадияләрендәге чыбык-чабыклар (диаметры 20 см башлана). Җил аударган агачлар-туфрак комплекслары (ВПК) – зур агачларның тамыр системасы һәм туфракның өске катламнары белән бергә авуы нәтиҗәсе. | Таркалу тәрәзәләрен табигый яңару төркемнәре, шулай ук башка объектлар белән берлектә билгеләү максатка ярашлы була. Билгеләү эше объект чикләре буенча башкарыла. |
| 11 | Коры-сары, биек түмәрләр, куышлы агачлар, берән-сәрән ятучы зур чыбык-чабыклар | Төрле токымнардан зур күләмле (диаметры 20 см башлана торган) коры-сары. Куышлы һәм тукран тукыган эзләре булган коры-сары аеруча кыйммәтле була. 2-5 м биеклегендәге һәм 20 см зуррак диаметрлы табигый эре түмәрләр. Куышлы агачлар. Төрле токымга караган, төрле таркалу стадияләрендәге чыбык-чабыклар (диаметры 20 см башлана). | Диләнке эшләгәндә куркыныч тудырмый торган коры-сарыны саклау максатка ярашлы була. Коры-сарылы һәм куышлы тере агачлар зарури сакланырга тиеш. |
| 12 | Күп еллык агачлар һәм аларның чәчәклекләре, җыйнак биологик кыйммәтле урыннар | Берән-сәрән күп еллык агачлар, аларның чәчәклекләре һәм җыйнак биологик кыйммәтле кишәрлекләр. | Күп еллык, янгынга каршы корытылган наратлар, карт усак, кара зирек, кәҗә талы аеруча кыйммәтле. Агачларның ябалдашы яхшы үсеш алган һәм җилгә каршы торырга сәләтле булырга тиеш. Күп еллык агачларның чәчәклекләре һәм җыйнак биологик кыйммәтле өлешләре составында |

| № п/п | Биологик күптөрлелек объектларының аталышы | Биологик күптөрлелек объектларына сыйфатлама | Буфер зоналары зурлыгы (зарурлык булганда) |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | агачларны саклау оптималь булып тора. |
| 13 | Төбәк өчен сирәк токым агачлары | Киң яфраклы токым агачлары: имән, корычагач, карама, өрәңге, юкә. | Сирәк токым агачларының җыйнак төркемнәрен һәм шушы токымнарга караучы берән-сәрән агачларны үз эченә алган чәчәклекләр саклана. |
| 14 | Сирәк һәм терлек азыгы булган куаклыклар | Чикләвек куагы, артыш, миләш, гөлҗимеш, зелпе куаклары һ.б. | Сөйрәнмәләрдән башка саклана. |
| 15 | Яңартылуның гамәлдәге төркемнәре | Киселгән урыннарда үсеш алырга мөмкин булган ышанычлы үренте төркемнәре. Дренажланган урыннарда агач чыбылдыгы тәрәзәләрендә яңартылу төркемнәре, зур коры-сары тупланган урыннарда чыршы шытымы. | Үренте чәчәклекләре яңартылуның югары тыгызланган өлеше чикләре буенча билгеләнә |
| 16 | Сирәк очраучы һәм нәзберек үсемлекләрнең һәм гөмбәләрнең тереклек итү урыннары | Россия Федерациясе Кызыл китабына һәм/яисә төбәк Кызыл китабына кертелгән сирәк очраучы һәм нәзберек үсемлек һәм гөмбә төрләренең яңа ачыкланган даими тереклек итү урыннары. | Төрләрнең биологиясе һәм экологик таләпләре нигезендә билгеләнә. Күпчелек сирәк төрләрне билгеләве авыр булганга күрә, сирәк төр һәм аларны саклау өчен зарури чикләр булу-булмавын тәгаенләштерү өчен биология белгеченә мөрәҗәгать итәргә киңәш ителә. Әгәр бер нөсхә яисә затларның җыйнак төркеме ачыкланса, алар тирәли киңлеге кимендә 50 метрлы буфер зонасын билгеләргә кирәк. |

Гамәлдәге урман орлыкчылык объектларының нормативлары һәм параметрлары әлеге урман хуҗалыгы регламентында әзерләнми, урман орлыкчылык объектлары турында белешмәләр ел саен Россия Табигать министрлыгының «Дәүләт урман реестрын алып бару формаларын раслау турында» 2016 ел, 06 октябрь, № 514 боерыгы белән расланган 14-ГЛР формасы буенча яңартыла.

___

**Лениногорск урманчылыгы буенча урман хуҗалыгы регламентын килештерү кәгазе**